ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№06 (401)
ИЮНЬ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

КАНАТЛАНДЫРА ТОРГАН БИЗНЕС ТАРИХЫ

№05 (400)
МАЙ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Илсөяр Закирова,
Николай Крушинин, Сөмбел Могыйнова,
Наилә Хәйретдинова, Әхмәт Шакиров
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Рита Хәбирова.
Фото Рита Хәбирова архивыннан

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-1010
Басарга кул куелды: 18.06.2025
Чыгу көне: 24.06.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ТАВЫШ БИР, ЮКСА ОТТЫРАБЫЗ!

Җәй бездә өч айлык отпуск булып дәвам итми, шунысы кызганыч. Кайчакта бер айга да тулмый әле ул! Тормыш шундый инде, нишләтәсең. Шәһәрдә чыдап булмаслык челлә булганда, термометрдагы терекөмеш космик дәрәҗәдә күтәрелгәндә, салкын кирәк. Безне Казанның парклары белән скверлары коткара, шөкер, соңгы елларда алар мәркәзебездә шактый күбәйде. Әле тагын да күбрәк була алыр иделәр... әгәр без тавыш бирергә өйрәнә алсак. Әмма без, ни кызганыч, онытып җибәрәбез. 2026 елда Казанны бизәргә тиешле объектларны сайларга өндәгәч, гражданнар бик аз активлык күрсәткән, ди. Моның начар ягы бар – без федераль ярдәмнән мәхрүм калачакбыз.

Казанда 32 җәмәгать урыны өчен тавыш бирү 21 апрельдә башланып китте һәм 12 июньдә тәмамланачак. Шәһәр бу программада 20 ел дәвамында катнаша. Шул вакыт эчендә парклар белән скверлар мәйданы биш мәртәбәгә артты. Әмма әле җәмәгать урыннары җитәрлек булмаган районнар да бар: Вахитов районында Кабан күле яр буенең өченче өлешен төзекләндерү үз чиратын көтә, Солтангалиев скверы да шулай ук. Совет районында – Нокса урманы, Яңа Савин районында – Укучылар скверы, Идел буе районында – Г.Тукай исемендәге Дәүләт филармониясе янындагы сквер, Мәскәү районында – «Тәбриз» скверы, Киров районында – Петров исемендәге паркның икенче чираты.

ТР Дәүләт хезмәте порталында болардан кайсын да булса сайлап алырга һәм үз вариантыңны тәкъдим итәргә мөмкин: gorodsreda.tatar.ru.

Иренмәгез, югыйсә парклар белән скверлардан колак кагачакбыз!

Сезнең тавыш биреп өлгергән редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китереп бирешле,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп бирешле,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» журналына 104 яшь

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

барысы тик ТАТАРСТАНДА

«ПРОСТОКВАШИНО»ДАГЫ ӘТИ ТАВЫШЫ

«Мондый песием булса, бәлки, мин гомердә дә өйләнмәгән булыр идем...» – «Каникулы в Простоквашино» мультфильмындагы дядя Фёдорның әтисе сүзләрен хәтерләмәгән кеше юктыр, дип уйлыйм. Һәрхәлдә, безнең илдә.

Ә менә персонажны шундый яхшы истә калырдай тавыш белән «бүләкләгән» актёрны белүчеләр – сирәк. Беләсегез килсә, безнең якташыбыз ул – Герман Качин. Казанда туган, 1950 нче еллар уртасында театр сәхнәсендә уйнаган. Дөрес, һөнәри белеме булмаган килеш. Соңрак ВГИКны тәмамлаган.

1960-90 нчы елларда Качин дистәләгән фильмда төшә. Мисал өчен, «Бриллиантовая рука» лентасында Семён Семёнович Горбунковны (Юрий Никулин) диңгез круизында озатып йөргән репортёр – нәкъ менә ул. «Доживём до понедельника», «Освобождение», «Щит и меч», «Петровка, 38» һәм башка дистәләгән фильмнарда уйный. Төп рольләрдә дә күреп беләбез – «Овраги» белән «Живодёр» картиналарында, мәсәлән. Болары инде – 1990 нчы елларда.

Әмма дядя Фёдорның Качин исеме белән сөйләшә торган әтисе – ул, әлбәттә, кабатланмас очрак. Мультфильм персонажының канатлы гайбәрәгә әверелгән җөмләләре дә нәкъ шундый ук. Әйтик, менә бу, бездә гел елмаю уята торганы – «Акылдан берәмләп кенә язалар, ә менә грипп белән күмәк авырыйлар».

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. KazanForum мәйданындагы рекордлар
Кул куелган килешүләрнең бәясе күпме

6. Хай-тек стилендәге татар әкияте
Анда энергетиклар ни рәвешле катнаша

8. Яңа технологияләргә йөз тоту
Ясалма фәһем фермага нинди файда китерә

22. Казан метросы
Метро төзүчеләр киләчәк буынга нинди юллама калдырган

26. Җир асты табылдыклары
Метро төзегәндә нәрсәләргә юлыгалар

30. Метрога дигән миллиардлар
Аларны кайда табалар

игелекле эшләр

36. Дөньяның иң гүзәл урыны
Мөслим ничек гөлбакчага әйләнгән

42. Ашамлыкларның психик энергиясе
Бизнес королевасы нәрсә белән сыйлый

58. Могҗизалар иленә юллама
Ул ничек Аю-Даг тавына китерә

60. Адъютант алып килгән «Поморин» теш пастасы
«Артек» ерак төбәктән килгән үсмерне кай ягы белән шаккатыра

66. Балачакның иң бәхетле мае
«Артек» ничек истә калган

68. Гамьле әңгәмә
Камил Кәримов ни өчен юбилеена әзерләнми

мәңгелек кыйммәтләр

74. 41 ел балалары
Сугыш чоры балалары нинди авырлыклар күргән

76. Сугышның 80 еллыгына
Батыр егетләр «телне» ничек алып кайткан

84. Китап киштәсе
Җәен нинди китаплар укырга

90. Татарстан авыллары
Иске Карамалы: аккошлар кайчан кайта

96. Казанның агач архитектура һәйкәлләре
Сабитовлар йорты ничек сакланган

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Фото: kino-teatr.ru

Акыллы гамәлләр



13.05

Владимир Путин, РФ Президенты, – «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVI Халыкара икътисадый форумда катнашучыларны сәламләп:

– Күпмилләтле илебез гасырлар дәвамында ислам дөньясы дәүләтләре белән ныклы хезмәттәшлек итә. Һәм бүген, катлаулы халыкара вазгыятькә карамастан, без икътисадый, фәнни, мәгариф, гуманитар, төбәкара элемтәләрне эзлекле рәвештә ныгытуны дәвам итәбез. Шуны билгеләп үтәм: Татарстан әлеге үзара файдалы һәм дөрес корылган мөнәсәбәтләрне актив үстерә торган Россия Федерациясе субъектларының берсе.

Игелекле эшләр

14.05

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Рәисе, – илдә иң зур Kazan Halal Market ярминкәсен ачу тантанасында:

– Бүген хәләл – тирән рухи һәм мәдәни кыйммәтләрне чагылдыра торган тулы бер тормыш фәлсәфәсе. Әлеге система бөтен дөнья күләмендә миллионлаган кешене берләштерә, һәм Татарстан хәләл индустрияне танытуга, аны үстерүгә аерым игътибар бирә.



Мәңгелек кыйммәтләр

14.05

Андрей Бельянинов, Евразия һәм Африка халыклары Ассамблеясенең генераль секретаре, – «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVI Халыкара икътисадый форумында:

– Халыклар хөкүмәтләргә караганда тизрәк аңлаша. Халык дипломатиясендә Татарстанның, Казанның һәм инде традициягә әверелгән KazanForumның өлешен һич киметеп булмый: без 110 милләт вәкиле тынычлыкта, дуслыкта һәм татулыкта яши торган республикага килдек. Казан инде күптән халыкара вакыйгалар үзәгенә әйләнде. Барыбыз да әлеге форумда катнашуны зур дәрәҗә дип саныйбыз, чөнки Казан бу яктан караганда үзенчәлекле Мәккәгә әверелде.

Фото: tatar-inform.ru, eurasia-assembly.org, kremlin.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ышаныч **ничек** хезмәттәшлеккә, ә хезмәттәшлек ышанычка әверелә

Метро булмаганда, Казан **ничек** яшәде

Метро төзегәндә, киләчәк буынга хәбәр **ничек** күмеп калдырыла

Җир астында эшләгәндә, **нинди** авырлыкларга юлыгалар

РОССИЯ – ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ:

«РОССИЯ – ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ: KAZANFORUM»

САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

ФОРУМДА

130 килешү һәм меморандум имзаланды, шуларның → **75** халыкара килешү һәм меморандум

148 эшлекле сессия үткәрелде

900 спикер чыгыш ясады

50 Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов форумда үткәргән очрашулар саны

KAZANFORUM:

96 илдән һәм Россиянең **89** төбәгеннән

22 500 катнашучыны җыйды

ФОРУМНЫҢ ТӨП ТЕМАЛАРЫ:

Россия һәм ИХО илләре арасындагы хезмәттәшлекне цифрлаштыру, халыкара хезмәттәшлек, күчемсез милек күргәзмәсе һәм конференциясе, спорт, хәләл индустриясе, ислам финанслары һәм инвестицияләре, туризм, мәдәният, хатын-кыз карашы, бизнес, икътисад, кадрлар бүген һәм иртәгә, фән һәм технологияләр.

150

компания «Казан» агросәнәгать паркы территориясендә оештырылган **KAZAN HALAL MARKET** халыкара сәүдә ярминкәсендә катнашты. Алар Россия, Төркия, Иран, Һиндстан, Пакыстан, Кыргызстан, Казахстан, Әфганстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән килгән иде.

12

ил үз стендларын форум кысаларында оештырылган **RUSSIA HALAL EXPO** халыкара күргәзмәсендә тәкъдим итте. Бу безнең илдә Россия төбәкләре һәм ИХО илләренең икътисадый һәм фәнни-технологик юнәлешләрдәге хезмәттәшлеген чагылдырган иң зур күргәзмә.

МАРАТ ХӨСНУЛЛИН, РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты рәисе:

«Без форумның безнең илгә дә, ислам дөньясы илләренә дә бик кирәк булуын күрәбез. KazanForum ел саен күбрәк даирәләрне үзенә тарта. Быел программа 200дән артык чараны, шул исәптән 990 спикер катнашында 148 эшлекле сессияне үз эченә алды. Форум үзенең нәтиҗәләлегә буенча рекорд куйды: аның мәйданнарында гомуми суммасы 1 млрд сумнан артып киткән 130 килешү һәм меморандум имзаланды, шул исәптән 75е – халыкара дәрәҗәдә».

Фото: tatarstan.ru, tatar-inform.ru

ЫШАНЫЧ ҺӘМ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

XVI ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАДЫЙ ФОРУМЫ

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Рәисе:
«Төрле дин тотучы һәм күпмилләтле халык яши торган Россия Федерациясе өчен ислам дөньясы белән партнёрлык мөнәсәбәтләрен урнаштыру тышкы сәясәттә иң мөһим эш юнәлешләренең берсе булды һәм булып кала бирә. Россия һәм Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләре, үзара файдалы алымнарга таянып, күп кенә глобаль проблемалар буенча актив хезмәттәшлек итәләр, яңа дөнья тәртибен формалаштыруда катнашалар, үз үрнәкләре белән цивилизацияләр өчен конфликтсыз аралашу мөмкин булуын күрсәтәләр».



УЗДЫРЫЛГАН ЧАРАЛАР:

- AAOIFI (ислам финанс институтлары өчен бухгалтер исәбе һәм аудит оешмалары) пленар утырышлары
- «Ислам урбанизацияләнгән мохите» (IBEIS 2025) халыкара симпозиумы
- Халыкара сәүдә-сәнәгать палаталары форумы
- ИХО илләренең XI Казан яшь эшкуарлары форумы
- «Төньяк – Көньяк» халыкара транспорт коридоры утырышы
- Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең мәдәният министрлары съезды

KAZANFORUM КЫСАЛАРЫНДА «РОССИЯ – ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ» СТРАТЕГИК КАРАШ ТӨРКЕМЕ

утырышы узды.
Очрашу яшьләр сәясәте һәм гуманитар өлкәдәге хезмәттәшлек сорауларына багышланган иде. Утырышны Татарстан Республикасы Рәисе, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме рәисе **Рөстәм Миңнеханов** алып барды.

57

компания International Property Market күчемсез милек күргәзмәсендә катнашты. Шулардан

29

төзелеш оешмасы һәм девелопер БГӘ, Азәрбайҗаннан һәм Төркиядән килгән иде. Әлеге уникаль мәйданчык халыкара бәйләнешләрне һәм төрле илләрдәге инвесторлар белән хезмәттәшлекне ныгытырга тиеш.

25 000

кеше «Изге Болгар җыены» форумының соңгы көнендә борынгы Болгар шәһәренә җыелды. Алар Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән иде.

ФОРУМ ВАКЫТЫНДА

10

очрашу оештырылды. Төрле форматтагы чараларда Россия һәм чит ил вәкилләре катнашты. Халыкара хезмәттәшлеккә багышланган «Россия – БГӘ», «Россия – MENA илләре», «Россия – Әфганстан», «Россия – Төркия», «Россия – Малайзия», «Россия – Иран», «Россия – Таҗикстан», «Россия – Казахстан», «Россия – Катар» чаралары уздырылды.

ХАЙ-ТЕК СТИЛЕНДӘГЕ ТАТАР ӘКИЯТЕ

«Ул энергетиканың үзенә охшаган!» – дип соклана Камал театрының яңа бинасына Казан электр челтәренең бүлгәләү челтәрләрен автоматлаштыру бүлеге башлыгы Александр Бурмистров. Аңлатып та китә: бинаның хай-тек стилендәге тышкы кыяфәте чынлап торып татар әкиятенә алып кереп китсә, милли рухлы эчке җиһазлары гаҗәеп рәвештә гармония хасил итә. «Энергетикада да шулай: югары технологияләрне кулланган хәлдә, без ышанычлылык һәм сыйфат традицияләрен саклыйбыз».

Александрның фикере игътибарга лаек. Ул бу объектка «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы вакытында энергетика менеджеры итеп билгеләнә һәм үзенең командасы белән бергә, бу көннәрдә энергетикларның барлыгын берәү дә искә төшермәслек югары кимәлдә хезмәт күрсәтүне тәэмин итеп, электр техникасы җиһазларын карап-күзәтеп тора…

«Челтәр компаниясе» хезмәткәрләре өчен Казанда уза торган зур чараларга хезмәт күрсәтү традициягә әйләнгән. Бу үз карамакларындагы объектларны электр энергиясе белән өзеклекләрсез тәэмин итү буенча бай тәҗрибә туплау мөмкинлеге бирә. Казан һәм тулаем республика өчен әһәмияткә ия булган берничә объект бу форумның эшлекле программасын, шулай ук сателлит чараларын үткәрү өчен мәйданчыклар итеп билгеләнә. Алар арасында «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге, Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ-парк, «Казан» агросәнәгать паркы, Казан Ратушасы, шулай ук Казан, Болгар, Зөя утрау-шәһәре бар.

Бу объектларда компаниянең үз традицияләре буенча «Челтәр компаниясе»нең техник белгечләреннән торган постлар куела. Һәм команда белән энергетика менеджерлары – филиалларның (Казан, Идел буе, Чистай һәм Буа электр челтәрләре – ред. иск.) төрле дәрәҗәдәге структура бүлекчәләре башлыклары җитәкчелек итә. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятеннән барлыгы 300 гә якын кеше җәлеп ителә.

Ислам форумының үзәк мәйданы «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә урнашты. 2019 елда ачылган үзәкнең алыштыргысыз энергетика менеджеры булып Идел буе электр челтәрләренең баш инженер урынбасары Илдар Хәмитов эшли. Үзенең ярдәмчеләре – Шәһәр яны Район электр челтәре башлыгы һәм баш инженеры Дмитрий Шмаков һәм Алмаз Хәмитов белән алар эчке һәм тышкы электр челтәре объектларында электр техникасы җиһазларының эшен контрольдә тоталар, алар дөрес эшләсен өчен даими рәвештә карап торалар. Төрле юнәлешләрдәге үзара хезмәттәшлек буенча сөйләшүләр, инвестиция һәм инфраструктурага караган проектлар, ислам финанслары һәм машина төзелеше буенча төрле инициативалар

Фото «Челтәр компаниясе» АҖ нән алынды. РЕКЛАМА

ИЛШАТ ФӘРДИЕВ, «Челтәр компаниясе» АҖнең генераль директоры:

– Бездә үз һөнәренең чын осталары эшли. Алар үзләренә йөкләнгән җаваплы эшне зур тырышлык белән башкарып чыкты. Безнең уңышның сере дә шушы бердәмлектән гыйбарәт – компания коллективы, Татарстан башкаласында уза торган дөньякүләм чараларны үткәрүдәге күпьеллык тәҗрибәсенә таянып, бердәм оркестр кебек эш итә.

тәкъдим ителгән эшлекле чаралар уза торган территориядә катнашучыларның мөстәкыйль тоташуын контрольдә тота.

Энергетиклар объектның штаттагы хезмәткәрләре белән гел элемтәдә тора. Даими элемтә радио һәм телефон аша тәэмин ителә. Чаралар вакытында җиһазларның мониторингы алып барыла. Бу ихтимал булган штаттан тыш хәлләрне тиз арада төзәтә алу өчен кирәк.

Шулай ук электр энергиясе белән тәэмин итүнең резервтагы чыганаклары да әзерләнә. Алар өчен җаваплы затлар белән дә тыгыз элемтә урнаштырыла. Бу җәһәттән «Челтәр компаниясе» белгечләренең осталыгына сокланырлык – вакытлыча стационар электр челтәрләренә тоташтырыла торган дизель-генератор җайланмаларының эшен алар 2013 елгы Универсиада һәм Сочидагы 2014 елгы Олимпиададан бирле карап, тәртиптә тоталар.

Күргәзмә комплексын электр энергиясе белән тәэмин итә торган трансформатор станцияләрендә кизү торган өч хезмәткәрнең дә тәҗрибәсе зур. Аларның иң яше – Идел буе электр челтәрләренең Шәһәр яны Район электр челтәре монтёры Илназ Шәйдуллин. Энергетика системасында эшләү тәҗрибәсе буенча ул 2019 елда ачылган «Казан Экспо» үзәгенә яшьтәш – бу объект аның биографиясендә мөһим роль уйный: хезмәт юлын ул шушында кизү торудан башлаган.

Электр җайланмаларын эчке һәм тышкы электр энергиясе белән тәэмин итү эшләренә методологик һәм техник контрольлек итү буенча эксперт ярдәме тагын бер яңа объектта – «Казан» агросәнәгать паркында оештырыла. Биредә Kazan Halal Market халыкара сәүдә ярминкәсе үтә. Бу җәһәттән объектларның милек хуҗалары белән үзара хезмәттәшлекнең җайга салынган булуы аеруча мөһим роль уйный. Нәтиҗә – халыкара статуска ия булган чараның уңышлы узуы да уртак җаваплылыктан тора.

АЙРАТ ШӘРӘФИЕВ, Көнчыгыш Район электр челтәренең баш инженеры, «Казан» агросәнәгать паркының энергетика менеджеры:

– Объектның штаттагы хезмәткәрләре белән берлектә электр җайланмаларын алдан тикшереп чыктык, җитешсезлекләрне ачыкладык, аларны бергәләп төзәттек. Димәк, энергетик энергетикны әллә кайдан күрә диган сүз!

Тәүлек әйләнәсенә кизү торучы постлар форум объектларын тәэмин итә торган югары класслы киеренкелек подстанцияләренә дә куела. Чакрымнарга сузылган электр чыбыклары комплексны электр энергиясе белән тәэмин итә. Алар шулай ук югары вольтлы чыбыклар хезмәте хезмәткәрләренең даими контролендә тора. Объектларны электр белән тәэмин итүдә катнаша торган оешмаларның эшен «Челтәр компаниясе» АҖ Идарә аппаратының тәҗрибәле җитәкчелеге вәкилләре кизү торган баш операцияләр үзәге (ГОЦ) һәм составына ТР энергетика системасы предприятиеләре белгечләре кергән төбәк оператив штабы координацияли. Алар электр энергиясе белән ышанычлы тәэмин итүне оештыра.

Шул рәвешле форум көннәрендә «Челтәр компаниясе» хезмәткәрләренең бердәм һәм тырыш хезмәте энергетикларның «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» форумын уңышлы үткәрүгә керткән һөнәри өлеше булып тора. Компания Россия һәм ислам дөньясы илләренең үзара аралашуы һәм хезмәттәшлеге өчен мөһим булган мәйданда үзенең абруйлы исемен тагын бер тапкыр раслады.

ИЛНАЗ ШӘЙДУЛЛИН, Идел буе электр челтәрләренең Шәһәр яны Район электр челтәре монтёры:

– Әлеге трансформатор подстанциясен без көн саен карап торабыз, әмма хәзер контроль тагын да көчлерәк – сәгать саен тикшереп чыгабыз, чөнки җиһазларга зыян килсә, авария килеп чыгу ихтималы бар.



СӨТ ТАРМАГЫНДА ЯСАЛМА ФӘҺЕМ

Россиянең бер генә төбәге дә сөт җитештерү күләме буенча Татарстан белән чагыштырырлык түгел – узган ел 2,3 миллион тонна сөт савып алынган. Бу рекордлы сан, әмма республикада инде яңа кыю планнар коралар. Максат – 2030 елга сөт җитештерүне 2,6 миллион тоннага җиткерү. Фантастикамы? Чынбарлык, әгәр заманча технологияләргә таянсак.

Баштa саннарга күз салыйк. Соңгы биш ел дәвамында республикада сөт җитештерү тотрыклы рәвештә арта бара, нәтиҗәдә 2020–2024 елларда үсеш 17,5% тәшкил итте. 2030 елга планлаштырылган 2,6 миллион тоннага җиту өчен тагын 12,5% ка үсәргә кирәк. Узган ел Татарстан Республикасында мөгезле эре терлекләрнең продуктлылыгы бер сыердан якынча 8,4 мең тонна тәшкил иткән. 2030 елга, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы фаразлары буенча, ул 10 мең тонна булырга тиеш.

Димәк, билгеләнгән күрсәткечкә ирешү өчен, савым сыерларын елына биш мең башка күбәйтергә һәм, бер үк вакытта савым күләмен арттырып, сөт җитештерү темпларын өч-дүрт процентка күтәрергә кирәк. Бу бер сыердан уртача 300–500 килограмм сөт савыла дигән сүз. Авыл халкының кими баруын исәпкә алсак, бу бурыч катлаулыдан хәл ителмәгәннәр рәтенә җиңел генә күчә ала. Бәхеткә, заманча үсеш драйверларын акыл белән гамәлгә керткәндә, алар аграр җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттырырга сәләтле. Тармакны цифрлы трансформацияләү, технологик процессларны автоматлаштыру – күп елларга алга җибәрерлек үсешнең реаль мөмкинлекләре. Һәм бу ерак киләчәк программасы түгел, аны Татарстанда эзлекле рәвештә гамәлгә ашыралар.

ФЕРМАДА ТӘРТИПНЕ ВИДЕОКОНТРОЛЬ САКЛЫЙ

Татарстандагы фермер хуҗалыкларының берсе. Гадәтие түгел. Сыерны саву процессын монда цифрлы ярдәмче тикшереп тора. Видеосистема операторның нәрсә эшләгәнен күзәтә. Ялгыш була кал-

Фото: илкулэм проектлар.рф, РМИУ тарафыннан тәкъдим ителде, agro.tatarstan.ru

са, аны терки һәм, алынган мәгълүматны анализлап, хатаны тиз арада төзәтергә булыша торган киңәшләрен бирә. Нәтиҗәдә сөт җитештерү өчтән бер өлешкә диярлек арта. Шул ук цифрлы ярдәмче терлекләрнең авыруларын киметергә һәм продукциянең сыйфатын күтәрергә мөмкинлек бирә.

Бүген әлеге яңа ысул Татарстанның җиде фермер хуҗалыгында кулланыла. Сыер саву процессын цифрлы технологияләр ярдәмендә контрольдә тоту (аңа һәр мөгезле эре терлек буенча көнлек савымны, персоналның эшен исәпкә алу һәм көтү белән идарә итү турындагы аналитик мәгълүмат керә) акрынлап гадәти хәлгә әверелә бара.

Аңлашыла ки, әгәр сүз чит ил системалары һәм программа тәэминаты турында барса, цифрлы технология кертү шактый акча таләп итә. Шуңа күрә фермерлар еш кына элеккеге технологияләрне һәм кул хезмәтен кулланып эш итә – шулай арзанрак. Әмма бүген савымның артуын, продуктның сыйфатын яхшыруны тәэмин итәргә сәләтле үзебезнең продуктлар барлыкка килә башлады. Аларны куллану чыгымнарның күпкә артып акланачагына дәлилли.

Татарстан фермерларына бу җәһәттән уңай туры килде. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге (РМИҮ) белгечләре тарафыннан көтү белән идарә итү буенча үзебезнең цифрлы технология эшләнде. Шуңа күрә әлеге технологияне кулай бәядән генә республикада тарату мөмкинлеге булды. Быел, мәсәлән, РМИҮ Татарстан Республикасында без сөйләгәнгә охшаш тагын 17 проектны гамәлгә ашырырга ниятли. Татарстан эшләнмәләре белән кызыксыну зур. Димәк, киләчәктә алар Россиянең башка төбәкләренә дә таралырга мөмкин.

Цифрлы технологияләр безнең заманда экзотика түгел, көндәлек ихтыяҗ. Алардан башка аграр өлкәдә, аерым алганда, терлекчелектә җитештерүне алга таба үстерү мөмкин түгел.

– Цифрлы технологияләрдән файдалану фермаларда идарә итү процессларын оптимальләштерергә ярдәм итә. Бу икътисадый нәтиҗәлелекне арттыра һәм хезмәткәрләр өчен хезмәт шартларын яхшырта, – дип искә төшерде май аенда Минзәләдә терлекчелек буенча узган зона семинар-киңәшмәсендә ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров. – Агросектордагы инновацияләр авыл хуҗалыгын үстерү өчен яңа мөмкинлекләр ача, аны эчке һәм тышкы базарларда тотрыклырак һәм конкурентлыкка сәләтлерәк итә.

Сөтчелек терлекчелегенә алдынгы мәгълүмати технологияләрне кертү үсешнең мөһим ноктасы булуын ассызыклап, министр көтү белән идарә итү программасын гамәлгә кертүнең нинди нәтиҗә бирәчәген үз күзләрең белән күрү өчен конкрет адресларның берсен дә атады. Бу – Кукмара районыннан Римма Таҗмиеваның крестьян (фермер) хуҗалыгы. Цифрлаштыру хуҗалыкка сөт җитештерүне арттырырга һәм финанс күрсәткечләрен сизелерлек арттырырга мөмкинлек биргән. Әлеге тәҗрибә аграр секторны үстерүдә заманча технологияләрнең нәтиҗәлелеген раслый. Бу «Белешмәләр икътисады һәм дәүләтнең цифрлы трансформациясе» илкүләм проектының максатларына һәм бурычларына туры килә.

СӨТЛЕБИКӘНЕҢ «ЭЛЕКТРОН ПАСПОРТЫ»

Әтнә районы, «Тукай» ҖЧҖ сөт комплексы. Май башында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм ТР вице-премьеры Марат Җәббаров бу комплекста булып киттеләр. Аларның тыгыз эш графигында әлеге сәфәр өчен вакыт табылды. Әлбәттә, очраклы түгел. 2400 баш сыерга исәпләнгән саллы комплекс республикада иң зурысы түгел, әмма инновацияле технологияләр буенча – чын мәгънәсендә алдынгы тәҗрибә мәктәбе.

«Тукай»да 114 кеше эшли. Дүрт сыер абзары, бозаулату бүлеге, сөт бозаулары өчен махсус бокслар, тәүлегенә 70 тонна моноазык җитештерә алырлык үз азык цехы һәм, әлбәттә, төп «фишкаларның» берсе – «карусель» тибындагы саву залы бар. Анда сыерларга роботлар хезмәт күрсәтә. Хәер, «карусель» дә, эре терлекчелек фермаларында роботлар да бүген сирәк түгел. Әмма монда телгә алынган сыер саву «каруселе» – савым сыерларының максималь продуктлылыгын тәэмин итә торган системаның бер өлеше генә.

«Тукай»да кулланыла торган көтү белән идарә итү программасы белгечләргә тиз арада терлекләр турында объектив мәгълүмат бирә – уртагын да, һәрберсе буенча аерымын да. Ясалма фәһем бер сыерны икенчесеннән ничек аера соң? Монда барысы да гади: һәркайсының үз датчигы – «электрон паспорты» бар. Саву залына кергәч, сыерны тәңгәлләштерәләр. Шуңа күрә оператор хәзерге вакытта кайсы сыерның савылачагын һәм «карусель»дә кайсы урынга басачагын күрә...

НИЯЗ ХӘЛИУЛЛИН,
РМИҮ АҖ генераль директоры:

– ХЕЗМӘТ ҖИТЕШТЕРҮЧӘНЛЕГЕ ШАКТЫЙ ТҮБӘН БУЛГАН АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА ЦИФРЛЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН ЯСАЛМА ФӘҺЕМ ДӘ, КЕШЕСЕЗ ЭШЛӘТҮНЕ КӨЧӘЙТЕРГӘ, ТИЗЛӘТЕРГӘ, КАЙДАДЫР ХӘТТА ТУЛЫЛАНДЫРЫРГА МӨМКИНЛЕК БИРӘ. ТӨБӘКТӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ПРОЕКТЛАРНЫ АНАЛИЗЛАУ НИГЕЗЕНДӘ БЕЗ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕҢ ХУҖАЛЫКЛАРГА НИНДИ ИКЪТИСАДЫЙ ФАЙДА КИТЕРӘ АЛУЫН, АЛАРГА БУЛГАН ИХТЫЯҖНЫ КҮРӘБЕЗ ҺӘМ ЦИФРЛАШТЫРУГА БАСЫМ ЯСЫЙБЫЗ.

Һәр сыердан савылган сөт күләме һәм сыйфаты, малның актив һәм тыныч вакыты, сәламәтлегенең торышы (кирәк булса – диагнозы) – болар барысы да теркәлеп кенә калмый, ә бәлки операторга, ферма мөдиренә, зоотехникка, ветеринария табибларына уйлану, ниндидер карар кабул итү өчен нигез бирә. Тупланган мәгълүматка таянып, программа башкарылырга тиешле эшләр исемлеген, аларның оптималь срокларын билгели.

Әйтергә кирәк, «Тукай»да тупланган тәҗрибәне җиде йозак астында тотмыйлар. Күптән түгел биредә семинар узды. Анда хуҗалык җитәкчесе Илфат Хәкимов коллегаларына заманча технологияләр, ясалма фәһем белән берләштерелгән цифрлаштыруның, процессларны автоматлаштыруның нинди нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирүе турында сөйләде.

«САУБОЗАУ»НЫ ЧАКЫРДЫГЫЗМЫ?

Ясалма фәһемнең төрле өлкә белгечләренә шактый җитди ярдәмче була алуына бүген беркем дә шикләнми. Ул терлекчелектә дә эзлекле рәвештә үз урынын яулый бара. Моның өчен һөнәри туры килүгә җитди сынау үткәрәләр. Әлеге сынауны, мәсәлән, «СауБозау» ясалма фәһем ассистентына да үтәргә туры килде. Аңа сөтчелек терлекчелеге өлкәсендәге белемнәрен ветеринария академиясе галимнәре каршында якларга туры килде.

«СауБозау» ЯФ ассистенты өчен аны уйлап табучыларга кызарырга туры килмәде. Казан ветеринария медицинасы академиясендә сөтчелек терлекчелеге юнәлеше буенча барлык биремнәрне үтәп, ясалма фәһем тестны уңышлы башкарды. Шуңа күрә хәзер аның «Ветеринария һәм зоотехния» белгечлеге буенча компетентлыгы рәсми дәрәҗәдә расланды.

Шикләнергә урын юк, чөнки академия профессорлары һәм мөгаллимнәреннән торган комиссия ЯФнең белемен 48 тест мәсьәләсе һәм бер ачык бирем буенча бәяләде. Темалар төрледән-төрле – сөт сыерларын тукландырудан алып авыруларны диагностикалауга кадәр. Сөтчелек терлекчелеген алып баруның практик юнәлешләренә аерым игътибар бирелде.

Ассистент GigaChat зур тел моделе базасында Саклык банкы һәм «Эвотор» командалары тарафыннан Телеграмда бушлай чат-бот формасында түбәндәге сылтама буенча төзелгән: https://t.me/MooMentor_Bot. «СауБозау» инде ай саен 16 меңнән артык кулланучыга булыша һәм актив рәвештә үсүен дәвам итә.

– Казан ветеринария медицинасы академиясе экспертлары ярдәмендә ЯФ ассистенты фермерларга сөт терлекчелеге буенча максималь төгәл һәм файдалы киңәшләр тәкъдим итү өчен белем базасын даими киңәйтә һәм эш алгоритмнарын камилләштерә, – дип билгеләп үтә Саклык банкының Идел-Нократ банкы рәисе Александр Анащенко.

«Н. Э. Бауман исемендәге Казан ветеринария медицинасы академиясе» Институты директоры Рөстәм Равилов сүзләренә караганда, «СауБозау» ясалма фәһем буенча эксперимент кына түгел, ул – авыл хуҗалыгына ветеринария ярдәме күрсәтүнең киләчәге дә.

– Саклык банкы белән хезмәттәшлек нәтиҗәсендә без укытучыларыбызның күпьеллык тәҗрибәсен цифрлаштыра алдык һәм аны һәр терлекченең кесәсенә салдык, дияргә була. Хәзер хәтта бик ерак районнарда яңа гына эшли башлаган фермер да академия профессоры дәрәҗәсендәге киңәшне ала ала! Бу бит чын революция! – ди Рөстәм Равилов.

– Тестны уңышлы эшләү авыл хуҗалыгында ясалма фәһемнең

гаять зур куәтен күрсәтә. Ассистент дистәләгән мең фермер өчен алыштыргысыз ярдәмче була ала, бигрәк тә ветеринария белгечләре җитмәү сизелә торган ерак районнарда. Бу проект акыллы ассистентларның тулы бер гаиләсен булдыру юнәлешендә беренче адым булачак, – дип дип сөйли Саклык банкының «Татарстан Банкы» бүлекчәсе идарәчесе Руслан Сәлимов.

АГРОФЕРМАДАГЫ ЦИФРЛЫ ЯРДӘМЧЕЛӘР

Татарстанның Яшел Үзән районындагы «Светлое озеро» агрофермасы җитәкчесе Татьяна Кированы җитештерүдә ИТ-чишелешләр кертүдә пионер дип атап булмый. Аның ныклы фикере шундый: терлек-туар һәм кош-кортларның һәрберсенә аерым якын килергә кирәк, аларны тоту да табигый шартларга максималь яраклашкан булырга тиеш. Бер уйлап караганда, мондый позиция «цифрлар» кертүне, процессларны автоматлаштыруны кире кага кебек.

Ничек кенә булмасын, баштарак агрофирмадагы барлык эшләрне кул режимында планлаштырганнар, җитештерү чыгымнарын һәм күләмнәрен кәгазьгә теркәгәннәр, алыш-бирешләр турында мессенджерларда килешкәннәр, хезмәттәшләре белән дә шунда киңәшкәннәр. Әмма хәбәрләр югала, ә язмалар буенча нәрсәне булса да структурлау, анализлау, карарлар кабул итү катлаулы була башлый. Шуннан соң «цифр»га мөрәҗәгать итәргә туры килде, ди Татьяна Кирова.

– Беренче эш итеп без хайваннар һәм кошларны тоту, хезмәткәрләрнең эш урыннарына, территориягә керү-чыгу юлларына видеокүзәтү системасын урнаштырдык, – дип сөйли Татьяна. – Бу эш процессларын контрольгә алырга һәм төрле ситуацияләргә тиз арада җавап бирергә мөмкинлек бирде. Хәзер территориягә бары тик оператор рөхсәте буенча телеграм-бот аша гына керергә мөмкин: шлагбаум аша узганда автомобиль номерын теркәгән контроль видео җибәрелә. Вакыт релесы яктырту һәм вентиляция системасы белән идарә итә, шуның белән терлекчелек биналарында көн озынлыгын һәм микроклиматны тикшереп тора.

Әйе, хуҗаларның терлек-туарны һәм кош-кортны үстерүгә аерым якын килүе фермада барлык эш процессларын автоматлаштырырга мөмкинлек бирми, әмма продукцияне эшкәрткәндә, сыр һәм деликатеслар җитештергәндә «Светлое озеро» заманча технологияләрне актив кертә. Автомат сыр кайнату һәм сыр өлгертү камералары, шулай ук салкын һәм кайнар ысул белән ыслау термокамералары җитештерүчәнлекне сизелерлек арттырырга, хезмәт чыгымнарын киметергә һәм продукциянең сыйфатын күтәрергә мөмкинлек бирә. Аерым алганда, автомат камера сырны өлгертү өчен идеаль шартлар тәэмин итә: температура, дымлылык һәм вентиляция – барысы да дөрес көйләнгән. Нәтиҗәдә югалтулар кими, керем арта, сыр, өлгереп, үзләренең уникаль тәменә, структурасына һәм хуш исенә ия була.

Хәзер Татьяна Кированы һәм аның хезмәттәшләрен цифрлы трансформациянең файда китерүенә ышандырырга кирәкми: аның өстенлекләрен һәм чиксез мөмкинлекләрен алар үз тәҗрибәләрендә аңлаганнар.

– Хәзерге фермер өчен агросәнәгать комплексын цифрлаштыру нәтиҗәлелеккә тәңгәл дияргә була: «цифр» җитештерү процессын тикшереп торуны җиңеләйтә, хисап бирүдә һәм башка эшләрдә булыша, – ди фермер хуҗалыгы җитәкчесе. – Дөнья трендлары итнең, сөтнең килеп чыгышын цифрлаштыруга, аларның ничек табылуын, малның ничек үстерелүен белүгә юнәлдерелгән. Россия дә әле юлдан бара. Һәм без республиканың агросәнәгать комплексын цифрлаштыруда алдынгы урында булуын теләр идек, моның өчен бөтен алшартлар да бар.

Хуҗалыкның планнарында – терлекләрнең баш санын һәм җитештерү күләмнәрен, сатуларны арттыру. Шул исәптән Россельхозбанкның «Своё Фермерство» экоплатформасын, уңайлы һәм, иң мөһиме, түләүсез цифрлы сервисларны кулланып та.

P.S. Яшел Үзәндәге фермер хуҗалыгы җитәкчесенең агросәнәгать комплексын цифрлаштыруда республикабыз алдынгы урында булсын дигән теләген тормышка ашкан факт дип санарга була. Мартта Хөкүмәт сәгате вакытында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Патрушев авыл хуҗалыгында цифрлаштыру буенча алдынгы төбәкләрне атады. Бу – Татарстан Республикасы, Ямал-Ненец автономияле округы һәм Кострома өлкәсе (цифрлы трансформация дәрәҗәсе буенча төбәкләр рейтингын ел саен Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы төзи – ред. иск.). Вице-премьер сүзләренә караганда, Россиядә эшләнгән цифрлы технологияләр функционалы буенча чит илнекеләрдән өстенрәк, шул ук вакытта арзанрак тора. «Алдынгы технологияләрне куллану тулаем алганда мәшгульлек структурасын үзгәртә. Без түбән квалификацияле хезмәткә ихтыяҗ кимүен күрәбез. Һәм киресенчә, киң компетенцияле һәм экспертизага ия белгечләргә тотрыклы ихтыяҗ формалаша», – дип йомгаклады сүзен Дмитрий Патрушев.

«КЫРЛАЙ» АГРОФИРМАСЫ: ЯХШЫ УҢЫШКА ӨМЕТ ЗУР

Руфия Фазылова

Арча районының Кырлай авылын ишетмәгән кеше юктыр. Тик соңгы елларда Кырлай дигәч, Тукай иҗаты белән бергә... бәрәңге дә килеп баса. Ни өчен дигәндә, Татарстанда җитештерелә торган икенче икмәкнең 60 процентын биредә үстерәләр. Шулай ук яшелчә культуралары да утырталар. Быел исә күпләп җитен чәчкәннәр.

Сүзебез гел яңалыкка омтылучы «Кырлай» агрофирмасы турында.

Генераль директор Марат Кәримов.

БӘРӘҢГЕГӘ ИХТЫЯҖ АРТТЫ...

Авыл кешесе җиңел сулап куйды, чөнки язгы кыр эшләре тәмамланды. «Кырлай» агрофирмасы да искәрмә түгел: көнне төнгә ялгаган чаклар артта калды, дип сөенәләр монда да. Бәрәңге утырту май азагында тәмамланган.

– Быел авыл хуҗалыгы өчен яз бик яхшы килде, – диде «Кырлай» агрофирмасының баш агрономы Рәмис Абдрахманов. – Көзге уҗымнар бик яхшы кышлады. Бәрәңге утырту өчен дә шартлар кулай булды. Икенче икмәкне утыртырга 19 майда чыктык. Салкын җиргә салып куюдан барыбер мәгънә юк, тишелми. Һәм уңыш та түбән була. Моңа инде ничә кат инандык. Быел дым күп, мондый шартларда бәрәңге атна-ун көн эчендә тишелә.

«Кырлай» агрофирмасында узган ел икенче икмәкне 1200 гектар җирдә утыртканнар. Быел исә 1346 гектар иткәннәр. Сәбәбе бик гади: ихтыяҗ бар.

– Быел бәрәңге урынына үзебезне дә төяп алып китә яздылар, – дип көлде Рәмис Абдрахманов. – Мондый ажиотажны 2010 елдан бирле хәтерләмим. Көзен бәрәңгене 20 сумнан сатсак, язын 47 сумнан озаттык. Әле җитмәде дә. Шуның өчен быел бәрәңгене күбрәк гектарга утыртырга карар кылдык. Көзгә дә шул хәл кабатланырга мөмкин. Читтән бәрәңге кертү кимегән, шуның өчен дә сорау арткан. Әлбәттә, бу безнең өчен файда гына.

Агрофирмада узган ел уңыш бик әйбәт булган: гектарыннан 400 центнер икенче икмәк җыеп алганнар (2023 елда – 251 центнер). Барлыгы 48 мең тонна бәрәңге уңышы җыелган. Биредә басулар су сибү агрегатлары белән җиһазландырылган. Соңгы елларда җәйләр нык эссе була, шуның өчен дә су сипмичә булмый икән.

– Су сибү агрегатлары төрле, – диде агроном. – Совет чорындагы кебекләре дә, чит илдән кайтарылганнары да бар. Әлбәттә, соңгылары бик көчле: бер урыннан икенче урынга күчереп йөртеп була. 1350 гектар җирне сугару мөмкинлеген бирә. Шулай булгач, коры елны да уңышсыз калмыйбыз.

«ЯШЕЛЧӘЛӘРНЕ КЫШКА КАЛДЫРМЫЙБЫЗ»

«Кырлай» агрофирмасында бәрәңгедән кала чөгендер, кишер кебек яшелчә культуралары да утырталар. Быел аларын да арттырганнар: узган ел 90 гектар азык чөгендере булса, хәзер аны 120 гек-

Фотолар «Кырлай» агрофирмасыннан алынды. РЕКЛАМА

тар чәчкәннәр, кишер исә 20 гектарда үсәчәк. Узган ел 10 гектар булган.

– Гадәттә, кишер белән чөгендер яңа елга кадәр сатылып бетә, – дип дәвам итте Рәмис Абдрахманов. – Яңа елдан соң аларның сыйфаты төшә, сакларга авыр.

– Чөгендер, кишергә караганда, бәрәңге үстерү кыйммәткәрәк чыгамы? – дим.

– Әлбәттә, кишер белән чөгендерне ике тапкыр эшкәртәсең, бәрәңгегә җидешәр тапкыр техника керә: чүбен утыйсың, ашлыйсың, агулыйсың. Быелгы кебек бәрәңгегә югары бәя сирәк була. Ун-унике сумга саткан чаклар да булды.

Агрофирманың 37 мең тонна яшелчә сыя торган базлары бар. Ләкин киләсе сезонга 10 мең тонна яшелчә сыйдырышлы яңа подвал салырга ниятлиләр.

– Мәйданны арттыргач, яшелчәләрне сакларга урын да кирәк бит, – дип дәвам итте агроном. – Әлбәттә, без уңышның күпчелек өлешен көзге ярминкәләрдә сатабыз, зур йөк машиналары белән шәхси эшмәкәрләр дә килеп ала. Ләкин язга да кала ул. Менә быел язын бәрәңге сату ничек отышлы булды. Шулай булгач, ел белән ел туры килми.

«Татарстан» журналы фермерлар турында еш яза. Һәм шуңа инандык: быелгы чәчү чорын аеруча дулкынланып көтте алар, бигрәк тә вак фермерлар. Техника, ягулыкка якын килә торган түгел, кыйммәт. Ә игеннең бәясе инде кайсы еллардан бирле түбән кала бирә. «Кырлай» агрофирмасында исә зарланмадылар:

– Язгы чәчү алдыннан ел саен бертөрле дулкынлану булып ала ул, – диде Рәмис Абдрахманов. – Ләкин бу тармакта күптән эшләгәч, ныклы элемтәләребез бар. Мисал өчен, ягулыкны литрын 49–50 сумнан, кичектереп түләү юлы белән алдык. Даими клиентлары булгач, бәрәңге орлыгына да ташлама ясадылар. Ел саен ничектер җае чыга аның.

«КЫРЛАЙ» АГРОФИРМАСЫ КАРАМАГЫНДА БҮГЕН 10732 ГЕКТАР ҖИР БАР. АГРОФИРМА АРЧА РАЙОНЫНЫҢ УН АВЫЛЫНДА ЭШЛИ. ХУҖАЛЫКТА 142 КЕШЕ ХЕЗМӘТ КУЯ. СЕЗОН ВАКЫТЫНДА КЕШЕ САНЫ ТАГЫН ДА АРТА.

РАПС УРЫНЫНА – ҖИТЕН

Җәй җитте исә, умартачылар чаң кага: рапска сипкән агу аркасында бал кортлары үлә. Бу проблема турында республика җитәкчелеге югарылыгында да сөйләшенде, әмма ел саен бер үк хәл кабатлана. «Кырлай» агрофирмасына да әлеге проблема таныш. Шуның өчен дә быел алар рапс культурасыннан баш тарткан. Югыйсә агрофирманың үзендә рапс мае ясый торган мини-завод та бар.

– Завод өчен рапсны сатып алачакбыз, – диде «Кырлай» агрофирмасының генераль директоры Марат Габделхәй улы Кәримов. – Узган ел 700 гектарда рапс чәчтек. Тик, дөресен әйтим, үз бәясен капламый ул. Рапсны үстерү чыгымлы, күп ашлама сорый, бөҗәкләргә каршы тору өчен кыйммәтле агулар сибәргә кирәк. Нәтиҗәдә, сатып алу бәясе кыйммәт булса да, рапс чыгымлы культурага әйләнә. Аннары, умартачылар да тыныч булачак: кортлар үлмәячәк.

Рапстан аермалы буларак, җитенне агуларга кирәкми, чөнки аңа кортлар килми. Шулай итеп, быел агрофирманың 500 гектар җирендә җитен һәм 240 гектарда көнбагыш үсәчәк.

– Игенгә караганда да җитен, көнбагыш үстерү отышлымы? – дип сорыйм җитәкчедән.

– Әйе, отышлы. Соңгы елларда игенгә бәя гел түбән, ә җитен, рапс, көнбагышка – югары.

ТӨЗЕЛЕШСЕЗ БУЛМЫЙ

«Кырлай» агрофирмасы иген дә үстерә, 600 гектарга – арыш, 600 гектарга бодай чәчкәннәр. Шунсыз булмый – хуҗалыкның икенче юнәлеше терлекчелек һәм сөтчелек. Димәк, беренче чиратта иген кирәк. Агрофирмада мөгезле эре терлек саны – 2 724 баш. Ләкин әле ниятләр зурдан...

Марат Габделхәй улы безне Арча районының Иске Иябаш авылындагы мегафермага алып барды. 1800 баш терлек сыйдырышлы заманча бина бу. Шуңа өстәп янә 600 баш терлеккә исәпләнгән яңа ферма төзелеп ята. Көзгә инде эшләп бетерергә планлаштыралар.

– Бүген мегафермада 1010 баш савым сыеры бар, – диде җитәкче. – Быел сөткә бәя яхшы булды, шуның өчен дә сөтчелек тармагын үстерергә карар кылдык. Хәзер бит барысы да автоматлашкан, баш санын арттырудан куркасы түгел. Сыерлар да нәселле, бер сөтлебикә тәүлегенә утыз литрдан артык сөт бирә.

Ләкин төзелешләр шуның белән генә бетми. Биредә әле зур, заманча гараж да салалар. Техника күп, һәм ул ел саен диярлек яңартылып тора. Бер ел эчендә генә дә лизингка яңа комбайн, трактор, кукуруз чәчкече, салам пресслый торган җайланма кайткан. Ә аларны саклар өчен яхшы шартлар кирәк.

...Атаклы нәсел дәвамчысы Марат Кәримовка алдан күрү, тоемлау кебек сыйфатлар хас. Бүген «Кырлай» агрофирмасы иң заманча технологияләр белән эшләүче хуҗалыкларның берсе. Күрсәткечләр буенча районда беренче өчлектән төшкәннәре юк. Алга таба да шул югарылыктан төшмәсләр кебек, чөнки моның өчен бөтен шартлар да бар биредә.

ТЕХНИКАҺӘРВАКЫТ БАР!

ПРОМИНТЕЛ АГРО

«Проминтел-Агро» ҖЧҖ

Казан ш., Хезмәт тыкрыгы, 22

Филиаллары: Яр Чаллы ш., Чистай ш., Буа ш., Ижевск ш.,

+7 (843) 221-95-20

www.promintel-agro.ru

@AGROSRV

@PROMINTELAGRO

РЕКЛАМА

агро
волга
2025

Ха лыкар а агро СӘНӘГать күр гӘЗМӘСе 9-11 июль «к азан Экспо» Хкү

Эшлекле форумнар

«трактор-шоу»

токымлы хайваннар конкурсы

AgroFoodFest

а выз итеп карау

Павильоннардагы экспозицияләр

а чык мәйданчыклар

кырларда демонстрация

техника күрсәтү

а сфальттагы мәйданчыклар

Сезнең өчен халыкара хезмәттәшлекне көйләү, продукцияне тәкъдим итү һәм тәҗрибә уртаклашу мөмкинлеге

agrovolga.org

12+

ЭШ № NH3/2022:

АГРОХИМИЯ БАЗАРЫ ЛИДЕРЛАРЫННАН БЕРСЕНЕҢ УҢЫШЫН ТИКШЕРУ

Досье

Исеме: ЭльбрусАгро
Сайт: elbrusagroltd.ru
Телефоны: 8-800-222-72-12
Урнашу урыны: Воронеж өлкәсе, Яңа Усман районы, Нечаевка авылы, Рубежная ур., 39 нчы йорт, офис I-I0
Базарга чыгу вакыты: 2022 ел
Компания штаты: I30 дан артык профессионал
Көчле яклары: базарда ышанычлы һәм мөһим уенчы
Компаниянең төп лидерлары: генераль директор Сбродов Станислав Николаевич, техник директор Буравлев Дмитрий Викторович

Шәхси эш 00I

Исеме: Станислав
Әтисенең исеме: Николаевич
Фамилиясе: Сбродов
Гаилә хәле: өйләнгән
Тибы/характеры: нордик, сабыр
Эш тәҗрибәсе: һөнәри юлындагы беренче адымнары белем һәм күнекмәләр генә түгел, ә зур тырышлык һәм даими үсешкә омтылу да таләп иткән. Бу чорда ул чын профессионал-җитәкче сыйфатларын – максималь концентрация һәм фидакарьлек сәләтен үстерүгә ирешкән. Хәзерге вакытта генераль директор вазыйфасында, барлык хезмәтләр белән нәтиҗәле идарә итү һәм аларны координацияләү системасын төзегән. Консерватор түгел, компания эшчәнлегенең теләсә кайсы өлкәсендә яңа технологияләр куллануга риза. Югары дәрәҗәдәге визионерлык сәләте хас.
Көчле яклары: уникаль сыйфатлар җыелмасына ия: А) җиңел генә ышаныч яулый ала; Б) иң таләпчән партнерлар һәм клиентлар белән дә элемтә урнаштыра һәм уртак тел таба белә; В) авыл хуҗалыгы тармагындагы белемнәренең киң теоретик һәм практик багажы белән ныгытылган ышандыру сәләтенә ия; Г) командaны рухландырырга һәм үз артыннан зур коллективларны алып барырга сәләтле. Ачык чагылып торган стратегик фикерләү осталыгына ия, бу аңа оешмадагы барлык эшләрдән хәбәрдар булырга комачауламый.
Игътибар/кисәтү: бик куркыныч, идеологик яктан нык, вербовкага бирелми

Шәхси эш 002

Исеме: Дмитрий
Әтисенең исеме: Викторович
Фамилиясе: Буравлев
Гаилә хәле: өйләнгән
Тибы/характеры: кырыс
Көчле яклары: үз эшенең чын остасы, авыл хуҗалыгы техникасын һәм сусыз аммиак кертү технологиясен биш бармагыдай белә. Стандарт булмаган фикерләү сәләтенә ия, белеме һәм сәләте аны үз өлкәсендә төп белгечкә әйләндерә. Бурычларны хәл иткәндә тиңсез ысуллар куллануы һәм процессларны тирәнтен аңлавы аркасында иң катлаулы хәлләрне нәтиҗәле хәл итеп, башкарып чыга һәм һәрвакыт оригиналь чишү юлларын таба. Корыч маркасын исеннән генә дә аера ала, күзләрен йомган килеш теләсә нинди төрдәге техниканы сүтеп җыярга сәләтле.
Игътибар/кисәтү: кулда М8 ачкычы гына булса да, бик куркыныч; каядыр тиз күчеп китү (телепортация – әлегә тәгәл түгел, эшләнә) турында белемнәргә ия

Фотолар «ЭльбрусАгро» ЖЧҖ алынды. РЕКЛАМА

Махсус хезмәтләрнең яшерен архивларында үзенчәлекле папка барлыкка килде. Күзәтү объекты – сусыз аммиак кертү хезмәте күрсәтә торган «ЭльбрусАгро» ЖЧЖ. Бу компаниянең эшчәнлекне актив киңәйтүе югары квалификацияле разведка белгечләренең игътибарын җәлеп итте. «Аммиак уңышы» дип яшерен исем бирелгән операция башланды. Тикшерү барышында алынган материалларның һәм документларның бер өлеше, архивлар ачылып, җәмәгатьчелеккә билгеле булды.

Эш 003

Исеме: Партнерлар һәм бизнеста союздашлар
Кыскача исемлек: «Агротех-Гарант» компанияләр төркеме, «АГРОЭКО» компанияләр төркеме, «Раненбург» ЖЧЖ, «Мираторг» компанияләр төркеме, «ПРОДИМЕКС-АГРО», «Русмолко» төркеме, «Русагро» агрохолдингы, «Русагро-Инвест» аграр компаниясе, «ЮВАГ» ЖЧЖ һәм башкалар.
Эшкәртү культуралары: көзге һәм сабан бодае, кукуруз, көнбагыш, рапс, шикәр чөгендере, бәрәңге, техник культуралар.

Сусыз аммиак технологиясен сайлау өчен сәбәпләр (хәзерге вакытта ачыкланганнары):
А) азот белән тиешенчә туендырганда уңдырышлылык арту (традицион агротехникалар белән чагыштырганда +20% тан +40% ка кадәр)
Б) ашламаның дәвамлы тәэсире
В) ашламаны иртә (җәй-көз) кертү исәбенә дә, шулай ук кертү процессының югары тизлеге исәбенә дә ашлауда вакытны янга калдыру
Г) азот белән ашлауның иң кулай формасы булып тора
Д) ашлама (сусыз аммиак) белән туфрак дымында бәйләнеш барлыкка килү
Е) бер тапкыр эшкәртү (өстәмә тукландыру таләп ителми).

«ЭльбрусАгро» ширкәтен сайлауларының сәбәпләре (хәзерге вакытта ачыкланганнары):
А) ашлама кертүнең югары тизлеге (бер звенога тәүлегенә I50 гектардан артык), ике сменалы эш режимы
Б) урынга барып җиткәч, җайланманы әзерләү һәм эшкә керешү тизлеге
В) өстәмә опцияләр куллану яисә тулы циклда (тракторлар, ягулык, яшәү) эшләү мөмкинлеге

Эш 004

«ЭльбрусАгро»ның матди һәм матди булмаган активлары

- Күпсанлы техника паркы (25 куәтле трактор, 25 культиватор, агрегатка тагыла торган 50 цистерна, аммиак ташыгыч 50 машина, 90 ат көчле тракторлар, техник ярдәм автомобильләре, җиңел автомобильләр)
- Команданың профессиональлеге («ЭльбрусАгро» ЖЧЖ нең барлык белгечләре даими рәвештә әзерлек һәм аттестация үзәкләрендә белем ала)
- Сервис хезмәте (техникага вакытында хезмәт күрсәтүне тәэмин итә)
- Эшнең барлык этапларында сыйфатны контрольдә тоту (GPS тренингы системасы, ГЛОНАСС; кабинада видеокүзәтү системасы; аммиак бирүне автомат рәвештә көйләү системасы, буразналарны ябу системасы)
- автоматической регулировки и подачи аммиака; система закрытия борозд)

Яшерен фотоархив

ТОТРЫКЛЫ УҢЫШ ЮЛЫ.
«ТАТАГРОХИМ»: ТАТАРСТАНДАГЫ ӘЧЕ ТУФРАК ПРОБЛЕМАСЫН ХӘЛ ИТӘ

Сөмбел Мөгыйнова

Фәндә исбатланган: югары һәм тотрыклы уңыш үсемлекләрнең яңа сортларын уйлап чыгаруга гына түгел, ә минераль һәм органик ашламаларны дөрес куллануга да бәйле. Ә әче туфракта уңдырышлылыкны арттыруның иң нәтиҗәле юлы – аңа известь кертү.

ОЗАК ЕЛЛАР БУЕНА ТИКШЕРЕНҮЛӘР НӘРСӘ ТУРЫНДА СӨЙЛИ

Известь белән ашлау нәтиҗәсендә файдалы микрофлора, бигрәк тә азот һәм нитритларны туфракка кертә торган бактерияләр активлаша. Бу исә атмосферадагы азотны үзләштерү хисабына үсемлекләрне азот белән туендыра. Акбур ташы (известь) кисәкчекләре туфракка эләккәч, структура агрегатлары үзгәнә әйләнә, бу исә суга чыдам ярмалы структура формалашуга ярдәм итә. Акбур ташы белән кергән кальций туфрак коллоидларын коагуляцияли, туфракның структурасын яхшырта һәм аның агрегатларының суга чыдамлыгын арттыра. Известь йогынтысында суүткәрүчәнлек һәм аэрация яхшыра, җир өстенең кабыклануы кими һәм авыр грануламетрик составлы туфракны эшкәртү җиңеләя.

Озак еллар буена алып барылган тикшеренүләр күрсәткәнчә, известьле ашламалар куллану туфракта хәрәкәтчән токсикант формаларының тупланууына һәм аларның үсемлекләргә үтеп керүенә экологик киртә булып тора. Туфракның агулы элементлар, бигрәк тә авыр металлар һәм радионуклидлар белән пыч-

Фото: «Татагрохим» ААҖ нән алынды. РЕКЛАМА



рануы шартларында, аңа известь кертү аларның үсемлекләргә үтеп керүен 3–8 тапкырга киметә.

Әче туфрак тотрыклы рәвештә авыл хуҗалыгы культураларының югары, экологик яктан чиста һәм биологик яктан тулы канлы уңышын алуны тоткарлый торган факторларның берсе булып тора. Шул сәбәпле, ел саен Россиядә – 20 млн тонна, Татарстанда 800 мең тоннадан артык бөртекле культуралар харап була.

РАЙОННАР БУЕНЧА СТАТИСТИКА

2025 елның 1 гыйнварына республикада 1298,6 мең гектар җир әче туфраклы булып санала, бу чәчүлек җирләре мәйданының 43,3% ын тәшкил итә. Шуларның 24,8 гектары (0,8%) – бик әче, 246,7 гектары (8,2%) – уртача әчелектә, 1027,2 мең гектар (34,2%) – түбән әчелектә. Әче туфраклы җирләр бигрәк тә Алексеевск (тикшерелгән мәйданның 59,8% күләме), Нурлат (57,3%), Арча (56,3%), Чистай (56,2%), Актаныш (54,7%), Аксубай (48,7%), Әлки (48,5%), Спас (45,5%), Яңа Чишмә (43,7%), Тукай (42,4%) районнарында күп.

Әче туфракны известь белән ашламый торып, авыл хуҗалыгы культураларының югары уңышын алып булмый! Туфрак мохитенең әче реакциясе үсемлекләр үсешенә тискәре йогынты ясый. Моннан туфракка известь кертеп кенә котылып була. Туфракка известьне проект-смета документларын эшләп бетергәч, хуҗалыкларның җирләрендә «Татар» дәүләт агрохимия үзәге һәм «Әлмәт» дәүләт станциясе агрохимик тикшеренүләр циклы үткәргәч кенә кертеп була. Известьне биш еллык цикл буенча кертергә кирәк. Ә болай нибары ике генә район эшли: Әтнә белән Балтач.

ЗИННӘТ ТҮГЕЛ, Ә ЗАРУРИЛЫК

Татарстанның фәнни нигезгә таянып, планлы рәвештә туфракның әчелеген бетерү мөмкинлеге бар, чөнки биредә, Россиянең башка төбәкләреннән аермалы буларак, «Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте системасы (элеккеге «Сельхозхимия» берләшмәсе – ред. иск.) сакланган, ул 45 ел гамәлдә инде. Хәзерге вакытта аның составына 28 предприятие, 10 ярдәмче хуҗалык, 15 карьер керә. Алар тулысынча махсус техника белән тәэмин ителгән, җитештерүгә миллион тоннадан артык известь ашламасы бирәләр һәм елына 100 мең гектар мәйдандагы әче турфакны известь белән эшкәртә алалар.

Җир эшкәртү буенча йөз елдан артык булган тәҗрибә шуны раслый: чәчү әйләнеше өчен ашлау системасын эшләгәндә, иң беренче әче туфракны известь белән эшкәртүне күздә тотарга кирәк. Әйе, тармакны химик ашламалар белән эшкәртү басуларның уңдырышлылыгын арттырды, әмма җир эшкәртүнең бу ысулы артыгы белән кыйммәткә чыга. Бу экологик яктан җитди проблемалар тудырды – туфракта ашлама һәм пестицид калдыкларының тупланууына китерде. Алар исә яңа организмнарның мутациясен китереп чыгара һәм токсик йогынты ясый.

Туфракка известь кертү турыдантуры аны туклану элементлары белән тәэмин итүгә бәйле. Биредә Дмитрий Николаевич Прянишниковның канатлы гыйбарәсе искә төшә: «Белем җитми икән, аны артык ашлама белән алыштырып булмый». Уҗым бодаен үстергәндә, тагын бер мөһим деталь: бу культура алюминий белән марганецның хәрәкәтчән формаларына бик сизгер, бигрәк тә кыш чыкканда. Алар бодайның уңдырышлылыгына һәм кышны исән-имин чыга алуына йогынты ясый. Минераль ашламаларны акбурлы таш белән бергә кертү уңышны ике тапкырга арттыру мөмкинлеген бирә. Ә инде органик ашламалар белән акбурны бергә кулланганда, хәтта өчләтә уңыш алырга да була. Известь кертү корылык елларында да бик файдалы.

«Татагрохим» ААҖндә шуны истә тотарга кушалар: авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын саклау буенча контроль Россия Федерациясендә гамәлдә булган законнар нигезендә дәүләт тарафыннан гамәлгә ашырыла. Шунысы да мөһим: кирәкле чаралар тотрыклы дәүләт субсидиясе белән тәэмин ителергә тиеш – субсидия барлык чыгымнарның 70-80%ыннан да азрак була алмый. Туфракның уңдырышлылыгы илнең азык-төлек куркынычсызлыгының иң мөһим пунктларының берсе булып тора.

Фотолар Александр Ефремов һәм махсус проектта катнашучылар архивыннан



«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп алга атлаучы, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылучы кешеләр бар. Алар юллар сала, күперләр төзи, тирә-юньне тәртипкә китерә – бер сүз белән әйткәндә, куллары тигән һәр нәрсәне камилләштерә.
Без, «Зарланмыйча эшләгән буын» проектын дәвам итеп, бу юлы эш сәгатенең күп өлешен... ҖИР АСТЫНДА үткәрүчеләр турында язарга уйладык.
Бу – инде менә 30 елга якын башкала тормышын уңайлырак һәм тизрәк итә торган метро төзелешендә катнашучылар тарихы.
Казан кешеләренең күбесе үзләренең тормышын метродан башка күз алдына да китерә алмый. Ә егерме яшьтән яшьрәкләр гомумән Казанда метроның булмавына ышанмый.
Казанда метро булмаган вакытта башкала тормышы нинди булган?
Шәһәребездә метро ничек пәйда булган?
Боларның барысын да кемнәр тормышка ашырган?
Утыз ел элек җир өстендә һәм җир астында булган вакыйгаларга әйләнеп кайтыйк әле.



21 НЧЕ ТАРИХ.
Минтимер Шәймиев җир астына киләчәк буыннарга аталган нинди юллама күмеп калдырган

22 НЧЕ ТАРИХ.
Николай Мошка җир астында ювелир эшенә тиң хезмәтне ничек башкарган

23 НЧЕ ТАРИХ.
Бухгалтер Дина Ткач метро төзелешенә дигән акчаны ни рәвешле тапкан

Башка тарихлар «Татарстан» журналында 2022 елның – 10–12 нче, 2023 елның – 1–2, 6 нчы, 2024 елның 1,4 нче саннарында дөнья күрде.

21 НЧЕ ТАРИХ

ЯҢА ГАСЫРГА ЫРГЫЛЫШ

1997 елның 27 августында, Казан метрополитены төзелешен башлау тантанасында, киләчәк пассажирларына юллама салынган капсула гранит-мәрмәр ротонда нигезенә салып калдырыла. Тиздән Казан метросы ачылуга 30 ел тула, ә шул чакта күзалланган киләчәк пассажирлары инде 20 ел буе (2005 елның августыннан) үз тормышларын метродан башка күз алдына да китерә алмый. Кызык, ул юлламада нәрсә язылган икән соң?
Метрода йөрүче шул пассажирларның берсе булганга, бу сорау белән Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевка мөрәҗәгать итәм: ул чакта, Татарстанның беренче Президенты сыйфатында, әлеге юлламаны язуда катнашкан шәхес бит.

Татьяна Вафина

ХАТНЫҢ СЕРЕН ӘЛЕГӘ АЧМЫЙБЫЗ!

– Минтимер Шәрипович, юлламаның серен ача аласызмы? Анда нәрсә язылган иде?

– Әлеге тантананы бик яхшы хәтерлим, барыбыз да шатландык. Метро! Ниһаять! Чыннан да, бу безнең тормышыбызда кабатланмас вакыйга булды. Шул көнне булачак «Тукай мәйданы» станциясендә метроның беренче дивары казылды. Әмма шул ук вакытта без үз өстебезгә зур җаваплылык та алдык. Җир астында төзелеш тәҗрибәбез бөтенләй булмаса да, Россиядә җиденче метроны нульдән ясарга тәвәккәлләдек! Мин моны «яңа гасырга ыргылыш» дип атадым. Шуннан бирле инде 28 ел узды, әмма ил буенча әлегә башка беркем дә моңа батырчылык итмәде. Ә без булдырабыз! Без булдырдык! Хәзер безнең метрополитенның икенче линиясе дә төзелә инде. Һаман алгарак һәм тирәнрәк юл салуыбызны дәвам итәбез. Шулай булгач, хатның серен дә ачмыйбыз әле! Бер генә нәрсәне әйтәм: метро – цивилизация билгесе, һәм без балаларыбыз белән оныкларыбызның моны аңлавын һәм тырышлыгыбызның кадерен белүен бик теләгән идек.

МИН БАРЫСЫ ДА НИЧЕК БАШЛАНГАНЫН ХӘТЕРЛИМ!

– Метро төзи башлаганда, бу эшкә каршы килүчеләр дә булды. Кемдер, Казанда туф-

Фото: ТР Дәүләт Советы матбугат хезмәтеннән алынды

рак катламы нинди дә булса җир асты корылмалары төзүгә яраклы түгел, дип ышандырмакчы иде, кемдер, акчагыз күп булса, фатирлар төзегез яки башка уңайлыклар тудырыгыз, дип шаулады... Халыкны тынычландырып, төзелешне ничек башлап җибәрдегез?

– Әйе, төрле фикерләр булды: җирнең сыйфаты турында да, сарыф ителәсе акча хакында да... Әмма аек акыллы кешеләр шәһәрнең зурая баруын күрә һәм аңлый иде. Бары тик җигүле транспортны гына исәпкә алып төзелгән урамнар һаман арта барган транспорт агымына инде көчкә түзә. Шунлыктан башкалабыздагы төп проблемаларның берсе – халыкны транспорт белән тәэмин итүгә игътибар бирүне кирәк таптык. Бу проблема белән шәһәр халкының күпчелеге көн саен очраша бит. Алай гына да түгел, бу – нәкъ менә канәгатьсезлек чыганагы иде. Һәрвакыт әйтә идем: әгәр дә җитәкче буларак үзеңә бәяне ишетәсең килсә, җәмәгать транспортына утырып әйләнә бер – халыкның чын кәефен тоярсың. Шулай булгач, мин кемнедер аеруча тынычландырырга туры килде, димәс идем. Без халыкка җир асты төзелешенә кагылышлы барлык нәрсәләр турында җентекле мәгълүмат бирдек: эшнең туфрак сыйфатына гына түгел, бәлки дөньядагы алдынгы технологияләрне үзләштерүгә бәйле булуын аңлаттык, финанслау чыганакларын да күрсәттек.

Казанда метро төзү кирәклеге турында инде 1979 елда – башкаланың миллионынчы кешесе тууын билгеләп үткәндә үк сүз чыккан иде. 1983 елда Казанның комплекслы транспорт схемасын эшләү тәгәлләнде. Сүз уңаеннан, анда инде метро төзелеше каралган, аны 2000 елда эшләтеп җибәрергә планлаштырылган иде. Билгеле инде, геологик тикшеренүләрдән башладык, иң танылган эзләнү, геология оешмаларын эшкә җиктек. Мин ул вакытта ТАССР Министрлар Советы рәисе идем. Шунлыктан барысы да ничек башланганын бик яхшы хәтерлим!

1986 елда Мәскәүнең «Метрогипротранс» институты метроның беренче линиясен проектлау һәм төзүнең техник-икътисадый нигезләмәсен тәкъдим итте. Проект эшләре башланды. Әмма 1989 елда СССР Министрлар Советы Казанда метрополитен буенча эшләрне финанслауны туктатты, чөнки экспертлар аны төзүгә каршы чыкты: бездә туфрак үзенчәлекле һәм тирән яткан тоннельләр таләп итәчәк, бу, әлбәттә, эшләрнең бәясен берничә тапкырга кыйбатландырачак, диделәр. Билгеле булганча, шул чакта илдә үзгәртеп кору башланды, һәм өстәмә акча табу турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде.

ЕЛЬЦИН КАРАРЫ

Без бу мәсьәләгә республика тормышындагы төп икътисадый реформалар һәм сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә икътисад үсешен тотрыкландыра алгач кына кабат әйләнеп кайттык. Әмма мондый зур проектка үз акчабыз гына җитми иде, әлбәттә. Шуңа күрә бу мәсьәләне берничә тапкыр федераль хөкүмәт каршында күтәрдек. 1995 елда Россия хөкүмәте якын киләчәктә метрога исәп тота алган тугыз шәһәр исемлеген төзеде. Әмма аңа Казан кертелмәгән иде. 1995 ел ахырында без метроның беренче участогы техник проектын үз көчебез белән эшләп бетердек. Ул начар түгел, сыйфатлы иде. Шуңа күрә без Россия хөкүмәтен һәм тармак министрлыкларын инициативабызны хупларга күндердек. 1996 елда, озак сөйләшүләрдән соң, республика Казанда метро төзүгә рөхсәт алды. Карар Россия Президенты Борис Николаевич Ельцин тарафыннан 1996 елда кабул ителде.

ИҢ ОСТАЛАР ЧАКЫРЫЛДЫ

Төзелеш-җир казу эшләрен башкару өчен «Казметрострой» МУП төзелде. Бөтен илдән тәҗрибәле тоннельче-метро төзүчеләр чакырылды. Җитәкче итеп туп-туры БАМнан кайткан һәм тоннельләр төзүдә зур тәҗрибәсе булган Марат Муллахмәт улы Рәхимов билгеләнде. Ул барлык сынауларны да намус белән узды һәм төзелешнең бу бик мөһим тармагын әлегә кадәр җитәкли.

2005 елда Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү турында 1999 елда карар кабул ителде, һәм метро әзерлек программасына әһәмияте һәм акча кертү күләме буенча төп «юбилей» объектларыннан берсе буларак кертелде. Төзелешне Россия һәм Татарстан тигез өлешләрдә финанслады, әмма федераль үзәктән акчага бәйле өзеклекләр әледән-әле эшкә аяк чалды. Шуңа да карамастан, безнең метро төзүчеләр беркайчан да эшне туктатмады!

ПУТИН ВӘГЪДӘСЕ

Россия Президенты вазыйфаларын башкаручы Владимир Владимирович Путинның 2000 елның 21 мартында Татарстанга килүе метро проектын гамәлгә кертүдә зур әһәмияткә ия булды. Без аның белән шәһәр үзәгенә киттек, тузган торакны бетерү программасы буенча җимерелергә тиешле йортларның берсендә булдык. Нәкъ шушы йорт янында Казан метрополитенының беренче станциясе төзелеше башланган иде. Владимир Владимирович бу мөһим объектны да игътибарсыз калдыра алмады. Путинны күргәч, шунда ук таныдылар (барысы да телевизор карый бит). Метро төзүчеләр безне чолгап алды һәм Владимир Владимировичка, Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча дәүләт комиссиясе рәисе буларак, беренче участок тантаналы датага тапшырылсын өчен, метро төзелешен вакытында финанслауны сорап мөрәҗәгать иттеләр. Эш шунда ки, әле үзе премьер булган чагында ук Владимир Владимирович безгә югары хөрмәт күрсәткән һәм әлеге комиссияне җитәкләргә ризалашкан иде.

Россия Президенты вазыйфаларын башкаручы, аннары инде Президент Путинның алга таба да комиссия рәисе булып калачагына минем бераз шигем бар иде. Әмма ул бу эшеннән дә баш тартмады. Алай гына да түгел, ул вакытта бездә бу темага сөйләшү булды, һәм ул, 26 марттагы сайлауларның нәтиҗәсенә карамастан, җәй көне Казанга килергә һәм дәүләт комиссиясенең чираттагы утырышын уздырырга теләвен әйтте.

Шул рәвешле, безнең уй буенча, метро миллионлы шәһәрдә яшәүчеләр өчен юбилейга төп бүләкләрдән берсе булырга тиеш иде. Тик әлегә төзелеш туктап калды. Һәм эшчеләр шул очрашу вакытында Путинга Стаханов режимында эшләргә әзер булуларын белдерделәр. Владимир Владимирович, аларны игътибар белән тыңлап, инициативаны хуплавын әйтте һәм финанслауны хәл итәргә вәгъдә бирде. Эшчеләр Россия Президенты вазыйфаларын башкаручыны «үзләренеке» дип таны-

Бу көнне без Россия Президенты Владимир Владимирович Путин, Казахстан Президенты Нурсолтан Абиш улы Назарбаев һәм РФ субъектлары башлыклары белән метрополитен станцияләрен карадык һәм поездда «Кремль» станциясеннән «Әмәт» станциясенә кадәр бардык.

ды һәм аңа Казан метро төзүчесенең фирма каскасын бүләк итте. Путин үз сүзендә торды. Финанслау җайга салынды!

Минем хәтеремә тагын бер тарихи көн уелып калды. 2000 елның 22 мае ул. Капсула салынганнан соң нәкъ 1000 көн үткәч, без Канаданың «Lovat» фирмасының беренче «Сөембикә» тоннель казу комплексын эшләтеп җибәрдек. Әлеге тантанада фирма президенты Рик Ловат үзе дә катнашты. Техник алгарышның бу уникаль могҗизасын күрү өчен безгә илнең барлык метрополитен җитәкчеләре җыйналды. Ул нәкъ менә Ла-Манш бугазы астыннан тоннель казыган комплекска тәңгәл иде. Бу Татарстан алынган эшнең дөньякүләм масштабта булуын тагын бер кат раслады. Башкача булуы мөмкин дә түгел иде, чөнки безнең катлаулы гидрогеологик шартлар метро төзелешендә иң алдынгы дөньякүләм казанышлардан файдалануны таләп итте. Күз алдыгызга китерегез, бу куәтле машина артыннан әзер тоннель кала! Чын могҗиза бу!

Метро төзүче эшчеләр иң югары мактауга лаек, чөнки бу – аларның гаять зур хезмәт батырлыгы! Җир астында эшләү аерым осталык һәм югары квалификация таләп итә. Без метро төзелешендә күп тапкыр булдык, һәм һәрвакыт аларның фидакярлегенә соклана идек.

МЕТРО ТӨЗҮЧЕ ЭШЧЕЛӘР ИҢ ЮГАРЫ МАКТАУГА ЛАЕК, ЧӨНКИ БУ – АЛАРНЫҢ ГАЯТЬ ЗУР ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ! ҖИР АСТЫНДА **ЭШЛӘҮ АЕРЫМ ОСТАЛЫК ҺӘМ ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИЯ ТАЛӘП ИТӘ.** БЕЗ МЕТРО ТӨЗЕЛЕШЕНДӘ КҮП ТАПКЫР БУЛДЫК, ҺӘМ ҺӘРВАКЫТ АЛАРНЫҢ ФИДАКЯРЛЕГЕНӘ СОКЛАНА ИДЕК.

Мәгълүм булганча, Казан метрополитенының беренче станциясе – «Сукно бистәсе». Ул 2005 елның 21 июлендә файдалануга тапшырылды. Әмма рәсми рәвештә Казанда метро 2005 елның 27 августында ачылды. Бу көнне без Россия Президенты Владимир Владимирович Путин, Казахстан Президенты Нурсолтан Абиш улы Назарбаев һәм РФ субъектлары башлыклары, башкаланың 1000 еллык юбилее кунаклары белән метрополитен станцияләрен карадык һәм поездда «Кремль» станциясеннән «Әмәт» станциясенә кадәр бардык. Миңа Владимир Владимировичның, ул көннең бик киеренке графигына карамастан, метро төзүчеләр белән аралашырга вакыт табуы ошады. Дәүләт башлыгы барысына да бик яхшы эшләре өчен рәхмәт белдерде. Әңгәмә «үзенекеләр» арасындагы кебек җылы һәм җайлы килеп чыкты.

Менә без сезнең белән метро төзелеше тарихына кыскача экскурсия дә ясап алдык.

ҺӘР СТАНЦИЯДӘ – ҺӘЙКӘЛ!

– «Казметрострой» АҖнең 30 еллыгына хезмәт коллективы метро төзүчеләргә һәйкәл кую инициативасы белән чыкты. Сез мондый һәйкәлне кайда күрергә теләр идегез?

– Метро төзүчеләр – төзүчеләр арасында элита ул. Аларның эше безнең һәркайсыбыз – республика, башкала һәм миллионлаган кеше өчен шулкадәр әһәмиятле ки, шуңа күрә метро төзүчегә һәйкәл үзләренә ошаган һәр җирдә торырга мөмкин. Һәр станциядә булса да ярый! Чөнки алар чыннан да зур мактау һәм хөрмәткә лаек. Аларның теләсә кайсы карарын хуплыйм! Гүзәл Казаныбызның барлык халкы һәм кунаклары минем белән килешер, дип уйлыймын!

22 НЧЕ ТАРИХ

БЕЗ БАМНАН КИЛДЕК

Төзелеш участогы җитәкчесе Николай Мошка – Казанда метро төзелеше башында торган шәхес. БАМны төзүче. Ул бу зур төзелешнең ничек башлануы, эшчеләрнең нинди кыенлыкларны җиңеп чыгуы һәм проектның ничек тормышка ашырылуы турында сөйләде.

Оксана Бирюкова

БУРЫЧ – МЕТРО ТӨЗҮ

– Метро төзүгә ничек карадык, дисезме? Нәрсәгә тотынуыбызны аңлап эшли башладык, – дип искә ала Николай Иванович. – Без аны үзебезнең бурыч дип кабул иттек. Хәзер генә ул метро төзелә торган бөтен җирдә борылырга да урын юк, ә ул чакта иркен чиста кырдан башланды – бер вагон, бер шахта казый торган машина, зур чокыр, күпчелеге (һәм шул исәптән мин дә) БАМ төзелешеннән килгән алты кеше идек.

Башта эшкә субподряд оешмалары – «Мосметрострой», «Комос» һәм башкалар җәлеп ителде, әмма процесс барышында без үзебез дә бөтен нечкәлекләргә төшендек. Акрынлап кешеләр арта башлады: югары класслы белгечләр дә, электрослесарьлар да, тоннель казу комплексының берничә машинисты да кушылды. Бер өлеше, минем кебек үк, Байкал-Амур магистраленнән килде. Әлбәттә, безнең комплекслар БАМдагыдан аерыла, әмма үзенчәлеге шул ук иде, шуңа күрә барысына да тиз өйрәндек.

Төзелеш вакытында ниндидер экстремаль хәлләрне хәтерләмим, гадәти эш – һәрвакыттагыча кыска сроклар һәм кадрларга ихтыяҗ. Әмма кешеләр табыла һәм барысына да өйрәнә торды. Башта без тәүлегенә, ким дигәндә, 12 сәгать эшлидек, бригадалар – тәүлек буе. Әйе, без оешкан вакытта беренче ел иң катлаулысы булды, аннары исә коллектив тупланды, берләште.

Канадада эшләнгән, нәкъ менә безнең гидрогеологик шартларга тәгаенләнгән махсус техниканы сатып алганнан соң, метроның беренче тоннельләрен үз көчебез белән казыдык.

Беренче чорда тоннель бөҗрасын тышлау күп вакытны ала иде. Бу эш югары төгәллек һәм ныклык таләп итә. Аны ясауда французлар, немецлар, канадалылар катнашты. Эш шунда ки, бездә тоннель бөҗрасы – чөйсыман. Технология ягыннан аңлатсак, болай: безнең машиналарда навигация тора, һәм һәр үткән метрдан соң компьютер бөҗраның ничек басарга тиешлеген күрсәтә, ә аның 22 борылышы бар. Ягъни бөҗра һәр метр саен әйләнү һәм чөйләнү хисабына кысыла, шуңа күрә тоннель тотрыклы килеп чыга.

Фотолар Николай Мошка архивыннан.

МАШИНА «ЧУМДЫ» ДА, «КАЛЫКТЫ» ДА

Беренче машина 1999 елда сатып алынды. Икенчесе бераз соңрак – NFM, Франциядән. Өченчесен дә – шулай ук NFM – алырга туры килде, чөнки метро казучылар артыннан өлгерешми башладык. Дүртенчесен – «Хитачи»ны 2011 елдан 2018 елга кадәр Мәскәү метрополитенының яңа станцияләрен төзүдә катнашканда башкала өчен сатып алдык. Аларның барысын да һәрвакыт төзек тотарга тырышабыз, хәзер ике машина эшли.

Нигездә, барысы да яхшы бара. Хәер, бик каты тырышырга туры килгән чаклар да була, әлбәттә. Бу җәһәттән, мәсәлән, Кремль станциясеннән Тукай мәйданына кадәр эшләнгән участокның соңгы өлеше истә калды. Ул җәяүлеләр кичүе астыннан үтте. Өстәвенә, кичүдән тагын ике метр тирәнлектә яңгыр сулары коллекторы урнашкан. Машиналарга аска «чумарга» һәм аннары өскә «калкып чыгарга» туры килде. Башта беренче тоннельне Кремль урамына таба казыдык, аннары Тукай станциясенә таба борылып кире килдек. Тагын бер катлаулы участок – станциядән җир асты кичүенә таба төзелгән кичү астында. Безгә тоннельне җәяүлеләр кичүе плитәсеннән ярты метрга гына аскарак казырга кирәк иде – бернәрсәгә дә кагылырга, тияргә ярамый. Ярыклар хасил булмасын өчен, бик каты төгәллек таләп ителде. Монда, шәһәрдә, үз үзенчәлекләре – коммуникацияләр бик күп. Безнең өстәге һәр тоннельдә – йә суүткәргеч, йә газ торбалары, йә кабельләр. Сукно бистәсеннән Тукайга кадәр – көчле гидростатикалы дымлы көпшәк ком. Кремль ягына таба геология үзгәрә: Тукайдан Профсоюз урамына кадәр йомшак токымнар ята, ә Профсоюз урамы астында инде доломитлар китә. Шул чакта тагын бер проблема пәйда булды – безнең машиналар ныклыгы 4 баллга кадәр булган токымнарга исәпләнгән, ә монда 8 тирәсе иде. Машиналар, су белән суытылуга карамастан, роторның каты токымнарга ышкылуыннан 50 градуска кадәр кызды.

Әмма, тулаем алганда, бу шәһәр метро төзелеше өчен гадәти эш мизгелләре. Машиналар да Казан геологиясе өчен махсус сатып алынды – максималь тотрыксыз һәм нык дымлы токымнар өчен. Алар тулысынча герметик, һәм без алданиләр булганын күрмибез – конвейерда эшкәртелгән токым гына кала. Төзелештә һәрвакыт ниндидер көтелмәгән хәлләр була инде ул, әмма эш тәмамлангач, кыенлыклар әллә ни мөһим булып тоелмый.

КӨТЕЛМӘГӘН ТАБЫЛДЫКЛАР

Сукно бистәсендә һәм Тукайда станцияләр төзегәндә 8 метр чамасы тирәнлектә иске буралар – яфраклы агач токымнарыннан буралган



кечкенә корылмалар очрады. Ленин дамбасына хәтле иске күпернең терәкләренә дә тап булдык – бер тапкыр хәтта ротор да туктап калды. Аннары архивлардан ачыклап шуны белдек: без нәкъ менә шәһәрнең беренче трамвае өчен салынган агач күпер астыннан узганбыз икән. Бассейн янында, Тукай станциясе тирәсендә, нииндидер иске коллекторларга юлыктык – мөгаен, дренаж системаларыдыр. Безнең өчен шунысы да гаҗәп булды: Кремльгә якынайган саен, «Кремль» станциясе тирәсендә, искитәрлек бернәрсә дә табылмады.

Сүз уңаеннан, әлеге станция турында – башта аны нәкъ Кремль каршында төзергә планлаштыралар. Ләкин аннары мәйдан ягыннан Кремльгә таба күренешне бозмас өчен, бераз күчерергә булалар. Беренчел проект буенча ул чиркәү янәшәсендәрәк урнашырга тиеш була.

Төзелеш вакытында безнең юлда нәрсә очрарга мөмкинлеген аңлау өчен архивларны даими өйрәнергә туры килде. Мәсәлән, Кремль ягында, Болак Казансу белән кушылган урында, табылдыклар күп булыр, дип уйладык, чөнки анда урман белән сату итә торган биржа булган, баржалар кереп туктаган. Архитектурасы да үзенчәлекле – Болак буенда сәүдәгәрләр яшәгән. Без – БАМ төзүчеләр. Кемдер тайгадан, кемдер Ташкенттан, Новосибирскидан, Киевтан. Күп нәрсә кызык булды безнең өчен. «Тукай» станциясен төзи башлагач, безгә: «Станция бирердә булачак, койма тотыгыз», – диделәр. Ә анда – колонналы иске агач йортлар – ике катлы, бер катлы. Боларның барысын да җимерергә туры килде. Сукно бистәсендә дә шул ук хәл кабатланды.

Әмәткә кадәр тоннель казыганда, Горки ягына таба участокта бигрәк тә кыен булды. Янәшәдә бакчачылар ширкәте – хосусый территорияләр, элеккеге дачалар. Җирле халыкның ризасызлыгын күп ишетергә туры килде – алар астан юл казуыбызны сизеп торды. Банк янында – Бауман һәм Профсоюз урамнары чатында урнашкан Казанның беренче даруханәсе белән булган хәл истә калды. Тоннель казыганда, бу бер гасырлык архитектура һәйкәле булган бинаның подвалына кадәр араның нибары 2,5 метр икәнлеге ачыкланды. Бинаны саклап калу өчен бик сак эшләргә туры килде.

ЭШТӘН ТУЙМЫЙБЫЗ

Бу юнәлештә инде күп еллар эшлим. Арыганлык та була, әмма бездә эштән туярга өлгермисең. Технологияләр элеккечә калса да, төзелеш урыннары даими үзгәрә. Башта шәһәр үзәгендә эшләдек, хәзер монда, Сахаров урамында, аннары Республика балалар клиник хастаханәсе районындагы каенлыкка күчәбез. Без бер урында озак тормыйбыз. Бүген Сахаров урамында булсак, бер елдан инде яңа мәйданчыкта эшли башлаячакбыз. Шулай күченеп йөрибез, Миль урамында урнашкан базабызга кайтып йөрмәскә тырышабыз, чөнки һәр күченү – өстәмә кыенлыклар ул.

Һәр станцияне төзү ике ел ярымга якын вакытны ала. Әгәр 3–4 станциядән торган тулы бер линияне алсак, үзегез исәпләп карагыз. Илебезгә хас кыенлыклар бездә дә чагылыш таба. Төп проблема – эшчеләр җитмәү, яшьләр хәзер механик эшне яратмый, курьер булып эшләүне өстенрәк күрә. Киләләр, әлбәттә, әмма кадрлар кытлыгы барыбер үзен сиздерә. Бу бигрәк тә субподрядчылар буенча – без бит монолит эшләрен үзебез алып бармыйбыз, башка оешмаларны җәлеп итәбез.

Кешеләр яхшы яшәргә тели – бу норма, әмма һәрвакытта да лаеклы шартлар тудырып булмый, хезмәт хакы буенча дәүләт предприятиеләре хосусый эшмәкәрләр белән көндәшлек итә алмый. Тирә-ягыгызга карагыз әле – дүрт ел эчендә биредә тулы бер квартал үсеп чыкты, ишегаллары машиналар белән тулды, фатирлар кыйммәт... Ә эшче куллар җитми.

МЕТРО КАЙДА, ЦИВИЛИЗАЦИЯ ДӘ ШУНДА

Баштан ук әйттек: иң мөһиме – башлау, аннары туктап булмаячак. Һәм шулай булып

чыкты да. Мәскәүгә карагыз – анда метроны инде 100 елга якын, 1936 елдан бирле төзиләр һәм туктый алмыйлар: бер боҗра, икенчесе, радиуслар. Без Мәскәүдә станцияләр төзергә ярдәм иткәндә, берсе МКАД артында урнашкан иде. Кыр уртасында төзелеш башладык, шул арада янәшәдә ике зур микрорайон үсеп чыкты – берсе 20 мең кешелек, икенчесе 30 мең кешелек. Метро кайда, цивилизация дә шунда.

Безнең Казанда да шулай – тормыш бер урында тормый. Статистика укыдым: бер ел эчендә генә дә безнең метро 40 миллионга якын пассажирны күчерә. Күз алдына китереп карагыз, бу кешеләр метродан башка – такси, троллейбус, трамвайларда ничек хәрәкәт итәр иде? Бөкеләр коточкыч булыр иде, бигрәк тә үзәктә.

Перспектив планнарны да күрдем – линияләрне Иннополиска, Юдинога кадәр озайтырга тәкъдим ителә. Даими үсештәге шәһәр өчен бу бик кирәк.

Без инде төп тоннельләрне казыдык һәм Дубравная белән Фучик урамнары чатындагы гамәлдәге тоннельләр астындагы техник яктан катлаулы ике өлешне төгәлләп килябез. Якын киләчәктә без техниканы РКБ янындагы участокларны төзүгә күчерәчәкбез. Анда инде әзерлек эшләре (шул исәптән инженер эзләнүләре һәм проектлауны да кертеп) алып барыла.

Беренчел план буенча бу участокларда өч яңа станция төзеләчәк: «Буревестник», «ДРКБ», «Каенлык». Шулай ук әлеге аерымланган тармакка хезмәт күрсәтәчәк яңа электр депосын төзү планлаштырыла. Дубравная һәм Фучик урамнары арасында 360 метр озынлыктагы тоташтыру тоннеле составларны метро линияләре арасында күчереп йөртү өчен мөһим элемент булачак.

2040 елга кадәр шәһәрне үстерү планы буенча челтәрне шактый киңәйтү күздә тотыла. Озак вакытны күздә тоткан планнар да бар. Әгәр без «Каенлык»ка кадәр барып җитсәк, кире

БЕЗ – БАМ ТӨЗҮЧЕЛӘР. КЕМДЕР ТАЙГАДАН, КЕМДЕР ТАШКЕНТТАН, НОВОСИБИРСКИДАН, КИЕВТАН. **КҮП НӘРСӘ КЫЗЫК БУЛДЫ БЕЗНЕҢ ӨЧЕН.**

әйләнеп кайтачакбыз. Мөгаен, линия «Компрессорная» станциясеннән Сахаров урамына кадәр барыр, анда тагын бер станция планлаштырыла. Аннан соң бу тармак шәһәр үзәгенә юнәләчәк. Станцияләрнең урнашу урыны әлегә тикшерелә, Ямашев һәм Чуйков урамнарындагы вариантлар карала. Алга таба линия «Декабристлар» станциясендәге беренче тармак белән тоташачак, моның өчен аны төзегәндә махсус камера калдырылган булган.

23 НЧЕ ТАРИХ

БЕЗНЕҢ КАДЕРЛЕ БУХГАЛТЕР

– Һәр зур эш кулай җитәкче эзләүдән башлана. Шуңа күрә, Казанда метро төзергә карар кылгач, бу гаять зур һәм безнең яклар өчен бөтенләй яңа төзелешне җитәкләргә сәләтле кеше эзли башладылар, – дип искә ала «Казметрострой» АҖ баш бухгалтеры Дина Семеновна Ткач. – Ул вакытта мондый төр транспорт турында бернәрсә дә белмибез диярлек, кунакка баргач, Мәскәү метросында йөреп кайтудан башка бер тәҗрибәбез дә юк иде бит.

Николай Крушинин

БЕЗНЕҢ ЯШЬЛЕК КОМАНДАСЫ

– Дина Семёновна, ә кулай җитәкчене ничек таптылар соң?

– «Казметрострой»ның булачак директоры Рәхимовны БАМда тапканнар. Кемдер менә БАМда уникаль Северомуйск тоннеленең 22 нче тоннель отряды башлыгы Марат Рәхимов бар, дигән. Ул элегрәк Ташкент метрополитенын төзүдә дә катнашкан, ягъни аның тәҗрибәсе зур. Рәхимов бу эшкә үз командасын алып килү шарты белән ризалаша. Һәм менә бу команда Казанга килә – шул вакыттан метро төзелеше башланып китә.

Башта өч-дүрт бүлмәле фатирларда бергә яшиләр – һәр гаиләгә, коммуналкадагы кебек, берәр бүлмә бирелә. 1997, 98, 99 нчы еллар... Иң авыр вакыт иде. Ләкин, кысанлыкка карамастан, бик тату яшиләр – алар бит БАМда чыныкканнар!

Хәзер инде Марат Муллахмәт улы – Россиянең атказанган төзүчесе, Казанның мактаулы гражданы, ә ул чакта, мин эшләгән «Гидроспецстрой» КМИ оешмасына килеп, «Казметрострой» МУП бухгалтеры вазифасына чакырганда, әле ять-яшь иде, мин дә яшь идем.

Дөресен генә әйткәндә, менә дигән эш урыным бар, бөтен нәрсәне белеп эшлим, яхшы хезмәт хакы алам һәм, иң мөһиме, аны тоткарламыйлар – ә бу туксанынчы елларда бик актуаль иде. Һәм кинәт элегә берни дә аңлашылмый торган яңа оешмага, яңа коллективка күчәргә тәкъдим итәләр. Анда исә үзең өчен дә, башкалар өчен дә эшләргә кирәк. Җитмәсә, метроның нәрсә икәнен һәм аны ничек төзүләрен БАМнан килгәннәрдән башка беркем дә аңламый.

Яшьләрне җыйдылар. Барыбызны да өйрәтергә кирәк иде.

Фотолар Дина Ткач архивыннан

Кыскасы, алда билгесезлек көтә... Мондый адымга яшьлек кенә сәләтле, ә мин яшь идем. Шуңа тәвәккәлләдем дә. Һәм моңа беркайчан да үкенмәдем.

Эшләү авыр, нинди дәрәҗәдә куркыныч, әмма бик кызык иде.

СЕЗГӘ ИКЕ МИЛЛИАРДНЫ КАЯ КҮЧЕРЕРГӘ?

– Ә мондый хәлдә сез бүген теге яшь Динага хәзерге тәҗрибәле Дина Семёновнадан нинди киңәш җиткерер идегез?

– Яңа эшкә алынырга кирәк. Яңалыкка өйрәнергә, күнекмәләрне үзләштерергә зарур. Башкаларны да өйрәтергә кирәк. Вазгыять өметсез түгел иде бит, ул бары яңа гына. Хәер, ул вакытта барысы да яңа иде. Тирә-якта барысы да үзгәрде. Кануннар да, салымнар да... Һәрвакыт нәрсәдер уйлап табылып торды.

«Метрострой»га килгәч, БАМнан килүчеләрне каршыма утырттым да: миңа белгәннәрегез турында барысын да тәфсилләп сөйләгез, дидем. Нәрсәдән башлана һәм нәрсә белән тәмамлана. Миңа исәп-хисапны җайга салу һәм барлык бухгалтерлык документларын, балансны дөрес төзи алу өчен барысын да аңларга кирәк иде... Менә алар миңа җентекләп сөйлиләр, төшендерәләр, минем сорауларым бетми: ә ни өчен шулай, ә нигә болай түгел?

Чөнки система бөтенләй башка. БАМда алар бары тик җитештерү белән генә шөгыльләнгән. Материаллар, комплектлау детальләрен – барысын да биргәннәр. Бер елга план төзегәннәр: ничә кубометр шартлатырга, ничә метр үтәргә кирәк – барысы да алдан билгеле. Тиешле араны үтәләр дә акча алалар. Һәм бернинди хисаплар да, баланс-финанслар да юк.

Анда төзүчеләр 20 мең кешелек бистәдә яшәгән. Рәхимов үзе җитәкче дә, хуҗа да булган. Ә монда – Россия, зур шәһәр, Татарстан, башка менталитет. Өстәвенә, Советлар Союзы таркалган, барлык законнар үзгәргән чак. Анда бар нәрсә дә баштанаяк үзгәрде бит.

Ягъни алар табыш турында да, салымнар турында да белмәгән. Һәм менә миңа яңа әйберләрне өйрәтергә туры килде. Шул рәвешле, алар – мине, мин – аларны өйрәттем, үзара тәҗрибә уртаклашу килеп чыкты.

Аларга минем белән авыр булды, бик төпченүчән, бөтен нәрсәгә бәйләнә, дигән сүзләр дә йөрде. Ә миңа алар белән ничек авыр булганын белсәгез! Мин аларга әллә нинди кушаматлар тага идем, кайберләрен һаман да онытмыйлар!

Әмма башта кайсы эштә дә җиңел түгел бит. Әкренләп барысы да җайга салына. Аннары эш майлагандай бара башлый...

Финанслау башта бик начар иде, аннары федераль бюджет пәйда булды, Казанның меңьеллыгына бүлеп бирделәр. Һәм нәкъ менә шул вакытта акчалар, ниһаять, килә башлады. 2001 елда. Меңьеллыкка өлгертү һәм беренче

биш станцияне эшләтеп җибәрү өчен безгә ике миллиард кредит бүлеп бирделәр. Хәтерлим, миңа Россия Саклык банкыннан шалтыраталар: «Сезгә ике миллиард сум бирәбез, кая күчерик?» – диләр. Күз алдына китерәсезме? Хәзер моны телефон мошенникларының чираттагы мәкере дип уйлаар иде, ә ул вакытта андый алдакчылар да юк иде әле.

Ике миллиард бирделәр. Һәм без барысына да өлгердек.

ЫШАНЫП, АКЧА БИРДЕЛӘР

– Бу миллиардлар биш станциягә дә җитмәме?

– Барысына да түгел. Финанслар җитмәгәнгә, кредит алдык. Кредитлар, процентлар, процентлар... Хезмәт хакы тоткарлану, салымнар тоткарлану. Прокуратурага, салым инспекциясенә, хезмәт министрлыгына чакыралар – кая гына барырга туры килмәде! Ни өчен хезмәт хакы түләнми? Ә ул шундый вакыт – акча юк. Предприятиеләрдә хезмәт хакын әйберләтә – макарон белән дә, киез итек белән дә бирделәр. Тик без бит макарон фабрикасы түгел. Шуңа күрә кредитлар җыйдык – халыкка хезмәт хакы түләр өчен. Метро төзүчеләр буларак, беренче рәсми хезмәт хакын без 2008 елның мартында гына алдык бит.

Ләкин БАМ төзүчеләр шундый дус, үз эшләренең осталары – беркем дә беркайчан да сынатмады. Барысы да эшләде. Берәү дә зарланмады. Алар бүген дә эшли. Күбесе инде пенсиядә, хәзер метроны аларның балалары төзи. Династияләре белән шул хезмәткә тугрылар.

Бер хәлне хәтерлим. 2002 елның марты, метро төзелеше башланганга биш ел үтте. «Ничек тә хезмәт хакын түләргә кирәк, бетте-китте!» – диде Рәхимов.

Акча табылды, ләкин бит әле аны алырга һәм халыкка таратырга да кирәк. Ул чагында акчалата бирәләр иде. Карточкалар юк.

Менә миңа җаваплы миссия йөкләнде – объектлар буенча йөрергә һәм акча таратырга. Коточкыч хәл. Бернинди инкассаторлар да, бернинди сакчылар да юк ул чакта, берьялгызым бер олау акча белән! Җаваплылык бик зур иде.

Безгә акча бүлеп бирелде-бирелүен, әмма алар счетка килмәде. Ә бездә бәйрәм – халык акча көтә. Мин банк белән килештем: әлегә акча

исәп-хисап счетына килмәсә дә, алар миңа биреп торачак. Һәм, минем сүземә ышанып, акча бирделәр! Сез күз алдына китерәсезме? Менә бит нинди зур ышаныч булган!

Кыскасы, акчаны бирделәр. Халык заводка бәйрәм итәргә җыелды. Мин дә заводка барам, вакыт инде кичке алты. Кинәт миңа банк департаменты башлыгы шалтырата: «Дина Семёновна, акча әлегә кадәр юк бит!» – ди.

Нишләргә инде хәзер? Акчаны премия иттереп, һәркемгә конвертка салдык бит. Тиешле боерык та бар. Конвертлар миндә. Рәхимов шалтырата, ашыктыра: «Син кайда? Тизрәк кайт!» – ди.

Мин исә бу пакетлар белән машинада утырам, беркая да бара алмыйм. Заводка барып, акчаны таратыргамы, әллә банкка кире тапшырыргамы? Аптырадым. Банк хезмәткәре Гүзәлгә хәлне аңлатам.

Ул: «Син, Дина Семёновна, заводка бар, аннан соң минем янга банкка кил. Счётка акча кергәнче, заложниклар кебек бергә утырырбыз!» – ди. Әлбәттә, аны мондый хәл өчен эштән дә куарга, судка да бирергә мөмкиннәр. Чөнки мондый хәлнең әлегә кадәр булганы юк – счётка акча кучмәгән килеш кулга акча бирү. Ул чакта нинди хәлдә калуымны, нәрсәләр кичерүемне беркайчан да онытмаячакмын!

Кыскасы, бәйрәмнән соң, сәгать унда банкка киттем. Инде төн, мине кертмиләр. Гүзәл шалтыраткач, керттеләр тагын. Икәүләп гасабиланып утырабыз. Эчебездә җан юк. Бөтен җиргә шалтыратабыз. Тик моның файдасы юк. Шалтырат-шалтыратма, соң, эштә беркем дә юк. Акча да юк. Инде куркудан йөрәгебез шартлар хәлгә җитте.

Һәм менә төнге 23.45 тә счетка акча килеп төште. Ура, менә бәхет!

Без, тынычланып, өйләребезгә таралыштык. Гүзәлне хәзергә кадәр искә төшерәм. Аңа «Метрострой» нәрсәгә иде инде?! Безнең өчен үзен шулай куркыныч астына куярга кирәк бит! Ул безгә бик күп яхшылык эшләде. Түләү кәгазьләрен безнең сүзгә ышанып үткәреп җибәрә иде. Метро төзелеше, казу эшләре туктамасын өчен, ашыгыч рәвештә нииндидер материалларга түләргә кирәк бит, һәрвакыт хәлебезгә керде.

ТАБЫШСЫЗ ЗАВОД

Тагын бер хатирәне яңартыйк. 1999 елда без ТБЭ заводын кабул итеп алдык. Ул йортлар төзү өчен панельләр чыгара. Үзгәртеп корудан соң аның бурычы бик күп җыелган. Шул бурычлары өчен бу заводны безгә бирделәр.

Без завод эшен белеп бетермибез, әмма барысын да санап чыгарга, инвентаризация үткәрергә, барлык номерларны күчереп язарга кирәк, миңа хәтта канализациягә дә төшәргә туры киде... Анда шундый тәртипсезлек-таркаулык, чөнки завод инде эшләми, ташландык хәлдә. Барысын да башка җиһазлар өчен үзгәртергә, бетон бәҗралар чыгаруны җайга салырга куштылар. Реконструкция ясау өчен акча бүлеп бирделәр.

Ә завод исә табышлы түгел. Бу бөтенләй коммерцияле булмаган предприятие. Әмма моны берәү дә аңларга тырышмый, нигә ашыкмыйсыз, әкрен кыймылдыйсыз, дип аптыраталар. Болай буласын белсәк, заводны сезгә бирмәс идек, диләр...

Завод кына түгел әле, аннары бездә транспорт юнәлеше пәйда булды. Мин, баш бухгалтер буларак, каршы идем. Күпме техниканы карап тотарга кирәк булачак бит! Бульдозер, экскаватор, күтәрү краннарын читтән китереп эшләтү арзангарак төшә... Ә алар БАМда шулай эшләргә күнеккән – барысы да, Советлар Союзындагы кебек, үзеңнеке булырга тиеш.

Гомумән, төрле очраклар күп булды. Аннары әкренләп барысы да җайланды, көйләнде, тотрыкланды.

ГАИЛӘМ

Метро төзелешен бизнес дип атап булмый. Безнең коллектив та бизнесменнардан түгел, күбрәк энтузиастлардан тора иде. Чит кешеләр эшкә карата булган мондый мөнәсәбәтебезне аңламый. Күп кенә предприятиеләрдә үзара мөнәсәбәтләр бөтенләй башка бит. Коммерцияле. Танышларым миңа да: «Ни өчен шулкадәр борчыласың? Үзеңнеке өчен хафаланган сыман? Бу бит синеке түгел!» – дия иде.

Ничек инде минеке түгел?! Бу бит минем дә казанышым! Бирeдә озак эшләүчеләрнең күбесе метроны үз казанышы дип саный. Чөнки аны юктан үз кулларыбыз белән булдырдык.

Әмма хәзер инде тирә-якта бөтенләй башка тормыш.

Мин «Казметрострой»да 25 ел эшләдем. Якыннарым эш һәм хезмәткәрләр өчен хәзергә кадәр ут йотканымны, аларны туганнарымны кайгырткандай кайгыртуым белән инде күптән килеште. Минем җомга кичем яки шимбә иртәм:

«Дина Семёновна, безгә бетон бирмиләр!», «Дина Семёновна, берәр нәрсә эшләгез инде! Туктарга ярамый бит!» – дип шалтыратулардан торырга мөмкин. Һәм бу гел шулай, берөзлексез. Кичем – кич, ялым – ял түгел.

Һәм мин бер тапкыр да җавап бирми калмадым. Метро – өзлексез җитештерү процессы ул. Бу объектта сигез сәгать эшләгәннән соң, өйгә кайтып китеп булмый. Кешеләр җир астында эшли. Һәм һәрвакыт уяу булырга кирәк – төрле хәл килеп чыгарга мөмкин бит. Мин ихластан ышанам: «Казметрострой» – гаилә ул. Минем гаиләм.

КАЙЧАК ЭШ КҮП, Ә КАЙЧАК – ЮК

Бездә ничек була? Кайвакыт эш бик күп, ә кайчагында бөтенләй юк. Метро файдалануга тапшырылды. Меңьеллыкны бәйрәм иткәннән соң, эш тә юк, финанслау да юк. Ярый әле 2006-2007 елларда безне Самарага чакырдылар. Анда бер тоннель казыдык. Бу безгә зур файда булды. Аннары тагын эшсезлек. Алга таба «Җиңү проспекты» расланды – тагын эш ишелде. Беркайчан да онытмаячакмын: Яңа елны каршылыйбыз, әмма Рәхимов һәм башка бик күпләр юк – алар объектта. Без алардан башка бәйрәм итә башладык. Ярты сәгатькә генә килеп киттеләр. Барыбыз да шуны яхшы белә: казу эше башланган икән, аны бер генә минутка туктатырга да, озакка игътибарсыз калдырырга да ярамый.

КЕМДЕР ШИКЛӘНӘ, КЕМДЕР ТӨЗИ

– Элек күпләр Казанда метро булачагына ышанмады. Ә сез үзегез аның булачагына ышана идегезме соң?

– Ышанмасак, без монда эшләргә килмәс идек, әлбәттә, ышандык. Без аның булачагына шикләнмәдек тә. Мин монда килгәндә, метро төзелеше турында бөтенләй берни белми идем. Финанслау, проект турында да, беренче станциянең кайсы елда тапшырылырга тиешлеге хакында да.

Бары тик 2000 нче елларда гына хәл бераз ачыкланды, вазгыять тотрыклана башлады. Тик минем метро булачагына барыбер беркайчан да шигем булмады.

Кемдер шикләнде, ә кемдер төзеде. Һәм менә без төзеп бетердек инде, ә бу шикләнүчеләр хәзер кайда?

Заказчының да әллә ни белгечләре юк иде бит. Яңа төзелеш, яңа процесс. Миңа хәтта еш кына Мәскәүгә шалтыратырга, бухгалтер буларак киңәшләшергә туры килде. Норматив документлар юк, методика үзгәрде, һәм моны ничек эшләргә, ничек рәсмиләштерергә, дигән сорауларга хәтта Финанс министрлыгында да җавап бирерлек кеше табылмый иде кайчак. Киресенчә, кайвакыт минем белән: «Дина Семёновна, ә бу ничек?» – дип киңәшләштеләр. Чөнки законнар әле эшләнмәгән иде.

Без заказчыны судка да бирдек әле. Казанның меңьеллыгын бәйрәм иттек, объектны тапшырдык, ә заказ бирүче безгә миллиард ярым бурычлы калды. Акча да, хәтта вәгъдә дә юк. Салымнар түләргә, хезмәт хакы бирергә, материаллар сатып алырга кирәк. Башта судка бирергә курыктык, тик мин үз сүземдә нык тордым. Моның безнең өчен ничек тәмамланасын беркем дә белми иде.

Суд ел буе барды. Бу турыда хәбәр Президентка барып җиткәч, мәсьәлә хәл ителде. Әгәр бу адымга барырга батырчылык итмәсәк, безне банкрот дип игълан итәрләр иде. Без юкка чыгар идек.

ҺӘР ТИЕН ИСӘПТӘ

Атна саен Рәхимовка, Казан мэры Камил Исхаковка күрсәтергә дип, эшебез турында таблицалар төзи идем. Баштарак, мэр бу таблицаларны аңлыймы икән соң, дип уйлый идем. Әмма Исхаков һәр тиеннең кая киткәнен белә иде.

Бервакыт өйдә утырам, кичке тугыз. Кинәт миңа шалтыраталар: «Эшкә кил!» – диләр. «Нәрсә булды?» «Исхаковка синең таблицаң ошамады». Иртәнге дүртенче яртыга кадәр мин шул таблицаны үзгәртеп утырдым.

> ЫШАНМАСАК, БЕЗ МОНДА ЭШЛӘРГӘ КИЛМӘС ИДЕК, ӘЛБӘТТӘ, ЫШАНДЫК. **БЕЗ МЕТРОНЫҢ БУЛАЧАГЫНА ШИКЛӘНМӘДЕК ТӘ**!

Камил Шамил улы безне контрольдә тотты, акчаның кая, күпме һәм нәрсәгә киткәнен белеп торды. Һәм безнең өчен акча эзләде.

Тагын бер очрак. Безгә ике миллиард биргәндә, Исхаков мине консультациягә чакырды. Һәм сорау артыннан сорау яудырды: «Салымга күпме? Күпме түләргә кирәк? Табыш нинди булачак?»

Мин аңа барысын да ничек бар шулай сөйләдем. Бу бит әле вазгыятькә дә бәйле. Һәм әллә ничә төрле вариант бар.

Аның белән озак сөйләшеп утырдык, болай да, тегеләй дә чамалап карадык.

ЧЫН ЭНТУЗИАСТЛАР

Безнең предприятиенең уникальлеге – башыннан алып бүгенге көнгә кадәр эшли торган кешеләр ул. Марат Муллахмәт улы биредә булганда, халык аның артыннан барачак, беркем дә хыянәт итмәячәк, барысын да эшләячәк. Өстәвенә, иң авырын – формалашу чорын - без инде барыбыз бергә кичердек.

Бу искиткеч коллектив, чын энтузиастлар – андыйларны мин башка беркайда да очратмадым.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Мөслим **ни өчен** гөлбакчага тиң

Матурлык алиһәләре бизнесны **ничек** алып бара

«Артек» балачакны **ничек** берләштерә

Камил Кәримов **ни өчен** юбилеена әзерләнми

Мөслим районы

Рамил Саламов, Александр Ефремов фотолары. Оксана Кузнецова иллюстрациясе

МӨСЛИМ: МАТУРЛЫК ИЛЕНДӘ ЯШӘҮ ҮРНӘГЕ

Татьяна Вафина

Иң матур һәм мавыктыргыч экскурсияләр, әлбәттә, Мөслимдә. Табигатькә караганнары да, ниндидер вакыйгаларга кагылышлылары да бар. Менә инде күпме вакыт халык яхшы яшәү, матур тормыш өчен ничек эшләргә кирәклеген күрергә ашыга.

Мөслим инде берничә ел элек үк ничек яшәргә һәм эшләргә дигән сорауга җавап бирү юнәлешендә үзгәреш кичерә. Ул вакытта район башлыгы Рамил Муллин иде. Бүген аның эшен Альберт Хуҗин командасы дәвам итә. Араларында Муллин белән бергә туган якны матурлый-тәртипкә кертә башлаган кешеләр бар.

УРАМДА – МАЙ

Альберт Робертович экскурсовод ролен бик теләп башкарды. Өстәвенә, табигать һәм һава торышы да бүген безне генә көткән диярсең: Мөслимдә май ае – Япониядә сакура чәчәк ату чоры кебек. Аннан да матуррак. Чөнки биредә мөмкин булган бөтен нәрсә чәчәк ата. Алсу чәчәкләр белән бизәлгән декоратив алмагачлар рәвешендәге сакуралар да. Монда тагын ап-ак чәчәкле алмагачлар, лаләләр, сирень, чия, шомырт һәм, әлбәттә инде, тузганаклар – сап-сары борчаклы яшел келәм – күз явын алырлык.

– Чүп үләне, әлбәттә, – ди башлык, тузганакларга сокланып, – чабарга кирәк. Мондый матурлыкка ничек кул күтәрелсен, ди?

Тулысынча килешәбез. Без матурлык яклы! Тузганаклы гүзәллек яклы!

БАРЫСЫ ДА ЯР БУЕН ТӘРТИПКӘ КИТЕРҮДӘН БАШЛАНА

Татарстанда парк һәм скверларны төзекләндерү Мөслим авылыннан башланган, дип саный алабыз. Менә бу «Кояшлы Ык» дип аталган яр буеннан. Яр буенда безгә очраган кешеләрдән аның озынлыгын ачыкларга тырышып карадык. Саннар шулкадәр төрле... Чаңгы таяклары белән йөрергә чыккан бер әби, чакрым тирәседер, диде. Парлашып йөрүче гашыйклар яр буеның озынлыгын 11 чакрым дип саный. Юлда очраган бер ир-ат исә безнең сораудан бер мәлгә югалып калды кебек. Әмма тиз генә күңелдән исәпләп, 16 километр, диде. Район башлыгы буларак үзенә ышанып тапшырылган территориягә кагылышлы бөтен саннарны яттан белүче Альберт Хуҗин гына нәтиҗә ясады:

– Безнең яр буе 6 километрга сузылган, Сабан туе уздырыла торган урынга кадәр. Әмма яр буен төзекләндерүне дәвам итәбез, планда – аны 11 километрга җиткерү.



ЛЭНД-АРТТАН ЫК-РОККА КАДӘР

Ләкин төзекләндерелгән алты чакрымда да күңел ачар һәм сокланыр урыннар шактый. «Лэнд-арт» Халыкара фестиваленнән калган арт-объектлар гына да ни тора! Ике елга бер мәртәбә үткәрелә торган бәйрәм район халкына да, килгән кунакларга да табигый материалдан нинди шәп әйберләр ясап булуын күрсәтә. Ә тагын биредә ел саен «Ык-рок» Бөтенроссия балалар һәм яшьләр фестивале уза.

– Менә монда, шушы кояшлы яр буенда, яшь рок-музыкантлар җыела һәм безгә барлык кунаклар таң калырлык шәп концерт күрсәтә! – Ык елгасы яры буенда яңгыраган рок авазларын исенә төшереп, хисләнеп сөйли район башлыгы. – Бу фестиваль беркемне дә битараф калдырмый. Чөнки ул Россиядә рок-музыка жанрына багышланган беренче балалар фестивале бит. Фестиваль балалар һәм яшүсмерләр рок-төркемнәренә үзләрен күрсәтергә, танытырга, фикердәшләр табарга, очрашырга менә дигән мөмкинлек бирә!

– Менә монда, шушы кояшлы яр буенда, яшь рок-музыкантлар җыела һәм безгә барлык кунаклар таң калырлык шәп концерт күрсәтә!

Мөслим районында оста куллы бер кеше яши...

ИҖАТ КЕШЕЛӘРЕ УРЫНЫ

Мөслим районында алтын куллы бер кеше яши. Илисай Имаметдин улы Имамов – агачны уеп төрле әйберләр ясаучы оста. Аның эшләре җирле музейны да, мәдәният йортын да бизи.

– Менә бу аның күптән түгел генә иҗат иткән әсәре, – ди Альберт Робертович, агач атның агач ялын сыйпый-сыйпый, – ә Илисай бабайга хәзер 93 яшь! Гомумән, Мөслим – шагыйрь, рәссам һәм башка иҗат кешеләренең яраткан урыны. Чөнки монда иҗат итәргә илһам килеп кенә тора: шәп языла, җырлана һәм укыла. Ә яр буендагы ауган матур агачны кунакларга истәлекле урын итеп күрсәтәләр – анда республиканың танылган кешеләре тынлыкта, китап укып, ял итәргә ярата икән. Агач бу функциягә идеаль туры килә – үзебез дә тикшереп карадык!

КИТАПХАНӘ ҺӘМ МУЗЕЙ

«Татарстан» журналы Мөслим китапханәсен берничә мәртәбә мактап язды инде. «Татарстан» гына да түгел. Китап укый торган урын артык зур да түгел, әмма шулкадәр уңайлы, укырга кызыксыну үзеннән-үзе уяна. Монда интернетка керәсем килә дигән уй бөтенләй тумый һәм туа да алмый.

– Балаларда укуга булган кызыксынуны сакларга тырышабыз, – ди район башлыгы. – Чөнки ниндидер вакыйгалар турында китап, газета-журнал битләрендә социаль челтәрләрдәгегә караганда кызыклырак һәм җентекләбрәк язылган. Һәм алар башыбызны эшләтергә, уйланырга мәҗбүр итә, интернетта очраган һәм һәрвакытта да файдалы булмаган мәгълүмат кебек түгел.

Башлыкның сүзләрен раслап, туган якны өйрәнү музеенда безгә Бөек Ватан сугышында катнашкан мөслимлеләр турында «Утлы еллар аша» дигән яңа китап күрсәттеләр. Сугыш кырыннан әйләнеп кайтканнарның, туган ил азатлыгы өчен яу кырында башын салганнарның туганнары сөйләгән истәлекләр тупланган бу китапта. «Яңа чыккан өченче томга авылдашларымның истәлекләрен генә тупладым», – диде китап авторы Равил Тимкин тыйнак кына. Аңа кадәрге ике томны башка авторлар эшләгән.

– Яңа чыккан өченче томга авылдашларымның истәлекләрен генә тупладым, – диде китап авторы Равил Тимкин.

Үсеп килүче буын белән истәлеккә фото.

ҖИҢҮ ПАРКЫ ҺӘМ ХӘТЕР АЛЛЕЯСЫ

Мөслимдә сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан якташларын онытмыйлар. Бөек Ватан сугышыннан алып, Әфган, Чечен кампанияләрендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар, армия елларында ВДВда, диңгез флотында, башка гаскәрләрдә хезмәт иткән мөслимлеләр һәрвакыт истә. Мондый хәтернең инициаторлары – ветераннар үзләре. Алар һәйкәлләрне дә карыйлар, шуңа күрә биредәге һәр объект – авылдашларының истәлегенә, районда зур җаваплылык белән каралган армия хезмәтенә карата хөрмәт үрнәге.

– Минә, күрәсезме, минем «Телеграм»га да язалар. Берәр нәрсә ошаса, лайк куялар, кайдадыр тәртипсезлек күрсәләр дә язалар...



Бакчалар урамында – истәлеккә фото.

КҮЗ САЛ: СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ ГҮЗӘЛ!



БАКЧАЛАР УРАМЫНДА – ИСТӘЛЕККӘ ФОТО

Гомумән, кая гына керсәң дә, кай якка гына күз салсаң да, Мөслимдә мәңгелек май кебек. Җете төсләргә, хуш исләргә бай район үзәге бөтен республика халкын үзенә җәлеп итә торган гөлбакчаны хәтерләтә кебек. Шуңа күрә бу гаҗәеп төбәкнең җитәкчесе белән фотога, әлбәттә, Бакчалар урамында, сакура төсле чәчәк аткан алмагачлар арасында төшәбез, истәлеккә калсын әле.

– Әйе, төп эшләр, әлбәттә, Рамил Хәмзә улы Муллин вакытында эшләнде, – дип искә ала районның бүгенге башлыгы. – Хәзер яр буе булган урында бик зур чүплек юкка чыгарылды. Бүген анда ташландык урын булган да кебек түгел. Ә ул чагында без, чүпчарга баткан урыннан шундый матур яр буен ясап була дип, күз алдына да китерә алмый идек! Мөслимнең үзендә дә урамнарны чистарттылар, иске гаражларны, сарайларны сүттеләр, һәр йорт алдында бакча ясадылар...

Хәзер боларның барысын да тәртиптә тотарга кирәк: чабарга, кыштан соң торгызырга, буярга, ни өчендер сүүсемнәр һәрвакыт бик тиз үсә торган сулык төбен чистартырга. Әмма мөслимлеләр инде матурлык белән сугарылган тормышны беләләр һәм үзләре шалтыраталар яки минем «Телеграм»га язалар – кайдадыр тәртипсезлек күрсәләр, сигнал бирәләр. Үзләре дә өмәләрдә һәрвакыт актив ярдәм итәләр – барысына да матур, чиста, төзек, уңайлы урында яшәү ошый. Әлбәттә, яшьләрне барыбер зур шәһәр утлары кызыктыра – яшьлек бит, нишлисең! Ләкин күбесе соңыннан кайта. Табигать законы шундый. Ә безнең гүзәл Мөслимгә кайту, килешегез, һәрвакыт күңелле.

Редакция кухнясы

БИЗНЕС КОРОЛЕВАСЫННАН БРОККОЛИ БЕЛӘН ДОРАДО

Татьяна Вафина



Әгәр гаилә мөнәсәбәтләрегездәге борылыш-үзгәрешләрнең сәбәпләрен ачыкларга телисез икән, сезгә «Тормыш һәм мөнәсәбәтләр мәктәбе» дип аталган психология үзәгенә барырга кирәк. Квалификациягезне күтәрергә теләсәгез, «Мәгариф һәм бизнес академиясе» – нәкъ менә сезнең өчен. Ә инде тегесен дә, монысын да кирәк дип тапсагыз, өстәвенә, тәмле, файдалы ризык ашыйсыгыз килсә («нәрсә ашасак, без шул» дип юкка гына әйтмиләр) сезгә эшмәкәр ханым – әлеге мәктәпкә һәм академиягә нигез салган Лилия Вәлиуллина янына юл тотасы.

«Татарстан»ның редакция кухнясында бүген ул хуҗабикә. Димәк, төрле тозлы-татлы ризыклар белән иркәләнеп беткән ашказаннарыбыз гына түгел, бетмәс-төкәнмәс көндәлек мәшәкатьләр белән тулып ашкан акыл-зиһеннәребез дә гастрономик-психологик рәхәтлек алачак.

АЗЫКНЫҢ ПСИХИК ЭНЕРГИЯСЕ

– Без брокколи белән балык һәм көнбагышлы ике яшелчә салаты әзерләрбез, – ди Лилия. – Мин ит ашамыйм, чөнки кеше аксым, май һәм углеводлардан гына түгел, психик энергиядән дә тора дип саныйм. Ә азыкның психик энергиясе бар.

Асылда, табигать безгә кирәкле бөтен нәрсәне бирә. Психологлар өчен баш миендәге ике ярымшарның да тигез эшләве мөһим. Ә баш миенең уң ярымшары еш кына эшкә җигелми торган халәттә кала, шуннан галимнәр кызыл ит куллану уң ярымшарга юлны каплый дигән нәтиҗә ясаганнар. Ә ул – мәгълүматны логик, аналитик һәм вербаль эшкәртүдән бигрәк, башкача кабул итү өчен җаваплы. Бу ярымшар интуициядә, иҗатта, эмоциональ өлкәдә, шулай ук пространствода ориентлашу һәм музыка белән сәнгатьне кабул итүдә төп рольне уйный. Кешегә кирәкле көч нәкъ менә яшелчәләрдә, яшел тәмләткечләрдә, көнбагышта тупланган. Ә хатын-кызларга коллаген, аксым кирәк. Болар

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- Дорадо балыгы – 4 данә;
- Брокколи – 1 кучән;
- Тоз-борыч – тәменчә.

Салатлар өчен:

Шпинат, черри помидоры, кыяр, авокадо, лимон, кабак төше, көнбагыш төше.

Фото: Ната Смирнова. РЕКЛАМА

барысы да балыкта бар. Шуңа күрә бүген бездә менә шундый файдалы меню.

Гомумән, мин ашарга пешерергә яратам. Еш пешеренәм, тиз әзерлим һәм бары яңа җыелган, сатып алынган продуктлар гына кулланам.

Лилия дорадо дип аталган балыкны кулына ала һәм аңа мул итеп тоз сылый.

– Мин балыкны, кетердәвек кабык хасил булсын өчен, тозда пешерергә яратам. Хуш исле булсын өчен, соңыннан балыкка яшел тәмләткечләр өстәрбез. Балыкны менә шулай фольгага төреп, духовкага куябыз.

СИСТЕМАЛЫ ЭШ АЛЫП БАРУ

– Барлык психологлар да ашау-эчү мәсьәләсендә шундый психологик алымга таянамы?

– Мин психолог кына түгел, эшмәкәр дә – ике оешмам бар, ә эшмәкәрлек – тәүлек буе мәшгуль булу дигән сүз.

«Тормыш һәм мөнәсәбәтләр мәктәбе» психология үзәгендә без кешеләргә үз-үзләрен аңларга ярдәм итәбез. Анда кеше үзенең ниндидер борчулы халәтен, эчке проблемаларын, көндәлектәге тынгысызлыкны ачыклый ала.

Ә менә «Мәгариф һәм бизнес академиясе» профессионаллар үстерүгә йөз тота. Биредә без психологлар, консультантлар, коучларны һәм шуларга ярдәмче һөнәр ияләрен укытабыз. Бизнес белән психология бергә керешеп киткән юнәлештә эшлибез: төрле компанияләрнең хуҗаларына, топ-менеджерларына, җитәкче даирәләренә даими ярдәм күрсәтәбез. Психологик белемнәрне идарә итү системасы белән берләштереп, белем бирү һәм стратегик программалар буенча укытабыз. Теләсәк тә, теләмәсәк тә, бүген психология тормышның барлык өлкәләрендә дә бар.

Җитәкче кеше һәрвакыт бизнесын көндәленә якын нәрсәләргә нигезләнеп кора. Монда мин системалы ысулга йөз тотам. Кешенең гаиләсендә нәрсә булганын карыйм. Без гаиләдә дөньяга киләбез һәм барлык программаларны шунда алабыз. Бу программа безгә компьютерның каты дискына язылган кебек язып куела. Димәк, без киләчәктә тормышыбызны, командада, коллективта мөнәсәбәтләребезне гаиләдә булган хәлләрдән чыгып төзибез. Һәм, тормыш стратегияләребезне ачыклагач, бизнеста нәрсәне дөрес эшләмәвебез аңлашыла. Ә моны аңлый башлагач, проблема җиңеләя, гадиләшә. Психологларны мин нәкъ менә шуңа өйрәтәм, чөнки кешеләр үзләренең бу системада ялгыз түгеллеген, кемнеңдер булыша алуын аңласын дип телим.

Еш кына кеше, бигрәк тә үз авыру-сызлануларына бикләнгәндә, үзен ялгыз тоярга мөмкин. Яки, киресенчә, ниндидер уңышларга ирешкәндә, кеше боларның барысын да үзе генә башкарып чыккан кебек хис итә ала.

Чынлыкта һич тә алай түгел. Тормышыбызда булган барлык катлаулы мизгелләр һәм сынаулар безне көчлерәк итә. Без яңа күнекмәләр үзләштерәбез, яңа стратегияләр булдырабыз, үз-үзебезне һәм башкаларны күбрәк аңлый башлыйбыз. Шуңа күрә «Мәгариф һәм бизнес академиясе» – психологиягә өйрәтү генә түгел, һәр әйбернең ничек төзелгәнен, ничек корылганын аңлату да, чөнки тирә-ягыбызда бөтен нәрсә дә ниндидер бер системага буйсынган.

Ә дөрес һәм яңа пешкән ризык шул исәптән безнең эчке системабызны да туендыра.

ТОРМЫШ ӨЧЕН КӨРӘШҮЧЕЛӘР БУЫНЫ

– Мин үзем – гомерем буе психолог, чөнки бала чактан ук яшәү өчен көрәшергә туры килде. Язмышым катлаулы, ләкин бик кызыклы булды. Гаиләдә хәмер кулландылар, әтием шуннан үлеп китте. Миңа 19 яшь чакта йортыбыз янып бетте. Янгында әнием һәм апам һәлак булды. Мин урамда калдым. Берүзем. 19 яшьтә.

Ә тугыз айдан соң улым туды. Ягъни кайгырту, тәрбия таләп иткән җан иясе дөньяга килде. Һәм бу миңа исән калырга ярдәм итте.

Безнең буынга һәрвакыт яшәү өчен көрәшергә, яңа тормыш шартларына җайлашырга туры килде. Һәм мин, исән калу өчен, бизнес белән шөгыльләнә башладым. Кием кибетләрем бар иде. Ләкин инде матди хәлем яхшырып, үз кибетем, фатирым, машинам, үсеп килгән улым булгач та, эчемдә ниләр кайнаганын аңламый идем. Ни өчен язмышым шундый, ни өчен ул мине шулай сыный, ни өчен миндә болай, ник тегеләй ту-

гел икәнен аңларга зиһенем җитмәде. Һәм менә шуларны ачыклау өчен, мин психолог булдым. Психологик үзәк ачу идеясе дә шулай туды, чөнки кайчандыр минем кебек үк үз-үзләрен аңлый алмаган, җыелып килгән проблема-сорауларның авыр йөген нишләтергә белмәгән кешеләргә ярдәм итәсем килде. Аларга бу турыда сөйләү оят тоела, башкалар кебек булмаганга, үзләрен гаепләргә мөмкиннәр.

Менә шушы – без башкалар кебек түгел дигән хис белән без бала табабыз, аларны тәрбиялибез, бу хисләрне алга таба илтеп тапшырабыз.

ЯЛГЫШЛАРДАН САБАК АЛЫП...

– Психологик үзәк ачкач, минем белән бергә башкаларга ярдәм итә алырлык кешеләрне өйрәтергә кирәклеген дә аңладым. «Мәгариф һәм бизнес академиясе» әнә шундый максатны күздә тотып пәйда булды.

Без психологларны укытып, дәүләт стандартындагы диплом биреп чыгарабыз. Бу – өстәмә белем бирү үзәге. Һәм мин анда психологларга үз белемемне, үз тәҗрибәмне тапшырам, шуннан соң алар үзләре дә кешеләргә башкача яшәргә булыша, дип өметләнәм.

Һәркемнең бәхетле, бай, сәламәт яшәү һәм уңышка ирешү мөмкинлеге бар. Һәм үз үрнәгемдә, үз тәҗрибәмдә шуны аңлатам: әйләнә-тирәдәгеләрнең гаепләвеннән куркып, матур «тышлык» артына нәрсәнедер яшерү, капларга, беркемгә дә күрсәтмәскә тырышу дөрес түгел.Алга таба яшәр, үсәр һәм уңышка ирешер өчен, бу хакта ачылып сөйләп бирергә кирәк. Иң мөһиме, нәкъ менә үз тәҗрибәмә таянып, мин бу белемнәрне алга таба да тапшыра алам.

Без бу белемнәрне аңга сеңдергән арада, балык 20 минутка духовкага кереп китә. Ә өлешләргә бүлгәләнгән брокколи кайнап торган суга чума.

– Озакка түгел, – дип аңлатып үтә бүгенге ашчыбыз. – Витаминнары һәм файдасы саклансын, әмма кәбестә бераз йомшаграк булсын өчен, альденте дәрәҗәсенә генә җиткерәбез.

ҖАН ТУРЫНДАГЫ ФӘН

– Минем өчен психологларның теоретик фәнни базага нигезләнүе, үзләренең нишләгәннәрен һәм кешенең психик процессларына ни өчен төшенергә тиешлекләрен чынчынлап аңлавы мөһим, – дип дәвам итә Лилия. – Шуңа күрә укытучыларны без җентекләп сайлыйбыз. Еш кына психологияне җан турында фән дип атыйлар. Тик, мөгаен, ул күбрәк кеше психикасы турындагы фәндер, психиканың төзелеше, аның ниләр эшләве, нинди үзгәрешләр кичерүе, ярсыткычларга ничек җавап бирүе, бу реакцияләрне ничек үзгәртеп булуы турындагы гыйлем. Төп белеме булмаган психологларны еш очратырга мөмкин. Шул ук вакытта практикада алар гомумән кеше психикасының ничек эшләвен аңламый. Һәм кеше нинди дер балачак травмасы тәэсиренә эләксә, яки, әйтик, ул кинәт елап җибәрсә яки калтырый башласа, нишләргә белмиләр.

Психик процессларны аңлап эш итү генә психологларга киләчәктә үзләре таяна алырлык нигезне һәм белемне бирә.

ДӨРЕС ПСИХОЛОГ

– Психологка мөрәҗәгать итәргә карар кылган гап-гади кешегә дөрес белгечне ничек сайларга? Хәзер бит психологлар – чат саен.

– Әгәр ихтыяҗ булмаса, без бу кадәр күбәймәс идек, һич арттыру түгел. Бүген кеше психология белән мавыга: нәрсәдер укый нинди дер курслар уза, марафоннарда катнаша. Бөтен кешелек дөньясының аңында глобаль үзгәреш бара. Һәм һәркемгә үз психологы табыла, кеше бит белгечне шәхес буларак сайлап бара.

Һичшиксез аның сертификатларына, белеменә дә карарга кирәк. Шуны аңлау шарт: психологның яшәү рәвеше ул тапшыра, сөйли торган төшенчәләргә туры киләме? Психологның супервизия сәгате җитәрлекме? Супервизия психологның практик эшчәнлеккә керешүен белдерә. Бу вакытта яшь белгеч зур тәҗрибәсе булган һәм үзенә ярдәм итә алырлык коллегасы – остазы янына йөри.

Минемчә, һәр кеше үз психологын табарга тиеш. Хисләрен бушатыр, аларны тоярга һәм аңларга өйрәнер өчен, атнага бер тапкыр шул психолог янына йөрергә тиеш. Бөтен пычракны, тискәре хисләрне чыгарып ташлый торган чүп чиләге итеп дус кызыңны кулланырга кирәкми. Әйе, ул боларның барысын да тыңлый һәм түзә. Бушлай.

– Бер салатны мин шпинат, томат һәм «Страчателла» сыры белән ясармын. Ә икенчесе яшел булачак. Анысында – кыяр, авокадо, салат яфраклары һәм көнбагыш төшләре.

1 Тоз сибәбез

2 Өстибез

3 Тезәбез

4 Пешерәбез

5 Бүлгәлибез

Безнең психологлар боларның барысына да өйрәтелгән. Беренче белемем буенча мин юрист, гештальт-терапиягә җиде ел укыдым, системалы терапиягә әлегә кадәр өйрәнәм. Икенче югары белемем дә бар, анысы психология өлкәсендә. Шуңа күрә шәхси терапия аша син менә шушы тотрыклылыкка һәм үз хис-кичерешләреңне генә түгел, ә башкаларнықын да күтәрә белергә өйрәнәсең.

– Сездә психолог һөнәренә кемнәр укый ала?

– Бездә юристлар да, икътисадчылар да, массажистлар да укый. Психологияне белү төрле һөнәрләрдә кирәк. Менә журналистларны гына хәтерләмим. Мөгаен, бу журналистлык эшенең үзенчәлегедер – алар сенсация ясарга, укучыны шаккатырырга омтыла. Кызыклы нәрсә язып, җыелган материалдан нәрсәнедер тартып чыгарып, аны ничектер борып җибәреп, укучыны/тамашачыны әләктереп аласы, игътибарын җәлеп итәсе килә. Алар мәкаләдә сүз барган кешенең соңыннан үзен ничек хис итәчәге турында уйлап та карамый. Бәлки, шуңа күрә бездә әлегә журналистлар булмагандыр.

Белем алучыларның башкалары психологик белемнәрен үз һөнәрләренә кертеп-кушып җибәрә.

РОЛЬЛӘРНЕ БУТАМАГЫЗ!

– Табиб кеше берәр юбилейга яки бәйрәмгә килгәч, кунаклар аның һөнәре турында белеп алгач, киңәш ишетергә яки түләүсез консультациягә өметләнеп, аңа авырулары турында сөйләп бирергә тырыша. Сезнең һөнәрегездән шулай тәкәллефсез файдаланырга теләүчеләр бармы?

– Әлбәттә, бар. Без үз һөнәребезне читкә куеп тора алмыйбыз. Әмма психологка үз танышларына психотерапия сеанслары ясамаска түгел, ә рольләрне аерырга өйрәнергә кирәк. Һәм рольдән чыга белергә. Әгәр гаилә бизнесы алып барабыз һәм мин ирем җитәкләгән эш урыныма килеп утырам икән, анда үземне өйдәге кебек тота алмыйм. Монда – төрле рольләр, төрле функционал.

Яки менә мондый мисал: хатын ирен әнисе кебек тәрбияли, аның белән идарә итә башлый, контрольдә тота, әйтик, урамга чыкканда бүреген кияргә куша. Бу күренеш котылгысыз рәвештә конфликтка китерә. Чөнки алар бала – ана ролендә булганда, ир белән хатын рольләреннән чыга. Шуңа күрә монда үз ролеңнең чикләрен аңлау мөһим. Бу эш урынындагы вазыйфаи инструкцияләр кебек. Менеджерның бурычлары бертөрле, дизайнерныкы – икенче. Ә без чит рольләргә, чит территорияләргә керә башлагач, кыенлыклар туа һәм низаглар килеп чыга.

БИЗНЕС КОРОЛЕВАСЫ – 2025

– Сезгә бизнес алиһәсе ролен башкару ничегрәк?

– Беләсезме, мин бу конкурска бөтенләй барырга җыенмаган идем. Беренчедән, вакыт юк. Икенчедән, сәхнәдә спикер булып тору – бер нәрсә, ә үзеңнең «күңелеңдәге кыз»ны халыкка чыгару – бөтенләй башка. Куркыныч булды. Һәм хәтта «әйе, мин үземне сынап карыйсым килә» дигән теләкне тану да куркытты. Шунда дустым Ольга Глухова: «Лилия, бу сиңа кирәк!» – диде. Һәм мине уятып җибәргәндәй булды. Мин королева булу-булмавым турында уйламадым. Бу минем өчен күңелдәге: «Ә миңа нәрсә ярый?» – дип сорый торган баланы тышка чыгару иде. Чөнки янгыннан соң урамда калган, тормыш авырлыкларына түзәргә мәҗбүр булган кыз моңа лаек түгел кебек иде. Мин шунда, сәхнәдә торганда, лаеклы икәнемне аңладым.

Һәм әлеге чыгышымнан шулкадәр иҗади, креатив энергия алдым, ул эшебезгә дә уңай йогынты ясады. Әгәр шәхси тормышта, гаиләдә матур хис-тойгылар белән яшәвебезне, үзебезне бәхетле булуыбызны һәм тормышыбызның уңай баруын тоябыз икән, әлеге позитив энергияне һичшиксез эшебезгә дә кучерәбез. Эшебездә барысы да шәп икән, без моны гаиләбезгә дә алып кайтабыз. Конкурс минем өчен нәкъ менә шундый – башкалар белән бүлешү теләге янып торган илһам чыганагы булды.

«Бизнес королевасы» титулын алганда, миңа бик күңелле һәм рәхәт булды. Хәзер минем таҗым бар, һәм мин «Миссис Бизнес Россия» бәйгесенә барам.

ГАИЛӘМЕ, БИЗНЕСМЫ?

– Сезгә кайсы якынрак: гаилә психологиясеме, әллә бизнес-психологияме?

– Икесе дә. Эшмәкәрләрдә еш күренеш: әгәр аның бизнесы начар икән, гаиләсендә дә эшләр мактанырлык түгел. Яки киресенчә. Һәм без гаиләдәге мөнәсәбәтләрне җайга салганда, бизнес та алга китә. Шулай да була ала: кеше бизнеска бик күп игътибар бирә һәм мөнәсәбәтләрдән көч ала һәм, аны тәмам сарыф итеп, ялгыз кала. Ир-ат, мәсәлән, барысына да ирешкән, ди, үзенә хәтта Тын океанда утрау да сатып ала, әмма сәламәтлеген югалтырга һәм комада ятарга мөмкин.

Яки бу ир-ат шикәр чиреннән интегә һәм үзен бәхетле хис итми. Эшнең асылы – шушы мизгелдә бәхетле булуда, чыннан да ләззәт

6 Пешерәбез

7 Кыздырабыз

8 Кушабыз

китерә һәм үзеңә ошый торган нәрсәне эшләүдә. Эш булсын өчен генә эшләүнең бәхет түгеллегенә төшенергә кирәк. Ир кеше бит хатын-кыз өчен, хатын-кыз хакына эшли. Нәкъ менә хатын-кыз теләкләре аны югары үрләргә ирештерерлек двигательгә әйләнә. Ә иң кызыгы: хатын-кыз – үз халәтенә таянып, аңарга нигезләнеп, ә ир-ат исә шул халәткә ирешер өчен эшли. Хатын-кызны яратканда һәм кадерләгәндә, ир-ат аңа күктән айны алып бирергә риза. Һәм ул айны алачак та, чөнки хатын-кыз теләкләре – ирләр өчен этәргеч, көч-куәт чыганагы. Бу – традицион модель, ул безгә табигатьтән салынган. Шул ук вакытта һәрберебезнең кабатланмас үз юлы да бар.

БӘХЕТНЕҢ ТӨП ТОЙГЫСЫ

– Бәхет турында сүз чыккач, шул хакта сорыйк әле. Ничек бәхетле булырга? Бу уңайдан сездә нинди дә булса универсаль психологик киңәш бармы?

– Менә хәзерге мизгелдә бәхетле бул, чөнки моның өчен бездә табигать биргән бөтен нәрсә дә бар. Без күбрәк үзебездә булмаган нәрсәләргә карыйбыз, әмма булганны күрмибез. Рәхмәт хисе – бөтен нәрсәгә ачкыч. Минем күзләрем бар, алар күрә. Минем аякларым бар, алар йөри. Минем чәчләрем, матур гәүдәм, якын кешеләрем бар – мине бәхетле итәрлек күп нәрсә бар. Ләкин без булмаган нәрсәгә карыйбыз. Мәсәлән, мин кияүдә түгел, шуңа күрә бәхетсезмен. Миллион долларым юк, шуңа күрә мин бәхетсез. Шәп машинам юк, шуңа күрә мин бәхетсез.

Ләкин чынлыкта бәхет күңелебездә утыра бит. Тәмле ашадың, шуннан ләззәт алдың, һәм бу – кыска вакытлы бәхет. Үзең өчен кадерле кеше белән очраштың, аралаштың – икегез дә бәхетле. Эчке бәхет тойгысы күңелебездә бар, ул яши. Ләкин безне аңардан файдаланырга өйрәтмәгәннәр, чөнки ата-бабаларыбыз җәфа чиккән, алар безгә җәфаланып яшәү тойгысын геннар аша тапшырган. Авырлык белән яшәү серен биргәннәр, ә бәхет серен – юк. Ә бит тик торганнан гына ләззәт алырга, булганнан канәгатьлек хисе тоярга, шатлык-куанычың белән уртаклашырга, гади генә әйберләрдән дә рәхәтлек кичерергә мөмкин.

Мин Һиндстанга еш барам. Анда коточкыч фәкыйрьлек, тик мин бу илдә ләззәт алам, чөнки Һиндстанда кешеләр бәхетле. Алар беркая да йөгерми, ашыкмый, әллә кая омтылмый, бик тыныч. Анда бездәге кебек күзләрне тондырып, максатыңа барудан торган, бар булмышыңны үзенә суырып ала торган чоңгыл юк. Анда үз-үзең булып яши аласың. Һәм бу халәт минем кем булуымны, ни өчен биредә булуымны, гади бер кеше икәнлегемне искә төшерү өчен гаять мөһим. Асылда, без барыбыз да тигез икәнлекне аңлау миңа бик зур энергия бирә. Моны бик гадиләштереп, дөньяга ялангач һәм бернәрсәсез килгәнбез, шулай китәбез дә, дип әйтергә мөмкин. Без ни өчен киләбез? Тормышның мәгънәсе нәрсәдә? Күпкә тирәнрәк рухи төшенчәләрдә. Алар турында мин үз курсларымда һәм дәресләремдә сөйлим.

Шушы матур урында без балыкны духовкадан чыгарып, өстәл әзерлибез һәм шул мизгелдәге кечкенә генә бәхет порциясен алабыз. Безгә тәмле дә, рәхәт тә, моның өчен бүгенге ашчы-психологыбыз Лилия Вәлиуллинага зур рәхмәт.

МИН ҺИНДСТАНГА ЕШ БАРАМ. АНДА КОТОЧКЫЧ ФӘКЫЙРЬЛЕК, ТИК МИН БУ ИЛДӘ ЛӘЗЗӘТ АЛАМ, ЧӨНКИ ҺИНДСТАНДА КЕШЕЛӘР БӘХЕТЛЕ. АЛАР БЕРКАЯ ДА ЙӨГЕРМИ, АШЫКМЫЙ, ӘЛЛӘ КАЯ ОМТЫЛМЫЙ, БИК ТЫНЫЧ. АНДА БЕЗДӘГЕ КЕБЕК КҮЗЛӘРНЕ ТОНДЫРЫП, МАКСАТЫҢА БАРУДАН ТОРГАН, БАР БУЛМЫШЫҢНЫ ҮЗЕНӘ СУЫРЫП АЛА ТОРГАН ЧОҢГЫЛ ЮК.

ТОРМЫШНЫҢ ИҢ ӨМЕТСЕЗ ЧОРЫНДА
БИЗНЕС ТУА

Николай Крушинин

Аның тарихы идәнгә матрас җәеп яшәгән 15 метрлы бүлмәдән башлана. «Ул чакта мин әле биш-алты елдан соң бу урынның шәхси косметика лабораториям булачагы хакында уема да китерми идем», – дип искә ала Рита Хәбирова. YARATAM натураль косметика линиясенә нигез салучы ул.

– Мондый тарихлар илһамландыра һәм канат куя. Димәк, сез, Рита, үзегезнең язмышыгыз турында сөйләп, күпләргә бизнес ачуда һәм тормышта үз урыннарын табуга үрнәк бирә аласыз...

МИНЕМ ШӘХСИ НУЛЕНЧЕ КИЛОМЕТРЫМ

– Миңа 28 яшь һәм тормыштагы иң зур өметсезлек вакытында алдыма куйган максаттан башка бернәрсәм дә юк иде, – дип искә ала Рита. – Ресурслар да, тәҗрибә дә, акча да. Хыялымны чынга ашыра башлау юлында ул чак минем шәхси нуленче километрым иде. Ә хыялым – беренче милли косметика брендын булдыру.

Краснодар төбәгендә, Анапада яшәгән чагым. Туган ягым – Казаным бик нык сагындыра. Традицияләр, үз нәселеңә тугрылык, кешеләрне ярату – болар минем өчен һәрвакыт бик әһәмиятле төшенчәләр иде. Шуңа, күрәсең, YARATAM брендында аларны чагылдырырга тырышканмындыр да.

– Бренд ничек барлыкка килде?

– Ике ел дәвамында алны-ялны белмичә эшләдем. Кухняда, сеңлем белән бергәләп, крем ясап карау да калмады, беренче хезмәткәрне эшкә алган мизгелне дә һич онытасым юк, тәүге лабораториябезне ачкан көнне дә... Без әле анда кремнарны кулдан җитештерә идек, инде алар Россиянең 23 шәһәрендә сатылса да. Бердәнбер фатирыбызны саткан мизгелне дә бик яхшы хәтерлим, ә аңа алмашка яңа җитештерү җиһазлары белән цех пәйда булды!

Фото Рита Хәбирова архивыннан. РЕКЛАМА

ҮЗ ФӘЛСӘФӘСЕ ҺӘМ ЯРАТУ ЭНЕРГИЯСЕ

– Ә хәзер ничек?

Бүген, инде өч ел узганнан соң, минем кулланышта 1800 квадрат метрлы цех һәм 70 хезмәткәр бар. Хезмәткәрләр барысы да КИТТУ-КХТИның косметика технологияләре кафедрасы белән Казан медицина университетының фармацевтика факультетын тәмамлаган. Без өзлексез камилләшәбез: онлайн укулар узабыз, бөтенроссия күләмендә билгеле косметика брендларын булдыручы технологлардан белем үзләштерәбез, аларның тәҗрибәсен өйрәнәбез. Үзебезне дә тәрбиялибез, бьюти-индустриядә нинди яңалыклар пәйда булуын күзәтеп барабыз. Һәм ике сменада YARATAM косметикасын җитештерәбез. Шулай ук контракт буенча матурлык салоннары, масс-маркетлар, атаклы блогерлар, кибетләр челтәре өчен дә бренд әзерлибез. Бөтен Россия өчен! Теләсә кем, безгә мөрәҗәгать итеп, косметикага заказ бирә ала.

Бер көн эчендә 8000 нән артык берәмлек продукция сатабыз, аларның һәркайсының үз фәлсәфәсе һәм энергиясе бар. Болар – битне һәм тәнне тәрбияли торган кремнар да, шампуньнар белән бальзамнар да, юыныр өчен гельләр дә, тирене чистарту өчен кирәк-яраклар да...

– Казаннан кала, сезнең косметиканы тагын кайларда беләләр?

– Халыкара күргәзмәләрдә еш катнашабыз, үзебезнең Россия косметикасын Казахстанда, Дубайда, Кыргызстанда, Төркиядә тәкъдим иткәнебез булды. Казанда хәзер татар ДНКсы белән спа-салон төзибез, анда традицияләр белән заманчалык бербөтен булып кушылачак!

МИСС БИЗНЕС – 2025

– Сез Татарстанда узган «Мисс Бизнес – 2025» бәйгесенең җиңүчесе...

– Һәм хәзер «Мисс Бизнес Россия» бәйгесендә катнашырга җыенам, анда Татарстанны тәкъдим итәчәкмен. Башта бу хакта уйламаган да идем, әмма коллектив мине катнашырга өндәде, күндерде.

Хыялыма юлым үземне хатын-кыз, кеше буларак үстерү аша да, бизнеста үз урынымны табу аша да булды. Болар әһәмиятле һәм файдалы продукт җитештерергә дә булышкандыр, дип уйлыйм. Хәзерге көндә үз эшен башлаучы эшмәкәрләр, бизнес-җәмәгатьчелек өчен остаз буларак та чыгыш ясыйм, ментор ролен үтим.

МӘХӘББӘТ МИССИЯСЕ

Бүгенге көндә минем миссиям – косметика җитештерү һәм сату гына түгел, ә халкымның милли-мәдәни мирасын сакларга, аны башкаларга җиткерергә омтылу да. Бу максатка ирешер өчен, тулы бер юнәлеш булдырырга телим. Бизнес аша мин татар халкының кыйммәтләре белән традицияләрен дә кире халыкка кайтарам бит. YARATAM косметикасын бүләк итү – «Мин сине яратам» дип әйтүгә тәңгәл.

– Ә ни өчен крем аша... мәхәббәт аңлату кирәк?

– Без ярату турында бик аз сөйләшәбез. Һәм аз яратабыз да. Газиз кешеләребезне бик аз кочаклыйбыз, үбәбез. Әниләребез, бигрәк тә СССР чорында тәрбияләнгәннәре, хисләрен тышка чыгарырга күнекмәгән. Балаларына карата да хәтта. Ул чакта бу табигый дип кабул ителмәгән булганга, күрәсең. Шәхси тойгылар җәмгыять таләп иткән нәрсәләрдән түбәнрәк, икенче пландарак дип уйларга ияләшкән халык. Ә безнең косметика бу кануннарны үзгәртә ала. Без җитештергән барлык линияләр дә – яраткан кешеләребезгә, туганнарыбызга, балаларыбызга, бар дөньяга һәм, әлбәттә, тәнебезгә мәхәббәт аңлату ул.

ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ САКЛАУ

– Конкурентлар сезнең идея, технология, җитештерү үзенчәлекләрен үзләренә алырга тырышмыймы?

– Косметика җитештерүчеләр, әлбәттә, күп. Әмма һәркемнең – үз урыны, рецептурасы, идеясе. Шуңа мин безне конкурентлар дип исәпләмим. Без бер-беребезне тулыландырабыз гына. Һәм, әлбәттә инде, үзебезнең сатып алучыны эзлибез. Ә ул безнең косметиканы үзенә туры килә, дип тоя икән, башканыкын эзләмәячәк.

– Сез моңа ник шулай нык ышанасыз?

– Чөнки бездә – бары тик үзебезнең Татарстанда гына үсә торган үләннәрдән ясалган уникаль рецептура. Безнең миссиябез дә кабатланмас – традицияләрне саклау. Без сыйфат ягын гел контрольдә тотабыз, бу еллар дәвамында шулай. Мин моны сезгә химик-технолог буларак әйтәм. Алай гына да түгел, ә ярлылыкның ни икәнен белгән һәм хәзерге көндә бизнес белән матурлык шаһинәсенә әверелгән Көлсылу буларак та әйтәм...

– Сезнең үрнәк башкаларга да илһам бирсен! Т

Фото Лицей – инженерлык үзәге архивыннан. РЕКЛАМА

ЗУР МӨМКИНЛЕКЛӘРНЕҢ «КЕЧКЕНӘ МӘКТӘБЕ»

Хезмәт дәресе бара. Беренче сыйныф укучылары зур кызыксыну белән «Фанкластик» конструкторы модельләрен үзләштерә. Тәнәфескә кыңгырау чыңлаганчы, яшел һәм сары блоклардан, тәгәрмәч һәм «передача»лардан тырыша-тырыша машина җыялар. Беренче сыйныф өчен конструктор шактый катлаулы, әмма балалар аны башкарып чыга. Әле дәрес башланганчы ук меңәрләгән детальне мөгаллимнәр тиешле тәртиптә махсус тартмаларга салып куйган. Югыйсә аларны актарып, эзләп табуга вакыт сарыф итсәләр, болай тиз эшли алмаслар иде.

Казандагы Intellectual Linguistic School (ILS) инде унөч елдан артык нәнә шундый кулдан идарә итү режимында эшләп килә. Шуларның 10 елы дәвамында алар – Лицей – инженерлык үзәге структурасында. Шунысын да әйтеп узарга кирәк: киләсе елда укырга керергә тиешле беренче сыйныфларның яртысыннан артыгы – ILS ны тәмамлап чыккан кызлар-егетләрнең сеңелләре һәм энекәшләре. ILS директоры Эльмира Митрофановага «мәктәп» дип атала торган әлеге катлаулы конструкторны җыеп тотарга нәрсә булыша? Ни өчен биредән гаиләләр белән китәселәре килми һәм яңа буыннарны да укырга кертергә омтылалар?

ҮСКӘЧ КУЛАЙ БУЛАЧАК МОДЕЛЬ

Башлангыч сыйныфтан соң, күп кенә укучылар дүртенчегә Лицей – Инженерлык үзәгенә бара. Мәктәпләрнең мәгариф модельләре бертөрле – көннең беренче яртысында балалар ФГОС программасын үзләштерә, икенчесендә инде – өстәмә белем бирү программасын.

«Кечкенә мәктәп»тәге өстәмә белем бирү программасы шулай корылган: бала дүртенче сыйныфтагы гади, блоклы программалаштырудан бишенчедә инде популяр «өлкән» телдәге программалаштыру нигезләренә күчә, ягъни – инженерлар программасы мохитендәге 3D–рәсемнәрдән 3D–проектлауларга кадәр һәм тагын башка ысулларга да.

Бер үк вакытта, «Кечкенә мәктәп» Лицей кабул иткән үсеш стратегиясенә нигезләнеп эшли. 2024-2027 елларга исәпләнгән стратегия офыкларның аръягында булган киләчәккә йөз тота. Ул югары сыйныф укучыларын аэрокосмос, ясалма фәһем, цифрлы игезәкләр, мәгълүмати куркынычсызлык, БПЛА, тотрыклы үсеш, икътисад һәм хокук кебек өлкәләрдә файдалы булырдай итеп әзерли.

– Яңа стратегиягә бәйле рәвештә, без олимпиада өчен математика дигән махсус курс керттек. Чөнки математиканы яхшырак үзләштергән

балага программалаштыру да җиңелрәк биреләчәк. «Фанкластик»ны да өстәдек. Әлеге конструктор кечкенәләргә пространствоны тоярга һәм техник фикерләү сәләтен үстерергә бик яхшы ярдәм итә, – ди Эльмира Митрофанова.

КЕЧКЕНӘ ЭКСПЕРИМЕНТЛАР КӨЧЕ

Сез моңа кадәр металл коррозиясенең шактый эре фаҗигаләргә сәбәпче булганын беләидегезме? Әйтик, подшипниктагы коррозия нәтиҗәсендә 1967 елда АКШта Огайо елгасының ике як ярындагы штатларны берләштереп торган «Көмеш күпер» җимерелеп төшә. «Кечкенә мәктәп»нең өченче сыйныф укучысы Святослав Деревянных әлеге күренеш турында бик күп фактларны ачыклап кына калмый, экспериментка таянып, цинк нигезендә эшләнгән матдәләрнең металлны коррозиядән барысыннан да яхшырак саклавын да билгели. Бу хакта яшь тикшеренүче «Минем беренче ачышларым» конференциясендә сөйләгән. Әлеге конференция ILS да быелгы елдан уздырыла башлаган икән.

– Без баланы үзен иҗатта, фәнни тикшеренүләрдә, аралашуда сынап карарга, тәҗрибә тупларга өндибез. Монда үзеңә нәрсә кызыклы, шуны эзләп табарга була. Төрле рольләрне сынап карарга. Ә инде кайсы кулай икәнен ачыклагач, акрынлап үз мөмкинлекләреңне билгеләргә, аларны ничек үстерергә икәнен аңларга. Бездә – рәхәт, куркынычсыз мохит, монда балага ялгышудан куркырга кирәкми, киресенчә, үзен төрле яклап сынап карап кына бала иң дөрес юнәлешне таба ала. Димәк, бу өлкәдә зур уңышларга да ирешәчәк, дигән сүз. – Эльмира Митрофанова моңа тулысынча инанган.

Бу инануның нәтиҗәсе дә күзгә күренеп тора. Биредә уздырылган бәйрәмнәр белән тематик чараларның шаһиты булган һәркемгә. Номерлар һәрвакыт үзенчәлекле, кызыклы, ә балаларны биләп алган дулкынлану белән шатлык хисләре, тантана – ихлас. Алар бу хисләр ташкынын залга – килгән тамашачыларга да бүләк итә.

ҺӘРКЕМ ДӘ ИРЕШӘ АЛА ТОРГАН УҢЫШ

Әлеге мәгариф моделенең уңышлылыгын статистик ысул белән билгеләп карарга мөмкин. Әгәр 2017–2018 уку елында ILS укучылары шәһәр, республика һәм федераль олимпиада һәм бәйгеләрдә 84 мәртәбә призёр булса, 2023–2024 уку елында бу сан инде 281 не тәшкил итә. Мәктәп укучыларының дүрттән өче – шәһәр, төбәк, бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларның даими катнашучылары. Төрле дәрәҗәдә – «Русский медвежонок»тан башлап, комплекслы метапредметлы бәйгеләргә кадәр. Теләгенә карап, укучы юнәлешләрнең берничәсен дә сайлый ала.

– Без балаларны олимпиадаларга беренче сыйныфтан ук җәлеп итәбез, аларга юнәлеш сайларга, бурычларның асылына төшенергә булышабыз. Тора-бара бала фикер йөртү, мәсьәләләрне чишү кебек акыл процессыннан үзе үк тәм табарга өйрәнә. Ә аннары инде – үзе ирешкән нәтиҗәләрдән дә, – дип сөйли

югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы, башлангыч сыйныфларның методберләшмә җитәкчесе, «Сәләтле бала» программасы кураторы Татьяна Майорова. – Бездә җиңүче балаларны линейка вакытында бүләкләү традициясе дә бар. Уңышка ирешүнең һәркем өчен дә мөмкин булуын күрсәтәбез. Бу илһамландыра, баланы үзенә ышанырга өйрәтә.

Сүз уңаеннан, бу елны дүртенче сыйныф укучылары Айлин Сафина белән Елизавета Заһретдинова математика белән тормыш иминлеге нигезләре буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы призёрлары булган. Югары мәктәп өчен дә – җитди нәтиҗә, ә кечкенәләр өчен – олы җиңү.

ТЕЛ УЛ – КИЛӘЧӘК КҮНЕКМӘСЕ

Технологик трендларга йөз тотып, «Кечкенә мәктәп» «лингво + техно» принцибына тугры кала. Монда телләргә зур әһәмият бирелә: инглиз, немец, кытай телләре өйрәнелә. Аларны балалар беренче сыйныфтан үзләштерә. World around us алган белемнәр белән әйләнә-тирә мохитне берләштерсә, көннең икенче яртысында инглиз телендә сөйләшүче тьюторлар белән аралашу телнең табигый җирлеген тудыра. Бәлки, шуңа да «Инглиз телендәге театр» клубында ел саен шедевр дәрәҗәсендәге спектакльләр туа, һәм алар төрле дәрәҗәдәге балалар иҗат бәйгеләрендә призлы урыннар яулый. Соңгы шаккатырган хитлары – «Алиса Могҗизалар илендә».

– Технологияләр бүгенге көндә телне белмичә дә аралашырга мөмкинлек бирә. Әмма күз алдына китерегез: әлеге технологияләр кинәт кенә сафтан чыкты, ди, ә сез – чит илдә, башка тел мохитендә, гаять әһәмиятле очрашуда, – ди Екатерина Гаврилова. – Иң беренче чиратта, без балаларны дөньякүләм аралашу технологияләрен үзләренең булачак һөнәрләре өлкәсендә эшләү вакытта кыенлык тумаслык итеп үзләштерергә өйрәтәбез.

ЫШАНЫЧ ПЕДАГОГИКАСЫ

РФ мәгариф министры Сергей Кравцов, 2030 елда Россиядә укытучыларга кытлык 40 меңгә җитәчәк, диде. ILS бу ситуациянe дә истә тота һәм педагогларга алмашны яшьтән әзерләүне гамәлгә кертә. Алар Казан педагогика көллияте белән тыгыз элемтәдә тора. Әйтик, Юлия Денисова дүрт ел элек мәктәпкә педагогик практика узар өчен килгән булган, ә бүген инде аның беренче чыгарылышы, ILS ны тәмамлап, лицейның бишенче сыйныфына аяк атларга әзерләнә. Бу вакыт аралыгында Юлия «Педагогик дебют – 2024» бәйгесендә җиңүче булырга, «Безнең яңа укытучы» федераль проекты грантын һәм белемен күтәрер өчен Казан мэры грантын алырга өлгергән.

Сере нидә дисезме? Лицейга укытырга килгән белгечләр үзләрен эш урынына гына түгел, ә инде тәмам оешып өлгергән бердәм гаиләгә эләккәндәй хис итә. Монда аларга ярдәм кулы сузарга да, ышаныч күрсәтергә дә әзерләр.



– Үземне зур команданың бер өлеше итеп хис итәм. Лицей инициативаларны тормышка ашырырга да булыша: миңа проектлар эшләргә мөмкинлек бирәләр, идеяләр тәкъдим итәләр, чараларда катнашырга җибәрәләр. Бу үз көчеңә ышаныч һәм алга таба да үсәргә омтылыш тәрбияли, – дип ургаклаша Юлия. – Мин үз укучыларымны бердән башлап, дүртенче сыйныфка кадәр җиткердем. Бу – һөнәремдәге һәм тормышымдагы бик әһәмиятле этап, күңел биреп эшләгән профессиональ юнәлешемнең чын мәгънәсендә нәтиҗәләре.

БЕРГӘ – БУ БЕЗНЕҢ ТУРЫДА!

«Дәрес югары методик дәрәҗәдә узды», – ачык дәресләрдән соң, ата-аналар әнә шундый комментарийлар калдыра. Бер телдә сөйләшергә омтылу – биредә һәркем шуңа көйләнгән. Балалар белән ышаныч телендә аралашу, уен методикаларын куллану (бигрәк тә 1-2 сыйныфларда), ата-аналар белән даими элемтә булдыру, укыту һәм тәрбия мәсьәләләрендә гаиләләргә ярдәм күрсәтү – Юлия Денисова һәм ILS ның башка педагоглары өчен төп ориентирлар менә шулар.

– Башлангыч мәктәп, аеруча укырга керү һәм беренче сыйныфта белем ала башлау – балаларның да, ата-аналарның да бу процесска иялəшүендәге иң әһәмиятле этапларның берсе. Шуңа күрә, гомуми җыелышлардан тыш, беренчеләрнең әти-әниләре белән аерым очрашулар да уздырам. Алар берәр сәгатьләп дәвам итә, кайбер вакытта озаграк та. Без баланың уңышлары һәм әле бик үк булдырып җиткермәгән яклары турында сөйләшәбез, аның мөмкинлекләрен һәм кайсы юнәлешне сайлый алуын уртага салып хәл итәбез. Мәктәптә дә, өйдә дә балага мөмкин кадәр файдалы, уңайлы мохит тудыру турында гәпләшәбез, – ди Эльмира Митрофанова. – Мессенджерларда язышу гына җитми – алар шәхси араләшуны алыштыра алмый. Индивидуаль очрашып сөйләшү вакытында ата-ананың шик-шөбһәләре тарала, борчулары кими төшә. Ул үзен тыңлаганнарын ишетә, педагогларның аның баласына ярдәм итәргә теләүләрен аңлый, арада киртәләр юклыгына инана. Димәк, ышаныч бермә-бер арта.

ӘКИЯТТӘН НӘРСӘ КАЛА?

– Ата-аналарның хыялы буенча, башлангыч мәктәп балалар бакчасының табигый, хәвефсез дәвамы булырга тиеш. Бездә бу җәһәттән барысы да бар – уңайлы шартлар, тыныч мохит, балаларны кайгырту һәм, әлбәттә инде, белем бирүнең югары дәрәҗәсе. Иң зур плюс – гаилә өйдә дәрес әзерләтүдән азат. ILS безне тулаем канәгатьләндерә, – ди «Кечкенә мәктәп»нең ике чыгарылышында да балалары укып



чыккан әни Янина Костычева.

– Мәктәптә өйдәге кебек җылы атмосфера. Педагоглар коллективы белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләр дә гаиләдәге кебек. Шуңа мин дә, күпчелек башка ата-аналар да башлангычларны биредә югары дәрәҗәдә укыту һәм тәрбияләүләренә тулаем ышанабыз, – ди Регина Айметдинова. – Боларга өстәп, миңа әле тагын ата-аналар өчен әзерләнгән чаралар бик ошый, аларда гел күңел тулып утырасың.

«Кечкенә мәктәп»тәге дүрт ел, әнә шулай итеп, белем алу һәм төрле кызыклы вакыйгалар дулкыны эчендә сизелми дә узып китә. Балалар үзләре белән урта мәктәп этабына ниләр ала соң? «Алиса Могҗизалар илендә» аудиоспектаклендәге атаклы бер җырда җырланганча, «әкиятне сөйләгәннән соң, нәрсә кала?»

– Дуслар, укытучыларым белән яхшы мөнәсәбәтләр, алар безгә биргән белем – башлангыч мәктәп миңа әнә шуларны бүләк итте, – ди ILSның быелгы чыгарылыш укучысы Аделина Әбделхакова. – Монда без акыллы, зирәк, мәрхәмәтле булырга өйрәндек. Бер-беребезне аңларга, хәленә керергә, ә иң мөһиме – теләсә нинди ситуациядә дә Кеше булып калырга.

Аделинаның сеңлесе дә быел ILSның беренче сыйныфына бара икән. Аның өчен әкият әле башлана гына.

Кадерле Эльмира Ревнеровна!

Юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз!

Җитәкче булу – һава шартлары нинди генә булуга карамастан, алган курска ышаныч белән бару һәм башкаларны да алып бара белү ул. Сезнең кебек җитәкчегә әлеге сыйфатлар хас. Сез, һава торышының нинди булуына да карамастан, ерактагы офыкны күрәсез, башкалар гадәти генә дип исәпләгән вакыйгалардан һәрчак мәгънә табасыз. Сезнең мәктәбегез – ул үсеш һәм ышаныч мохите. Һәм боларны Сез көн саен тырыш хезмәт белән булдырасыз: нәни генә детальләргә игътибар итеп, вак-төякне иң мөһим эшләрдән аерып куя белеп, олы максатларга ирешкәндә дә кешелек кыйммәтләрен саклап калып.

Сез илһамландыра, берләштерә, идеяләргә җан өрә һәм аларны тере эшлекле процесска әверелдерә торган искиткеч сәләткә ия. Тирән белем, зирәклек, затлылык Сезне яхшы җитәкче итеп кенә калмый, ә Сезгә охшарга омтылыш та уята.

Сезгә көч-куәт, сәламәтлек телибез! Тормышыгыздан ямь-тәм табып, алга – бик еракка карап, дөрес юлны, кыйбланы күрә белү сәләтен җуймыйча озын-озак яшәгез!

Ә без, зур ихтирам, рәхмәт һәм җылы ярату хисләрен җиткереп, һәрчак янәшәгездә булырбыз!

Лицей - инженерлык үзәге коллективы

ИДЕЯДӘН ӘЗЕР ПРОДУКТКА КАДӘР:

ТАТАРСТАН УКУЧЫЛАРЫН ЭШКУАРЛЫК НИГЕЗЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТӘЛӘР

Евгения Чеснокова

Төрле бизәкләр төшерелгән уңайлы шоперлар, сәйлән чигелгән нәзакәтле сумкалар, кулдан эшләнгән сабыннар, хайваннар өчен киемнәр, ротангтан эшләнмәләр... Казанда узган мәктәп бизнес-компанияләре слётында Татарстан укучылары үз куллары белән ясаган төрле продукцияне тәкъдим итте. Шунда ук «Мәктәп бизнес-стартры» проектының чираттагы сериясенә йомгак ясалды.

МИДХӘТ ШАҺИӘХМӘТОВ, ТР Премьер-министры урынбасары – икътисад министры:

– «Мәктәп бизнес-стартры» проекты Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча гамәлгә ашырыла. Программа республиканың барлык районнарын колачлый, зур булмаган торак пунктларда яшәүче мәктәп укучылары да катнаша. Өч ел эчендә анда 34 меңнән артык бала үз сәләтен күрсәтте. Балалар уен форматында үзләренең проектларын үстерү һәм аны аудитория каршында яклау күнекмәләре, компетенцияләр ала. Бу исә киләчәктә төбәк икътисадына уңай йогынты ясаячак һәм кадрлар резервы белән тәэмин итүгә булышачак.

БИЗНЕС – УЛ БЕЛЕМНӘР

«Мәктәп бизнес-стартры» проекты республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов башлангычы белән өченче ел рәттән тормышка ашырыла. Ул – «Нәтиҗәле һәм конкурентлыкка сәләтле икътисад» илкүләм проектының бер өлеше. Оештыручылары – Татарстанның Икътисад министрлыгы белән Мәгариф һәм фән министрлыгы, шулай ук «Минем бизнес» үзәге.

Проектның асылы шунда: урта сыйныф укучылары бушлай эшкуарлык нигезләренә өйрәнә, аларны бизнес-проектлар ясарга – идеядән ахыргы нәтиҗәгә килергә, әзер продуктны сәнәгать җитештерүенә кадәр җиткерергә өйрәтәләр.

– Безнең өчен катнашучылар арасында районда яшәүче балаларның күбрәк булуы мөһим, – дип сөйли «Мәктәп бизнес-стартры» проекты җитәкчесе Елена Тихонова. – Бизнес-тренерлар, тьюторлар мәктәпләргә бара, эшлекле уеннар үткәрә. Икенче этапка узганнарны эшкуарлар белән

Фотолар проектның матбугат хезмәтеннән алынды, kt.tatarstan.ru

өч көнлек уку котә. Соңрак алар бизнес-кейслар чемпионатында катнаша, эшкуарлар биргән чын биремнәрне үти. Һәм майда, финалда, командалар үзләренең продуктларын бизнес вәкилләреннән, экспертлардан торган жюрига тәкъдим итә.

Ел саен проектта 11 меңнән артыграк мәктәп укучысы катнаша, аларның 120 се финалга кадәр барып җитә.

УЙЛАП ТА ЧЫГАРА, ТӘКЪДИМ ДӘ ИТӘ

Жюри башлап җибәрүче эшкуарлар күпме акча эшләгәннәрен бәяли. Шуның белән бергә, балалар үз проектларын тәкъдим итә, командадагы рольләрне дөрес бүлә һәм яхшы нәтиҗәләргә китерерлек маркетинг үткәрә белергә тиеш. Бигрәк тә шунысы мөһим: укучыларга тәкъдим ителгән проектларның берсе дә «арзанга алып, кыйммәтрәк сату» принцибы буенча эшләми, дип ассызыклый Елена Тихонова. Егетләр-кызлар эшкуар булырга гына түгел, җитештерүче булырга да өйрәнә.

Әйтик, быелгы җиңүче командаларның берсе, Казанның 182 нче лицее укучылары, үзләре үстергән кабактан кабак цукатлары җитештерүне җайга салган. Алар аны төрле яңа тәмнәр белән баета – алма, эфлисун куша... Продукцияләрен саталар да инде – кайбер матурлык салоннары цукатларны клиентларын сыйлар өчен ала.

Яки, әйтик, икенче җиңүче – Алабуганың 8 нче мәктәбе укучылары. Алар сәйлән чигелгән сумкалар җитештерүне җайга салган. Әллә нәрсәсе юк та кебек... Әмма алар товарларын шундый итеп тәкъдим итте, финалда экспертлар тел шартлатты.

Быел өченче җиңүче команда Сарман районының Җәлил гимназиясеннән булды. Алар шоперлар тегә, шуларга Тукайдан өзекләр, туган районнарына ярату белдергән сүзләр чигә, матур аппликацияләр төшерә. Финал өчен ясалган күргәзмәдә экспертлар ул шоперларны бик тиз алып бетерде.

ҖИҢЕЛҮЧЕЛӘР БУЛМЫЙ

Җәй көне җиңүче өч команда да Мәскәүгә бара, шул исәптән «Сколково» технопаркында да була. Әмма проектта җиңелүчеләр юк, дип саный оештыручылар.

– Бу балалар эшкуарлыкның нәрсә икәнен аңлый башлады. Алар бизнес-процессларны дөрес итеп корырга һәм эшләгән эшләре өчен җаваплылыкны үз өсләренә алырга өйрәнде, – ди Елена Тихонова. – Бу яшь эшкуарлар формалашуның яхшы үрнәге, алар киләчәктә, һичшиксез, икътисадыбыз үсешенә дә өлешен кертәчәк.

АЙДАР САЛИХОВ, «ТР Эшкуарлыкка ярдәм итү фонды» Коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе генераль директоры:

– Балаларны эшкуарлык нигезләренә хәзер өйрәтергә кирәк. Үз эшләрен башлаганда ук, аларның шул идеяләрне уңышлы итеп тормышка ашырырлык белемнәре булсын. Бу җәһәттән «Мәктәп бизнес-стартлары» проектының әһәмияте зур, ул эшкуарлык өлкәсендә кыйммәтле белемнәр бирә. Проект нәтиҗәләре киләчәктә Татарстанда эшкуарлык активлыгын көчәйтүгә зур өлеш кертер, дип ышанабыз.

ИЛСУР ҺАДИУЛЛИН, ТР мәгариф һәм фән министры:

– «Мәктәп бизнес-стартлары» кебек проектлар балаларга өстәмә белем һәм күнекмәләр бирә. Бүген оешкан булырга, креатив фикер йөртә белергә, тиз һәм төгәл карарлар кабул итәргә өйрәнергә кирәк. Мондый проектлар балаларның талантын ачарга ярдәм итә. Проектлар бик кирәкле һәм үсеп килүче буынны эшкуарлык күнекмәләренә өйрәтүче кешеләр булуы да бик мөһим.

ТАТАРСТАН АРТЕКЧЫЛАРЫ

Кара диңгез яр буенда гаҗәеп балачак иле бар. Ул «Артек» дип атала. Бу ил иксез-чиксез мифлар, риваятьләр, могҗизалар саклый. Бирегә бер генә мәртәбә булса да килеп караган һәркемгә билгеле алар. Башка беркайда да булмаган һәм кабатлана алмаган иҗат һәм илһам яшәгән урын, дияргә дә була.

Борынгы Аю-Даг, әкияти Адалары кыялары, Горзувит ныгытмасы калдыклары, Шаляпин кыясына кагып дулкынлаган диңгез, Пушкин мәгарәсе, зәйтүн чытырманнары һәм берсеннән-берсе серле үсемлекләр... – болар барысы да «Артек»: төрле ил һәм континентларда яшәүче балалар очраша, дуслаша һәм киләчәк турында хыяллана торган җир. «Артек» гаиләсе ул – дөньяның 150 иленнән 1 803 720 бала дигән сүз!

Фото: culture.ru

2025 **елның 16 июнендә** «Артек»ка 100 яшь тулды. Бу түгәрәк дата уңаеннан «Татарстан» республикабызның төрле еллардагы артекчыларын барлады һәм алардан бәхетле балачак истәлекләре белән уртаклашуларын үтенде. Артекчылар исә, әйтерсең, истәлекләр белән бергә Кара диңгезнең назлы дулкыннарына да янә күмелде...

1965 ел. **Рәшит Хәйретдинов һәм могҗизалар иленә юллама.**
1982 ел. **Дмитрий Сивков һәм марганцовка исе сеңгән «Артек».**
1983 ел. **Ленар Исхаков – кичәге һәм мәңгелек артекчы!**
1984 ел. **Айсылу Корманова һәм бала чакның иң шәп май ае.**

«Артек»ка 1925 елның 16 июнендә нигез салына, 9 лагерьдан («Кипарисный», «Лазурный», «Полевой», «Речной», «Озёрный», «Хрустальный», «Янтарный», «Морской» һәм «Лесной») тора.

1965
«КИПАРИСНЫЙ»
лагере

МОГҖИЗАЛАР ИЛЕНӘ ЮЛЛАМА

Евгения Чеснокова



«Рәшит, сез әйбәт малай» – барысы бергә төшкән фотографиянең арткы ягына бу язуны Рәшит Хәйретдиновка пионервожатый Надя язган. Гаҗәеп лагерь һәм «дөньядагы иң әйбәт» пионервожатый турындагы хатирәләр аны гомере буена озата килә.

ТЕШ ПАСТАСЫ ҺӘМ БУЙСЫНМАГАН АЮ-ДАГ

Надяны иң матур пионервожатый дип санаса да, «Артек»та Рәшит Хәйретдинов өчен иң күңелсез вакыйга да аның белән бәйле. Чөнки бу хатирә биш йөз метр биеклектәге Аю-Дагка походка алмаулары турында. Кырымның көньяк ярындагы «Артек» турында ишеткән һәркем, һичшиксез, бу атаклы тау турында да белә.

Фото: Рәшит Хәйретдинов архивыннан

Ә эш болай була. «Артек»та да, совет чорындагы теләсә кайсы пионер лагерендагы кебек, теш пастасы белән шаяртырга яраталар: йоклап яткан иптәшләренең битләрен буйыйлар. Беркөн Рәшитләр бүлмәсендә дә шундый хәл була. Кемдер буйый, кемдер уянып, буяучыларны куа башлый. Ыгы-зыгы башлана. Рәшит белән аның дусты бу хәлләрдә катнашмый, әмма тавышка йөгереп килгән вожатый аны-моны ачыклап тормый. Бу эштә катнашмаганнарга да эләгә. Ул вакытта ни дәрәҗәдә каты үпкәләвен безнең герой әле дә хәтерли.

Күрәсең, Надя соңыннан үзенең хаклы булмавын аңлагандыр. Шуңа да смена ахырында теге фото артына шулай дип язып куйган. Рәшит Мәүлиевич әйтүенчә, ул сүзләр аның йөрәгенә бәлзәм булып ята. Ни дисәң дә, үсмер вакыттагы гашыйк булулар андый гына үпкәләрне тиз оныттыра.

ЯХШЫ УКУЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ ӨЧЕН

1960 нчы еллар урталарында Кукмарада яшәүче үсмер Советлар Союзының иң шәп лагерена ничек барып эләккән соң дигән сорауга Рәшит Мәүлиевич кулларын гына җәя – үзе дә әлегәчә аптырый. Гади татар мәктәбе укучысы, энисе – башлангыч мәктәп укытучысы... Әлбәттә, ул яхшы укучылар рәтендә, пионер отряды советы рәисе, әмма, аның уйлавынча, кайбер сыйныфташларының юлламага ия булу мөмкинлекләре зуррак булган – мәсәлән, араларында эти-әнисе югары вазыйфада эшли торган балалар бар. Әмма ахыр чиктә юллама аңа эләккән. Малай соңрак мәктәптә завуч булып эшләүче бер укытучының кырын карашын сизгәләгән, мөгаен, аның улы «Артек»ка бара алмагангадыр...

КИПАРИСЛЫ ОҖМАХ

– Безнең гаилә бай яшәмәде, дүрт бала, киемнәр олылардан кечерәкләргә күчә, – дип искә төшерә Рәшит Хәйретдинов. – Киеп барырга киеме дә юк, бөтенсоюз лагерена барасы булгач, тегеннән-моннан кием җыйдык... Ә анда башкаладан килгән балалар да бар – аларның өс-башлары башка, чәчләре дә модалы итеп алынган... Мин, мәсәлән, «Артек»ка кадәр шорты дигән кием барлыгын белми идем. Без елның күп өлешен униформадан үткәрә идек бит – телогрейка да киез итек... Ә дүрт тапкыр ашау? Өйдә ул турыда уйлап та булмый иде!

Әмма «Артек»та киемгә дә, чәчкә дә карап тормыйлар. Барысы да бик тиз дуслашып китә. 13 яшьлек Рәшит Казахстаннан килгән малай белән бигрәк тә дус була. Фамилиясен әле дә хәтерли – Кригер, милләте белән немец (Аю-Дагка ул да бара алмый кала).

Рәшит Хәйретдинов үзен әкият иленә эләккәндәй тоюын бүген дә хәтерли әле. Диңгез, таулар, кояш, тирә-яктагы чәчәкләр... Кукмара малаеның үз гомерендә мондый матурлыкны күргәне булмый. Кипарисларга шакката – мондый агачларның барлыгын белмәгән дә була. Гурзуф, Ялтага экскурсияләр, кичләрен учак тирәли җыелып утырулар истә кала. Хәтта уку да (лагерьга ул уку вакытында эләгә, ә мәктәп укучылары өчен дәресләр мәҗбүри була) җиңел бирелә.

«Артек»тагы соңгы учакның матурлыгын җылы итеп искә төшерә. Яңа дуслары белән аерылышканда елаганын.

Икенче тапкыр ул диңгезне егерме елдан соң гына күрә. Һәм лагерьда чакта экскурсияләргә барган урыннарны кабат йөреп чыга – «Артек» бүләк иткән гүзәллекне яңадан күрү, тою өчен.

МАРГАНЦОВКА ТӘМЕ БЕЛӘН ИСТӘ КАЛГАН «АРТЕК»

1925 елның 16 июнендә, ягъни төп-төгәл 100 ел элек, Бөтенсоюз пионер лагере «Артек»ка нигез салына. Ул дистәләгән еллар дәвамында СССР балаларының хыялы була. Әмма Кырымда урнашкан бу балалар курорты күпләр өчен чын мәгънәсендә беренче тормыш һәм сынау мәктәбенә дә әверелә. Һәм бу сынауны 1982 елның маенда җиденче класс укучысы Дмитрий Сивков чын егетләрчә уза. Сүзне үзенә бирик.

АБРУЙЛЫ, ӘММА ТҮЛӘҮЛЕ БӘХЕТ

1982 елның май ае. Язның яндырып торган кояшы уку елы азагына да үз тәэсирен сиздерми калмый – ничек итеп елны «өчле»ләрсез тәмамларга икән, дип пошынасың. Чөнки бөтен уең белән син инде каникулларда, ә анда ләззәт: иртәдән кичкә кадәр кинәнеп су коенырга, футбол, волейбол, атышлы уйнарга була. Әле тагын балта осталары бригадасына кушылып эшләп, акча юнәтергә һәм ниһаять Польшадан кайтартылган Odra джинсы чалбарын алып җибәрергә.

Баш миен әнә шундый җылы-рәхәт уйлар изрәткәндә, тәнәфестә завуч янына чакыралар, дигән сүз сискәндереп җибәрә. Җәза мәйданына атлагандай, шунда юнәлсәң, башны

Фотолар Дмитрий Сивковның шәхси архивыннан

инде икенче уй, дөресрәге, сорау бораулый: Валентина Ивановнага мин нәрсәгә кирәк булдым икән? Борчылырга сәбәп тә юк шикелле: 7 класс азагына 250 кешедән торган мәктәп комсомол секретаре урынбасары, беренче разряд белән мактана алам, чаңгы ярышларында район чемпионы – Уралның тирә-юнь авылларында беренче номер, җирле үзешчән сәнгать берләшмәләре «йолдызы». Дөрес, кем әйтмешли, яшерер серләр дә юк түгел-түгелен... Әмма алардан башка егетләр тиңдәшләре арасында авторитетка ия була алмый бит.

– Котлыйм! – дип башлады сүзен завуч, мин килеп кергәч. – Сиңа «Артек»ка юллама, уңышларың өчен ял итәргә җибәрергә булдык!

Минем бу яңалыктан берара сулышым кысылып киткәндәй булды. Хәзерге мәктәп балаларына совет заманында «Артек»ка юллама алуның нинди зур абруй һәм бәхет икәнлеген аңлату мөмкин түгелдер, дип уйлыйм. Бу үзенә күрә космонавтлар отрядына эләгү шикеллерәк могҗиза инде. «Артек» турында бөтенесе дә ишетеп белә, әмма синең бер генә танышыңның да, әлбәттә, әле анда булып караганы юк.

Педагог шаккатыруын тагын дәвам итте, монысы инде бәхетле галәми биеклектән шунда ук җиргә төшерде:

– Әти-әниеңә әйт, юллама бәясе – 98 сум, әзерли торсыннар.

Эп-эссе көндә өстемә бозлы су сипкәндәй катып калдым. 98 сум – ул бит әнинең бер айлык хезмәт хакы! Кырымда, Кара диңгез ярында ике атналык ял шулай итеп янә буй җитмәслек могҗизага әверелде. Әти-әнием – гади эш кешеләре – бу яңалыкны тыенкы-сабыр гына кабул итте. Гаиләдә артык акча юк, абый белән апа техникумда укый, әле җитмәсә мунчага дип төзелеш материаллары алырга торган чак.

Әти, уйларын бер йодрыкка туплап, үз сүзен җиткерде:

– «Артек»ка барасың килә икән, акча эшлә, улым. Син бит каникулда шабашкага йөрермен дигән идең. Җитмәгәнен өстәрбез.

Мин кызыккан Odra да шулай итеп хыялда гына калды. Джинсы – ул заманда һәркемнең олы хыялы иде, билгеле, әмма «Артек» – аннан күпкә зуррак хыял.

Ә БЕЗДӘ... «МЕДВЕДЬ» БАР!

«Кипарисный» лагереның беренче отрядында кич танышудан башланды. Көн дәвамында медосмотр узган, юыну процедураларын үткән, инде инкубатор чебиләре сыман бертөрле «Артек» униформасына киенгән ике дистәдән артык үсмер турында бара сүз. Бу униформаны киеп алгач, башкалардан аерылып тору омтылышы тагын да ныграк арта һәм асылда контрольгә бирелми диярлек.

Нигездә мондагы хәлләр Маршакның «А что у вас?» сюжетын хәтерләтә иде. Союз белән республика башкалаларында, төбәк үзәкләрендә яшәүчеләргә артык бернәрсә дә уйлап торырга кирәкми: төрле манзаралар төшерелгән открыткалар, значоклар, сувенирлар кулдан-кулга йөри, аларны әйләндерә-әйләндерә карыйлар, сөйлиләр. Бу вакытта тарих дәресләре һәм «Время» тапшырулары аша яхшы таныш вакыйгалар һәм атамалар яңгырап китә. Ә инде Германия, Венгрия һәм Чехословакиядәге совет гаскәрләрендә хезмәт итүче генерал, офицер балалары открыткалар урынына маркалар, кроналар һәм сагыз алып килгән.

Үзем алып килгәнне барлап карадым да, кәефем бөтенләй кырылды. Миндә боларны каплардай берни юк бит. Урман эшкәртүчеләр яшәгән Урал бистәсе заманасы өчен зур казаныш саналган «Медведь» автомат агач эшкәртү линиясе белән мактана алса гына... Тантаналы рәвештә ачканнан соң, ул да бары тик бер генә ягы белән аерылып тора – берниндн ярдәмсез урман ташучы КрАЗ машиналары күтәргән тузанга күмелеп утыра.

– Безнең шәһәрдә әле агач түшәлгән урамнар бар. Урыны-урыны белән агач тротуарлар да сакланып калган хәтта. Күз алдына китерәсезме?! – Архангельскидан килгән Лена иң шәп дәлилен ахырга калдырды һәм, әйтергә кирәк, оттырмады. Аяк табаннары бары тик асфальтның ни икәнен генә белеп үскән яшүсмерләр төньяктан килгән кызга шунда ук сизелерлек ихтирам белән карап куйды.

– Ә бездә башка төрлесенең булганы да юк, – дип чак кына ычкындырмый калам мин, әмма вакытында тыелам. Беренче мәртәбә күргәндәй, атсыз бармагымдагы җөйгә кабат тикшерергә керешәм. Ул әле юньләп тартылырга да өлгермәгән. Бармагымны җәй башында ялгыш балта белән әләктереп алган идем. Балта остасының ярдәмчесе булып эшләп йөргәндә. Нәрсә-нәрсә, ә менә агач тротуарлар хакында мин шәһәр малайлары белән кызларына сәгатьләр буе сөйли алам. Киңлеге 90 сантиметрдан артык булмаска тиешлеген дә, бәяләргә килгәндә, бригадага бер метрга 70 тиен түләнүен дә, бистә модницаларының шпилькадан йөрмәвен дә... Чөнки такталар арасындагы ярык – бер бармак юанлыгы...

– Ә безнең бистәдә агачны автомат эшкәртү линиясе бар, «Медведь» дип атала. Бу – совет урман сәнәгатендәге иң алдынгы казаныш. Линияне кулланышка кертү агач материал эшкәртү күләмен 30 процентка арттырырга мөмкинлек бирде, – дип, зур горурлык белән ярып салдым мин, үз төбәгем турында сөйләргә чират килеп җиткәч.

МАХСУС КИТЕРТЕЛГӘН «ПОМОРИН»

«Артек»ка килү белән балаларны биредәге кагыйдәләр белән таныштыралар. Катгый табуларның берсе – төнлә йоклап ятучыларга теш пастасы белән «макияж» ясарга ярамый.

– Күрше дружинада бер малайның күзләрен «Поморин» пастасы белән буяганнар иде, су-

– 1982 елның җәендә миңа Odra джинсы чалбарын «Артек» юлламасына алыштырырга туры килде. Хәер, джинсыны барыбер аннары әти белән әни Яңа елга бүләк итте.

– Вожатый сүзләренә караганда, Болгариядән кайткан «Поморин» теш пастасын «макияж» урынына куллану зур зыян китерергә мөмкин.

Язма авторының лагерьдан алып кайткан бүләкләре.

кыр калды, – дип, күңелебезгә шом кертергә тырышты һәм сәламәт йокы тарафдарлары булырга өндәде безнең вожатый.

«Әйбәт паста булса кирәк. Табасы булыр» – беренче уем шул булды. Аңа кадәр минем тешләремне нәрсә белән чистартуым турында гомумән уйлаганым булмады.

– Кемдә дә булса «Поморин» бармы? – дип сорадым мин, үземнең авыллыгым белән артык уйлап тормыйча.

Вожатый яңа гына сайлап куелган звено командирына шөбһә белән карап куйды. Кулын теләр-теләмәс кенә Мәскәүдән килгән Елизавета күтәрде.

– Мә, ал. Шалтыратып әйтермен, миңа иртәгә яңаны китерерләр, – диде ерак башкала кызы, пастаны сузып.

Мин баш тартып тормадым, «миңа иртәгә яңаны китерерләр» дигәнен дә шунда ук аңламадым. Икенче көнне миңа контроль-пропуск пунктында дежур тору «тәтеде». Елизаветага теш пастасын авиация подполковнигы китерде. Әлеге өлкән офицерга кадәр майор – район хәрби комиссариаты башлыгы килгән иде.

– Әтиеңме? – дип сорадым мин, офицер китәргә кузгалгач, аңа ишарәләп.

– Аның адъютанты.

– Ә этиең нинди званиедә?

– Генерал-полковник.

Мин генерал-полковник кызына теш пастасын нинди самолётта алып килгәннәрен белергә теләсәм дә, сорарга кыенсындым.

КАКТУСЛАР АША ЭСТАФЕТА

Социаль яктан бертигез булмасак та, балалар арасында ниндидер аерым дистанция сизелмәде. Мажорлар да, безнең ише гади эшче балалары да – лагерьда бердәй шартларда. Безнең ишеләр «Артек»тагы гади генә булмаган көндәлек тормышка яхшырак та яраклашкан булып чыкты.

Ерактан күзаллаганча, пионерлар оҗмахына бөтенләй охшамаган иде асылда «Артек». Көн таңнан алып кичкә кадәр минутлап бүленеп куелган – күзеңне ертып ачудан башлап, «отбой» җиткәнче син гел мәшгуль, нидер эшлисең. Соңрак мондый режимда хәрби хезмәткә әләккәч кенә яшәргә туры килде – яшь сугышчы курсларында. Йоклап китәр алдыннан һәр кичне без өйгә кайтасы көнгә тагын күпме калганын исәпли идек. Кемдер хәтта календарь да булдырды – Кара диңгез ярындагы көннәрнең узып киткән һәрберсен кызыл кара белән сызып барды.

Диңгездә йөзү – үзе бер аерым тема. Ун кешене пенопласт буеклар белән әйләндереп алынган суга ун минутка кертеп җибәрәләр. Суга чумып йөзү катгый тыела. Кагыйдәне бозучылар өч көнгә су керүдән мәхрүм ителә. Әмма монысы әле аның берни түгел, ә минә төнлә су коенган өчен гомумән өйгә кайтарып җибәрәләр. Мәсхәрә белән!

Әлеге тыюны без, беренче отрядлар, иң беренче эш итеп бозарга булдык. Сынауны узганнарны да искә алмый ярамас: Саранскидан Алексей, Читадан Олег, Көньяк совет гаскәрләре төркеменнән (Венгрия) Дмитрий. Нәкъ менә шушылар ахырдан отрядның умырткасы булып оешты да. Безне хәтта «дүрт мушкетер» дип тә атап йөрттеләр. Барлык фотосурәтләрдә дә без – бергә.

Пляжга әләгүнең дә ансатлыгын исәпкә алырга кирәк бу урында. Безне, иң өлкәннәр буларак, төп корпуста түгел, ә дүртешәр һәм унышар кеше итеп шифер мичкәләрдә урнаштырдылар. Нигездә – беренче линиядә.

Дөрес, смена тәмамланырга өч көн кала, без төнге вожатыйлар патруленә тап булдык. Аларга барып төртелмәс өчен, кактуслар аша эстафета үтәргә туры килде. Шортыдан килеш! Шуннан соң инде калган өч көнне джинсыдан пешенеп йөрдек, югыйсә безне тотып алып, тырналып беткән аякларыбыз буенча шунда ук «танып» алган булырлар иде.

Агач ботакларындагы җимешләрне ашау да катгый тыела, әмма куллар үзеннән-үзе анда үсеп утырган кизил, слива, алычага үрелә. Вожатыйлар, безне андый этлектә тотып алса, шунда ук медчастька алып бара: бер литр марганцовка эчерәләр дә, ике бармагыңны авызга тыгып, укшырга боералар. Коллектив белән җәзага тарту ысулы да бар: отрядтан кем дә кем кыргый җимеш ашауда тотылса, эчеп бетерер өчен, бер чиләк марганцовка бирәләр.

Озын сүзнең кыскасы, бу ике атна Уралның җәһәннәмдәге бер шәһәрендә үскән малай өчен чын мәгънәсендә сынау мәктәбе булды. Һәм мин аны уздым. Шул көннәр истәлеге итеп, Гурзуф өстендә калкып торган Аю-Даг итәгендә үскән лаванда ботаклары белән бергә, актив эшчәнлегем өчен грамота, волейбол турнирында беренче урын алган өчен диплом һәм «Артек таңнары» фестивале кысаларында бал биюләре буенча җиңгән өчен медаль дә алып кайттым.

Һәм – гаҗәеп күп кичерешләр! Дөрес, өйдәгеләргә аларның бөтенесен дә сөйли алмадым, класстан класска очрашуларга йөргәндә дә, кайберләрен сиздерергә шикләндем. Чөнки совет балаларының изге, якты хыялына тап төшерергә ярамый. Һәм, әлбәттә, бу кичерешләр Польша джинсыларыннан өстенрәк калырга тиеш!

Ә джинсы чалбарга килгәндә, ул миндә соңрак пәйда булды, каешын әле бүгенгә кадәр кадерләп саклыйм. Әмма монысы инде – бөтенләй башка тарих.

КИЧӘГЕ АРТЕКЧЫ – МӘҢГЕЛЕК АРТЕКЧЫ УЛ!

Җиденче класс укучысы Ленар Исхаков «Артек»ка штаб сменасына эләгә. Ул пионерлар хәрәкәте тарихында, ахрысы, бердәнбер шундый смена була. Һәм менә ничек уздыра аны безнең каһарманыбыз.

ПИОНЕР ШТАБЫ ЧЫГАРЫЛЫШЫ

Пионер штаблары бөтен СССР буйлап таралган чаклар ул – нәкъ менә шулар җирле урыннарда пионер хәрәкәтен оештыра һәм җитәкли. Казанда да һәр районда пионер штабы бар иде. Әле тагын шәһәр пионерлары штабы «Факел»ны да исәпкә алырга кирәк. 1983 елда мин Вахитов районының «Альтаир» штабында булдым, ә «Артек»тан соң, «Факел»га күчтем. Шуннан инде 1985 елда комсомол сафларына алындым. Комсомол булгач, коллегаларым белән бергә республикадагы пионер хәрәкәте белән җитәкчелек иттем. Пионер галстукларын салып ташламадык. Киресенчә, горурлык белән тагып йөрүне дәвам иттек!

Күбебез «Артек»та булды, кайсыберләребез – «Орлёнок»та. Тегендә дә, монда да өлгергән уникумнар да очрады. Кыскасы, мин «Артек»ка эләктем. «Актив тормыш позициясе» алып барган өчен.

Флаг күтәрү, төшерү... – минем өчен бу үзе бер миссия иде.

МИЛЛИ ТЕЛДӘГЕ ДӘРЕСЛЕКЛӘР

Без анда ял итеп кенә калмадык, ә укыдык та. Чөнки смена уку вакытына туры килде – 1983 елның март-апрель айлары. Мәктәптә бөтен Советлар Союзыннан җыелган балалар бар иде. Безнең белән бергә СССРның милли мәктәпләрендә белем алган укучылар да – җитәрлек. Отряд фотосына күз салсаң, шунда ук Союз уч төбендәгедәй күренә: Татарстан, Иркутск өлкәсе, Мәскәү, Владивосток, Приморье, Үзбәкстан, Якутия, Таҗикстан... Һәм барысы өчен дә милли, үз телләрендә дәреслекләр бар иде. Килүгә, сорыйлар: «Син каян?» «Молдавиядән! – ди берәү. – Мөмкинме, мин молдован телендә җавап бирәм? Миңа шулай җиңелрәк...» «Әлбәттә, мөмкин. Мин сиңа хәзер үз телеңдә дәреслек тә китереп бирәм», – ди укытучы. Һәм алып килә дә. Мин моңа үзем шаһит булдым.

43 ЕЛДАН СОҢ ОЧРАШЫРБЫЗ

«Артек»тан кайткач, без анда табышкан дуслар белән озак вакытлар хат алыштык. Армиягә кадәр. Ә күптән түгел генә, 35 ел узганнан соң, Иркутск өлкәсеннән, Ангарск шәһәреннән бер кыз, мине табып, хат язды. Ул ире, дуслары белән Казанга берничә мәртәбә килгән иде. Хәзер менә үзләренә Себергә чакыра – Байкалны күрергә.

Ә июнь аенда бер банк Казанда үзенең төрле төбәктәге хезмәткәрләрен җыя, очрашу оештыра. Һәм менә бу очрашуга минем белән «Артек»та ял иткән һәм мин 43 ел буена күрмәгән тагын бер кыз килә. Ул – Магнитогорскидан. Без аның белән «Одноклассники»да табыштык, очрашырга һич кенә дә җай чыкмый иде. Менә ул – фотографиядә, озын чәчле кыз, Наташа Петушкова. Ә монысы – безнең делегациядәге кыз, Лариса, ул – Түбән Камадан. Бу малай – Михаил Дубровин – Мәскәүнеке. Соңгы мәртәбә мин аны телевизордан күрдем, ул Нью-Йоркта яши, балалар табибы булып эшли иде. Хәзер яңадан Мәскәүгә әйләнеп кайтты.

Әгәр «Артек»та бер булгансың икән, ул инде армиядә булган кебек – аның эзен юкка чыгарып булмый (мин – уң якта).

«Армиядәшләр» белән (мин – сул якта).

ОНЫТЫЛМАС ЛЕГЕНДА

Инде үскәч, Кырымга баргында, «Артек»ка керергә тырышып карадым. Балама кат-кат сөйләгән истәлекле урыннарны күрсәтәсем килде. Әмма анда – үтә дә кырыс кертү режимы, алдан сөйләшеп-килешеп куярга кирәк икән. Балалар җыела торган урын бит, аңлашыла...

«Артек» һәрвакыт онытылмас бер легенда булды ул, хәзер дә шулайдыр, дип уйлыйм. Анда эләгергә хыялланмаган бала юк иде. Өч-дүрт палаткадан башланган лагерь тора-бара тулы бер Пионер Республикасы дәрәҗәсенә үсеп җитте. Аның нигезендә бик көчле идеология ята иде. Флаг күтәрү, флаг төшерү... «Пионерлар, коммунистлар партиясе эше өчен көрәшкә һәрвакыт әзер булыгыз!» «Һәрвакыт әзер!»

Ничек икән анда хәзер? Белмим... «Артек»ның иң яхшы традицияләре юкка чыккандыр, дип шикләнәм. «Артек» җырлары гына да күпме бит... «Алиса»дан аларны куюын сорагыз әле, ул сезгә ярты кич буе җырлатачак.

Җырдагыча шуны гына кистереп әйтә алам: «Кичәге артекчы – ул мәңгелек артекчы!» Әгәр «Артек»та бер булгансың икән, ул инде армиядә булган кебек – аның эзен юкка чыгарып булмый. Шунысы да бар: «Артек»та булганнар белән (ә алар Татарстанда җитәрлек) теләсә кайсы мәсьәләне хәл итүе күпкә җиңелрәк.

КҮҢЕЛСЕЗЛӘНЕРГӘ ВАКЫТ ЮК

Чөнки «Артек» ул – гадәти булмаган лагерь. Анда, әйтик, төннәрен теш пастасы белән буямыйлар иде, бу затсызлык исәпләнә. Әмма отбойдан соң, мәсәлән, без, бер төркем дус, йөреп кайтырга ярата идек. Таулы-урманлы урын, гаҗәеп матурлык... «Артек»та көн вакыйгалар белән шыплап тулган, сулыш алырлык бер минутың да юк. Буш вакыт бары тик ашарга һәм йокларга гына кала, калганнары – уку белән чараларга. Барысы да – расписание буенча. Ә уратып алган







киртә артында ни барын карарлык мөмкинлек бөтенләй юк. Диңгезнең бер чите күренеп тора, анда төшәргә дә вакыт җитми. Шуңа без кечке сәяхәтләрне көтеп ала торган идек. Диңгезгә дә төштек, серле, яшерен сукмаклар буйлап Аю-Дагка да күтәрелдек... Без анда 40 көн яшәдек, чөнки сезон түгел иде.

Инде бик күптән булган хәлләр бу. Әмма истәлекләр шулкадәр җете – кичә генә булган кебек...

«АРТЕК»НЫҢ ҖИРЛЕ РУХЫ

Балачакта мин пионер активы лагерьларында булдым. «Дружба», «Солнечный» – иң атаклылары. Казандагы лагерь бөтенсоюзныкыннан нәрсәсе белән аерыла, диярсез. Беренче чиратта, масштаблы булуы белән, әлбәттә. Безнең күпчелек «штабчылар» йә «Артек»та, йә «Орлёнок»та булып кайтканга, алардагы җирле рухны урындагы төбәк лагерьларында да сакларга тырыша идек. Нигездә, ярыйсы гына килеп чыккандыр, дип уйлыйм. Чөнки балалар ел саен без эшләгән лагерьларга да, штабка да яңадан килергә тели иде. Урамда очрасаң да, шунда ук исәнләшәләр. «Артек» рухы, шулай итеп, безгә ияреп кайтты, дисәк тә була. «Артек»та эшләгән вожатыйлар да бар иде бездә.

БАЛАЛАРГА ЙӨЗ ТОТЫП...

Пионер оешмасы Советлар Союзы таркалу белән юкка чыкты. Ул чакларда лагерьлар, яшерен-батырын түгел, әллә ни мактанырлык түгел иде. «Артек» исә, иле алышынып торса да, сакланып калды, аңа хәзер инде 100 ел. «Артек» бренды белән аның традицияләре дә сакланып калсын иде, дип телим. Чөнки аның тарихы бик кызыклы, зур, ә урыны-урыны белән – фаҗигале дә. Анда 1941 елда барган һәм бары тик сугыштан соң гына әйләнеп кайткан балаларны гына искә алыйк. Ул чакта аларны бөтен лагерь белән Себергә эвакуацияләделәр.

«Артек» әле озак еллар дәвамында кирәкле булыр, дип уйлыйм. Нәкъ менә үз форматында. Ул балаларга йөз тотып, патриотик тәрбияне алга сөреп эшләр һәм яшәр, дип өметләнәм.

2000 ЕЛДА ОЧРАШЫЙК

«Артек»та ял итүчеләрнең очрашулары булмавы кызганыч, мәктәп чыгарылышлары кебек, аларга да күрешү кызыклы булыр иде. Югыйсә, яшүсмерләр, саубуллашканда, һичшиксез очрашабыз, дип сүз куеша. Әмма без барыбыз да төрле республикалардан, шәһәрләрдән, хәзер инде – хәтта илләрдән дә. Кичке сәгать алтыда Кызыл мәйданда очрашып карагыз әле сез! Бөтен отряд белән! Барып чыгуы бик шикле.

Шулай берсендә, «Артек»та, Марк Аршанский белән пальма астында сөйләшеп утырабыз. 2000 елда очрашу планлаштырабыз. Безгә ул вакытта ничә яшь буласын күзаллыйбыз. Анда шаккаткыч саннар чыга – 33 яшь! Менә сиңа мә! Икенче яктан, 2000 ел – әле кайчан ич ул! Һәм без тынычланып калган идек.

Һәм менә узып та китте ул еллар, 2000 елдан соң да 25 ел җилдерде генә инде. «Артек»та бөтенләй юкка чыкмады. Төп, нигез әйберләр саклана. Дружиналарның да атамалары шул ук: Кипарисная, Морская, Янтарная. Соңгысында мин булдым. Кайсыдыр лагерьларда дружиналарда пограничниклар пионерлар белән бергә дозорга йөри, диңгездә коена, диңгез эшенә өйрәнә иде. Бу бик файдалы һәм кызыклы. Безнең балачакта бит «Артек» турында һәркем хыялланды. Хәзер генә ул самолетка утырып, дөньяның теләсә кайсы почмагына очарга була. Ә теге чакларда... «Артек»ка бару Марска очуга тиң иде.

ВАКЫТ ҮЗГӘРӘ, ПАТРИОТИЗМ – ЮК

Хәзер вакыт үзгәрде, пионерлар юк. Ә «Артек» – бар. Анда, Балачак илендә, без барыбыз да патриотларга әйләнә идек. 1775 елда ниндидер бер табиб – Самуэль Джонсон үзенең атаклы гыйбарәсен әйткән диләр: «Патриотизм – кабахәтнең иң соңгы качар өне ул». Шулай дигән дә бит, әмма мин патриотизмда берниндә дә зыянлы нәрсә күрмим. Әлбәттә, аның белән шәхси кызыксынулар һәм омтылышларны каплап куймасалар. Туган ватаныңны яратуда мин берниндә начарлык күрмим, мәсәлән. Ә ватан белән горурлану, аның гимны яңгыраганда, аяк басып тыңлау – бу бик шәп, минемчә! Укудагы казанышлары, кылган яхшы гамәлләре, активлыклары өчен мәктәп укучыларын да «Артек»ка җибәрсәләр – монысы, миңа калса, бөтенләй куана торган күренеш!

– «Книжка пионера-артековца» китабын хәзерге көнгә кадәр кадерләп саклыйм.

БАЛАЧАКНЫҢ ИҢ ШӘП МАЙ АЕ

Айсылу Корманова – Казан мәктәпләренең берсендә балалар укыта. Ә үзе укыган мәктәп тормышындагы иң матур истәлекләрнең берсе «Артек» лагере белән бәйле. Анда ул бишенче класста укыганда бара.

ЯХШЫ УКЫГАН ҺӘМ ТӘРТИПЛЕ БУЛГАН ӨЧЕН

– Ул интернат-мәктәпләр белән балалар йортларыннан җыелган балалар өчен оештырылган смена иде, – дип искә ала Айсылу Шәүкәтовна. – Миңа юлламаны «яхшы укыган һәм тәртипле булган өчен» бирделәр. Бишенчедә укыганда мин чынлап та шундый идем – тәртипле, оялчан, тыныч... «Янтарный» дружинасының 14 нче отрядына эләктем.

ПОЕЗД, ДИҢГЕЗ, ДУСЛЫК

Бу сәяхәтнең рәхәтлеген мин әле Казанда ук тоя башладым. Беренчедән, бөтен Советлар Союзына билгеле лагерьга барам – бу үзе үк могҗизага тиң! Апам мине Ирек мәйданын-

Фотолар Айсылу Кормановaның шәхси архивыннан алынды

дагы комсомол өлкә комитеты бинасына кадәр озатты. Икенчедән, беренче мәртәбә поездга утырам – бала өчен монысы да үзе бер маҗара инде! Өченчедән, беренче кат диңгезне күрәм... Ул зуп-зур, зәп-зәңгәр! – сокланудан тының кысыла хәтта! Аннан соң мин гел шушы тойгыны тоеп йөрдем – табигать хозурлыгыннан да, кызыклы экскурсияләрдән дә, учак янындагы җырлардан да, вожатыйларның җылы мөнәсәбәтеннән дә, лагерьда һәммәбезне бербөтенгә әйләндергән дуслыктан да...

ЯЛТА, АЮ-ДАГ ҺӘМ ТРЕТЬЯК

Дүрт яшендә әти-әнисен югалткан бала өчен бу аеруча кадерле бүләк булды. «Артек» минем хәтеремә әкияттәй кереп урнашты.

Ул балачак хатирәләре, Кара диңгезнең күбекләнеп килеп каккан дулкыны кебек, кайчакта хәтеремдә калкып күтәрелә дә, иреннәргә елмаю куна. Моңа бер сәбәп тә юк шикелле, әмма балачагымдагы ул гаҗәеп май ае ирексездән елмайта, җылы истәлекләрне уята.

Севастополь белән Ялтага экскурсияләр шунда ук искә килеп төшә, Аю-Дагка күтәрелүебез... Лагерьга очрашуга атаклы хоккейчы Третьяк килгәне һич онытылмый – аның исемен белмәгән совет баласы булмагандыр. Минем өчен бу аеруча тәэсирле очрашу булды, чөнки абыйларым хоккей ярата иде...

«МИНЕМ КЫЗЫМ БУЛЫРГА ТЕЛИСЕҢМЕ?»

Тагын бик хәтердә калган кешем – вожатый Инна. Ул бервакыт мине читкәрәк чакырып алды да сорады: «Минем белән Белгородка китәргә, кызым булырга теләмисеңме?» Мин аңа: «Казанда минем апам белән ике абыем калды, минем алардан башка яшисем килми!» – дип җавап бирдем.

Шул сүзләрдән соң, ул мине кочаклады да елап җибәрде. Аннары озак еллар буена без аның белән хатлар алышып тордык.



«ЗДРАВСТВУЙ, ЛУНА-КРАСАВИЦА!»

«Артек»та мин күп дуслар таптым. Миңа Үзбәкстаннан да, башка күп кенә союздаш республикалардан да язып тордылар. Хәтта лагерьдагы диджей белән дә хатлар алыштык. Ул миңа: «Здравствуй, Луна-красавица!» – дип яза торган иде. Чөнки исемемнең рус теленә «луна» һәм «красавица» буларак тәрҗемә ителүен хәтерендә калдырган. Мин интернат-мәктәптә татар телендә укысам да, «Артек»та барысы белән дә русча иркен аралаштым.

«АРТЕК»ТАН – ИСТӘЛЕК ӨЧЕН

Смена тәмамлангач, өйгә кайтыр алдыннан, безнең барыбызга да «Артек» дип язылган кул сәгатьләре тараттылар. Тагын әле значоклар да бирделәр. Мин аларны хәзерге көнгә кадәр кадерләп саклыйм...



«ЮМОР ҺӘМ САТИРА – УЛ МИНЕМ ДИАГНОЗ...»

Руфия Фазылова

Ачык кешеләр була. Туры сүзлеләр бар. Татарстанның халык язучысы Камил Кәримовка икесе дә туры килә. Аның һәрнәрсәгә карата үз фикере бар. Һәм күп очракта ул ярымшаяру рәвешендә булыр.

Соңгы өч елда Камил абый – «ирекле кош». Ике дистә елдан артык эшләгән «Казан утлары» журналыннан китте. Шулай да һаман актив, очрашуларга йөри, төрле чараларда еш була. Руль артына утырып, Казан – Шәле арасында җилдереп кенә тора.

- Камил абый, сүзне бала чагыгыздан башлыйк. Сез этисез үскән малай. Сезнең өчен бу бик зур фаҗига идеме?

– Әни белән үскән кеше үзен ятим итеп тоймый. Ә менә эти белән генә үскән бала әле ятим булырга мөмкин. Миңа алты ай тулганда, эти вафат була, сугыштан исән кайтып, биш кенә ел яшәп кала ул. «Сугышчан дан» ордены, «Сугышчан казанышлар өчен» медальләре белән бүләкләнгән кеше. Әни безгә, өч баласына, бөтен җан җылысын биреп үстерде, сөйләп аңлата торган түгел. Бик тырыш булды ул: көн-төн колхозда эшләде. Авыр эш кушып, безне интектермәде. Әлбәттә, урманнан ботак ташулар, печән җыюлар булды. Ләкин без ул эшләрне авырсынмадык. Әни безгә карата бик ягымлы иде. Шуның өчен дә ятимлекне тоймадым. Нечкә күңелле бала булып үсүем дә энигә бәйледер. Ул укый, яза белми иде. Шулай да безгә «Яшь ленинчы» белән район газетасы килде. Дүртенче сыйныфтан ук шигырьләр яза башладым, күрәсең, әнкәй минем әдәбиятка тартылганны күргән.

Тагын шуны да әйтим: этисез икәнлегемне җиденче, сигезенче сыйныфларда аңладым, чөнки этиле кызлар безгә өстәнрәк карады. Этиле кешеләр заманасына күрә бай, мотоцикллары да бар. Ә безнең нәрсә... салам түбәле өй. Мең хуҗалыклы Шәледә өч кенә шундый өй калган иде. Әлбәттә, аңа хурландым. Ел саен түбәгә яңа салам саласың. Ниһаять, 1965 елда, мин сигезенче сыйныфта укыган чакта, ике мең сум ссуда алып, өй салдык. Шуннан соң җилкәләр азрак турайды инде. Дөрес, ул ссуданы түли-түли җан чыкты.

Фотолар: Александр Ефремов, Камил Кәримовның шәхси архивыннан

– Сезне сатирик язучы буларак беләбез. Ул башкалардан кайсы ягы белән аерыла?

– Сатираны теләсә кем яза алмый. Сатирик язучы ул – кеше әйтергә теләгән, әмма төрле сәбәпләр аркасында эндәшми калган әйберне язып бирүче. Ләкин ул кемнәндер үч алу түгел.

2000 нче елларга кадәр чыккан юморескаларымны укыйм да гаҗәпләнәм: хәзер аларны бастырып булмас иде. Анда хәтта кешеләрнең исемнәре дә язылган. Һәм миңа бер кеше сүз әйтмәгән, чөнки аның чоры шундый булган. Ә хәзер син бисмилла урынына башта фәлән-фәлән түрәне телгә алмасаң, чыгыш ясарга чакырмыйлар да. Без хәзер сәясәткә яраклашырга мәҗбүр. Инде иялэндек тә, ә бер иялэнгэч, әллә нәрсә куркыныч та түгел шикелле. Камчы эленеп торса, ул куркыта, әмма камчыдан ерагайгач, курыкмый башлыйсың.

– Татарда матур юмор юк, билдән түбән өлештән генә көләбез. Әнә Екатеринбургның «Уральские пельмени» командасын гаилә белән утырып карарга да оят түгел. Без исә һаман шул оятлы темадан ерак китә алмыйбыз...

– Тудырып була яхшы юморны, ләкин аның белән тамак туйдырырга мөмкин түгел. Тамашачының зәвыгы бозылды, аны көлдерү өчен юмористлар «түбән» темаларны сайларга мәҗбүр. Әгәр шулай көлдермәсәң, тамашачы килми, димәк, акча да юк. Ул яктан без бәхетле идек: тәрбияле, зәвыклы аудитория белән эшләдек. Әйтелмәгән сүзләр дә кешене көлдерә иде. Ә хәзер күп нокталар урынына сүзен әйтергә кирәк. Эстрада бүген юморны үз юлы белән алып кереп китте. Хәзер фельетон язып кара син! Ә бит яза идек, исемнәрен атап. Ни кызганыч, бүген халыкны көлдерү өчен итәкне югарырак күтәрергә кирәк.

– Камил абый, елдан-ел Тукай премиясе тирәсендә бәхәсләр арта тора. Сез дә Тукай премиясен алган шәхес. Мәртәбәле исемгә лаек булу шулай авырмы? Аның шартларын үзгәртер вакыт җитмәдеме, ничек уйлыйсыз?

– Яшермим, Тукай премиясенә дүрт тапкыр дәгъва кылдым һәм соңгысында гына алдым. Комиссиядә һәр иҗат берлегеннән (композитор, рәссам h.б) бер кеше утыра. Алар һәммәсе үз дилбегәсен тоткан. Шулар арасында Язучылар союзы җитәкчесеннән башка, минем романнарны берәрсе укыганмы? Юк. Тукай премиясен алу комиссия әгъзаларының тавыш бирүенә карый. Ә сине укымаган кеше сиңа ничек тавыш бирә ала? Ул аны фәкать шәхесеңә карап кына билгели. Ә бу объектив булмый.

Тукай премиясе алгач, гаиләмне Грециягә алып барып кайттым. Хәзер миңа бу төш кебек кенә, чөнки бүтән кабатлый алмам инде. Ул пенсионерга эләгә торган әйбер түгел. Шунда баргач, безнең мохитнең тарлыгын аңладым...

– Әдәбият, матбугат турында да сөйләшәсе килә. Үзегезгә алмаш калдыра алдык, дип уйлыйсызмы? Сезнең буынны алыштырырдай яшьләр бармы әдәбиятта?

– Сорауга сорау белән җавап бирим әле: редакциягә килгән кулъязманы редакцияләмичә бастыра аласызмы? Юк. Менә мин кырык елдан артык редакциядә эшләдем. Әгәр шул дәвердә яшьләрдән килгән язмаларны редакцияләмичә чыгарган булсам, газета-журналларны укучы да булмас иде. Мөхәррир ул – күзгә күренми торган тәрбияче. Акрынлап яшьләрне сюжет корырга, язарга өйрәтәсең. Хәтта кайбер очракларда әсәрне язып бетереп тә бирәсең. Беренче хикәяләре, әсәрләре басылганда алар сиңа «остазым» дип җибәрә. Ә аннан алар синең белән исәнләшми дә башлый. Янәсе, алар үзләре кеше булган. Ләкин без моңа иялэнгән, алар аны яши-яши, тәҗрибә белән соңыннан үзләре дә аңлый.

Алмаш, дигәннән... Бүген әдәбиятка хатын-кыз килде. Булсын, мин каршы түгел. Бүген бала тәрбияләү дә хатын-кыз кулында, тормыш алып бару да. Ә алар йөрәк белән, күңел кушканча эшли.

– Матбугатның бүгенге хәле сезне борчыймы? Ун-унбиш елдан басма матбугат булырмы, әллә инде электрон вариантка да ризамы?

– Борчый. Әгәр Кол Галиләр вакытында электрон матбугат булса, «Кыйссаи Йосыф» безгә килеп җитмәгән булыр иде. Ул килеп җиткәнгә күрә, без татар әдәбияты тарихын 800 елдан да ким түгел, дибез. Әйе, без яңалык яратабыз, тик бу очракта кәгазь варианттан баш тарту зур хата булачак. Электрон басманың җаны юк, исе дә юк, тотып карап та булмый. Кәгазь калырга тиеш! Кәгазь гомергә тарихны саклаган. Алай дисәң, рәсемне дә электрон вариантка күчерик. Электрон хатыннар белән яши башлыйк... Фән казаныш-

Бер төркем татар язучылары белән. Алгы рәттә (сулдан уңга): Раушания Низамиева, Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин. Арткы рәттә (сулдан уңга): Камил Кәримов, Афзал Нигъмәтуллин, Равил Рахмани.

Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясен тапшыру тантанасында. 2018 ел.

лары кешелекне бетерү, тарихны сызып ату бәрабәренә булырга тиеш түгел.

– Элек язучы, шагыйрьләргә карата булган ихтирамны бүгенгесе белән чагыштырып та булмый. Ел саен яхшы ял йортларына юллама, бушка фатирлар, зур-зур гонорарлар. Сез дә шул хөррияттә яшәп калдыгызмы?

– 1983 елда СССР (Татарстан) Язучылар союзына кабул иттеләр. И, кемнәр генә юк иде анда. Язучыны өрмәгән җиргә дә утыртмыйлар иде. Бүген халыкның китап укырга вакыты да, сабырлыгы да юк. Аннары телефон бетерде, бөтен кеше шуңа ябышты хәзер. Язучының бүгенге дәрәҗәсе турында шуннан чамаларга мөмкин.

Нәкъ илле ел элек Ринат Закиров безне «Идел» лагерена семинарга җыйды. Ул чакта Ринат Зиннурович ВЛКСМ өлкә комитетында эшли иде. Максаты – иҗатта булган яшьләрне берләштерү. «Идел» лагере шундый матур җирдә, японнар өчен салынган бунгалоларда урнашкан иде. Дүрт-биш көнгә сузылган эчтәлекле, бик җылы семинар булды ул. Мәскәү язучылары, рәссамнары белән очрашулар, лекцияләр узды, безнең хикәяләрне тикшерделәр. Без анда чын мәгънәсендә үсеш алдык. Тик кызганыч, бу зур семинар ике-өч ел гына оештырылды, аннан аерым сәбәпләр аркасында тукталды. Менә шундый чаралар бүген дә бик кирәк, дип уйлыйм.

– Камил абый, укучыларга гаиләгез турында да кызык булыр. Улыгыз, кызыгыз бар икәнен дә беләбез. Алар иҗаттан еракмы?

– Икесе дә иҗат юлыннан китмәде. Кечкенәдән җиләккә барсак – бергә, су коенсак бергә булдык. Мин нәрсә эшлим, малай шуңа барып ябышты. Тик ул мине уздырды, бөтен эшкә кулы ята аның. Ветеринария академиясен тәмамласа да, төзелеш буенча эшли. Холкы буенча үткен. Әнә шул юнәлешкә кереп китте. Яшерен-батырын түгел, хәзер яши торган Шәледәге йортыбызны да улыбыз салып бирде.

Кыз да безгә карата бик игътибарлы. Музыка мәктәбен тәмамлады, тоемлавы яхшы. Икесенең дә гаиләләре бар, бик яратып оныклар сөябез. Аллаһы Тәгалә күпсенмәсен, балалардан уңдык. Әллә нәрсә мактанып, булдырдык дип әйтәсем килми дә, балалар үзләре шундый. Канына кермәсә, кешене тәрбияләп кенә булмый. Төп хикмәт геннарда, дип уйлыйм.

– Күренекле шагыйрь Зөлфәт белән унбиш ел бергә эшләдек.

– Сезгә тиздән 75 яшь тула. Яшь барганын сизәсезме? Яңадан яшьлеккә кайтып булса нәрсәне үзгәртер идегез?

– Яшәгән саен артка борылып карыйсың икән ул. Башта «Яшь ленинчы»да, аннары «Чаян» журналында җаваплы секретарь булып эшләдем һәм инде егерме елдан артык «Казан утлары»ның проза бүлеген җитәкләдем. Әле ярый юлымда дөрес, акыллы киңәш бирүче кешеләр очраган, дим. «Яшь ленинчы»га беренче хикәямне китергән вакытта шагыйрь Хәкимҗан Халиков: «Хикәяләреңне басабыз, ләкин язучы надан була алмый. Энем, әгәр бу юлдан китәргә теләсәң, укырга кер син», – диде. Ә мин ул вакытта су бораулаучы булып аена 500-700 сум акча эшләп йөри идем. Заманасына күрә бик зур акчалар. Һәм шушы эшемне ташлап, Казан дәүләт мәдәният институтына укырга кердем. Кырык сум стипендиягә яши башладым. Әмма һич кенә дә үкенмәдем. Студент вакытта төзелеш отрядларында йөреп, бик күп кешеләр, шул исәптән язучылар белән таныштым. Сорауга җавап шул: яңадан яшьлеккә кайтып булса, бернәрсәне дә үзгәртмәс идем.

– Юбилейга әзерләнәсезме, Камил абый?

– Юк, әзерләнмим. Илле яшьлегемне бик зурлап «Уникс» концертлар залында уздырдым. Анда нинди генә исемле җырчылар катнашмады. Тик хәзер яңадан андый кичә уздырырга көч юк, ә уртачасы гына кирәк түгел. Шулай булгач, уздырмыйм да.

Аллаһы Тәгалә күпсенмәсен, дип кенә яшим. Бәхетне аны каядыр күмеп куйган алтын дип кенә карарга кирәкми. Бәхет ул – сәламәтлек һәм кайбер хыялларның тормышка ашуы. Кочагың җитмәгәнгә, кочакны җәймәскә кирәк икән – яши-яши шуны аңладым.

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Сугыш чоры балалары **нинди** авырлыклар күргән

Батыр егетләр **ничек** разведкага барган

Китап киштәсендә **ниләр** бар

Казанда агач йортлар **ничек** сакланган

БЕЗНЕҢ ЧОРНЫҢ КАЮМ НАСЫЙРИЕ

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Кояшлы апрель урталарында, болай да тынгысыз, шомлы көннәребездә бу олуг затның үлем хәбәре безне сискәндереп җибәрде. Югыйсә без инде аның ике елдан артык өендә авырып ятуын, хәленең шактый мөшкел булуын ишетеп тора идек. Нишлисең бит, адәм баласы яманга түгел, яхшыга өметләнә.

Без – яшьтәшләр, бер чорда, охшаш тормыш шартларында туып-үскән, яшәгән кешеләр. Ярты гасырдан артык бер-беребезне беләбез. Бер коллективта эшләмәсәк тә, кунакларга бик йөрешмәсәк тә, очрашкалап тордык. Бер-беребезнең эш-гамәлләреннән ярыйсы гына хәбәрдар идек. Аның минем хакта, минем аның турында басылган берничә мәкаләбез дә бар.

Икебез дә, нигездә, бер юнәлештә – рухи мирасыбызны, язма чыганакларны, сүз сәнгатебезне өйрәнү өлкәсендә эшләдек. Кайвакыт безнең тикшерү тема-проблемалары, тармаклары керешеп, кушылып та китә иде. Шуңа күрә Марсель Әхмәтҗанов хакында берни дә әйтми кала алмыйм.

ТОРМЫШ ТӘҖРИБӘСЕ АША – ГЫЙЛЕМ ЯКТЫСЫНА

Марсель Әхмәтҗанов Индус һәм Энгель Таһировлар, Җәмит Рәхимов кебек билгеле галим-әдипләрне биргән Лениногорск районы Иске Шөгер авылында – Татарстан нефте табылган тәүге төбәкләрнең берсендә – 1939 елның 26 мартында дөньяга килә. Аның бабалары Казан артындагы Олы Мәңгәр авылыннан була. 1943 елда Марсельләр гаиләсе шул тирәдәге Яңа Кенәргә күчеп кайта. Булачак галимнең балалык һәм үсмер еллары Арча районындагы шул авылда уза. Аны соңгы юлга да шунда озаттылар.

Марсель мәктәп елларында ук тел, әдәбият, тарих белән кызыксына. Исәбе – шул юнәлештә китү. Әмма реаль чынбарлык егетнең планнарын кискен үзгәртә. 1957 елда өлгергәнлек аттестаты алган егет югары уку йортының көндезге бүлегенә керә алмый, моның өчен ике ел эш стажың булу шарт ул елларда. Марсель компрессор заводында, сәүдә системасында һәм кайбер башка урыннарда 10 елдан артык эшли, балта остасы да, товаровед та була. Гаилә әгъзаларының үгетләве буенча авыл хуҗалыгы, химия-технология институтларының кичке бүлекләрендә бераз укып та ала. Әмма тарих, иске китаплар, кульязмалар белән «җенләнгән» егетне болар бик кызыксындырмый.

1963 елда ул Казан университетының тарих факультетындагы кичке бүлеккә укырга керә. Һәм китапханә-архивларда, махсус фондларда тикшеренүләр алып бара башлый. Әмма әле университетны тәмамлагач та, хуҗалык өлкәсендә эшләвен дәвам итә. Ниһаять, яшь белгеч 1972 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага кабул ителә. Җитәкчесе – күренекле галим Фазыл ага Фәсиев. Төп темасы – татар шәҗәрәләре. Өч ел эчендә диссертациясен язып, өстәлгә сала егет. Әмма, Казанда яклау советы булмау аркасында, бу хезмәтне рәсми карау сузыла.

Марсель Әхмәтҗанов, 1981 елда Казахстанның Алма-Ата шәһәрендә диссертациясен яклап, «филология фәннәре кандидаты» дигән гыйльми дәрәҗә алуга ирешә. Г. Ибраһимов исемендәге институтта әүвәл кече хезмәткәр булып эшли, ә 1986 елдан алып (өч дистә елга якын!) – шул гыйльми оешмадагы кульязмалар һәм текстология бүлеге мөдире. 1998 елда ул Казан дәүләт университеты кар-

Фотолар «Татарстан» журналы архивыннан

шындагы гыйльми советта «Яңа археографик материаллар һәм аларның татар әдәбияты тарихын өйрәнүдәге әһәмияте» темасына диссертация яклап, филология фәннәре докторы дәрәҗәсенә ирешә. Шунысын да искәртим: бу могтәбәр затның диссертация яклавы фәнни-рухи тормышыбызда мөһим бер вакыйга рәвешендә кабул ителде. Мин моны Советның секретаре сыйфатында ул процессның үзәгендә кайнаган кеше буларак әйтәм.

ФИДАКЯРЛЕК ҮРНӘГЕ

Марсель Әхмәтҗановның эшчәнлеге гаҗәеп күпкырлы. Ярты йөздән артык китап, меңәрләгән мәкалә. Ул – археограф, тарихчы, әдәбиятчы, телче, фольклорчы, текстолог һәм кайбер башка тармаклар буенча белгеч. Марсель әфәнде эшчәнлегенең үзәгендә – татар яшәеше, аның катлаулы язмышы, рухи мирасы. Ул гомере буе үз халкы өчен тырышты.

Халкыбызның күп кенә ядкәрләре кулъязмаларда таралган. Галим ул төр материалларны туплауга, өйрәнүгә аеруча игътибар бирде. Аның меңәрләгән авыл-шәһәрләрдә булып, дүрт меңнән артык кулъязманы китапханәләргә, махсус фондларга тапшыруы гына да гаҗәеп зур батырлык.

УЛ – КҮПЛӘГӘН ШӘҖӘРӘЛӘРНЕ, ЯЗМА ДОКУМЕНТЛАРНЫ, КАБЕРТАШ ЯЗМАЛАРЫН ТАБЫП, АЛАРНЫ ТИКШЕРГӘН, ХАЛЫККА ҖИТКЕРГӘН ЗАТ.

Чордашым эшләгән өлкә – шактый авыр тармак. Кулъязма текстларны, эпитафик истәлекләрне уку-анализлауның кыенлыгын бик аз кешеләр генә белә. Ул төр текстларда гарәп-фарсы, борынгы төрки сүз-гыйбарәләр дә шактый очрый. Шуңа күрә Марсель Әхмәтҗановның бу юнәлештәге эшендә, иске текстларны хәзерге язуга күчерүдә, аңлатуда төрлелекләр, бәхәсле яклар булуы да табигый.

Мәрхүмнең үзе тапкан, тикшергән шәҗәрәләргә, төрле материалларга нигезләнеп язылган «Нугай Урдасы. Татар халкының тарихи мирасы» китабы да – фәндәге зур казаныш. Галимнең татар фольклорын, этнографиясен, ырым-арбауларын туплаган җыентыклары да бар. Аның «Еллар кичә килгән фикерләр», «Әйтер сүзләрем шулдыр» китапларында урнаштырылган мәкаләләрендә рухи мирасыбызның, фән һәм мәдәниятебезнең, милли тормышыбызның бик күп мәсьәләләре яктыртыла.

«МИРАСХАНӘ»ГӘ НИГЕЗ САЛУЧЫЛАРНЫҢ БЕРСЕ

Марсель Әхмәтҗанов – күренекле текстолог та, дидек. Ул Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Фатих Әмирхан һәм кайбер башка авторларның әсәрләрен, шулай ук дастаннарны әзерләп чыгаруда турыдан-туры катнашты.

Мөхтәрәм галим фәнни процессны оештыруда, кадрлар тәрбияләүдә дә зур эшләр башкарды. Хәзер Казан Кремле территориясендә бик күп кулъязма һәм басма ядкәрләрне, фольклор әсәрләрен, әдип-галимнәребезнең шәхси архивларын туплаган «Мирасханә» уңышлы гына эшләп килә. Аны оештыруда, материаллар туплауда Марсель әфәнде башлап йөрүче булды. Ул биредәге фонд-берәмлекләрне сыйфатлаган тасвирламалар да язды. Алар «Татар археографиясе» исеме белән дистәләгән китап рәвешендә басылып чыкты. Араларында шәҗәрәләргә багышланган берничә җыентык та бар.

Дистәләгән энциклопедия-белешмәлекләрдә басылган, төрле телләрдә дөнья күргән күпләгән мәкаләләр авторы да ул. Шигырьләре, әдәби әсәрләре дә бар.

Шөкер, хезмәте югары бәяләнде: фән докторы, академик, күптөрле премияләр, шул исәптән – Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендәге премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.

Марсель Ибраһим улы Әхмәтҗановның хезмәтләре – рухи тормышыбызның кыйммәтле хәзинәләре. Мәрхүмнең исемен мәңгеләштерү дә көн тәртибендә. Үзе нигезләгән «Мирасханә» дә аның исемен сорап тора. Татар тарихында фәнгә мөкиббән китеп, халыкка армый-талмый хезмәт иткән кешеләр бар. Марсель Әхмәтҗанов – әнә шундый күпкырлы, эшчән шәхесләрнең берсе. Мин аны безнең чорның Каюм Насыйрие дип тә әйтер идем. Мин бу сүзләрне галимнең бер юбилее уңае илә язган идем, шуннан соң 30 еллап вакыт үткән. Әмма алар искермичә, бүген тагын да актуальрәк яңгырый.

Бөек Җиңүгә 80 ел тулу уңаеннан, «Кырык беренче ел балалары» рубрикасын дәвам итәбез. Бөек Ватан сугышы башланган чорда туган, тәпи киткән бу сабыйларның язмышы ничек булып беткән? Нинди могҗиза белән исән калганнар? Әнә шундый өлкәннәребезнең гыйбрәтле язмышларын барлыйбыз.

«БЕЗНЕ ХЕЗМӘТ КЕШЕ ИТТЕ»

Руфия Фазылова

Балтач районы Пыжмара авылында яшәүче Рауза Әсхәдуллина Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган әтисе турында бик аз белә. Күпме эзләтеп тә мәгълүмат таба алмаганнар. Аның каравы, әтисе Нәҗипнең паспорты һәм хезмәт кенәгәсе сакланган. Һәм алар бер дә таушалмаган.

– Кадерләп саклагансыз, ахры, – дим Рауза апага.

– Документлар янында торды һәрвакыт. Әле ярый паспортында фотосы бар, югыйсә әтинең йөз-кыяфәтен дә белмәс идем...

«ӘТИНЕ КАЙТЫР ДИП КӨТТЕК...»

Нәҗип Гарипов Бөек Ватан сугышына Балтач районының Комаров-Завод авылыннан алына. Рауза апа әтисеннән алты айлык булып кала. Гаилә башлыгы фронттан сөйгән хатыны Зәйтүнәгә бер-бер артлы хатлар яза. Тик 1943 елда хатлар килүдән туктый. Берничә айдан Нәҗип Гариповның хәбәрсез югалуы билгеле була. Шуның белән шул...

– Әтинең Украина җирләрендә сугышканын беләбез, – диде Рауза апа. – Әни шулай дип сөйли иде. Балалар Бөек Ватан сугышы музее хезмәткәре Михаил Черапановка да мөрәҗәгать итте, ул да әлеге мәгълүматны раслады. Тик менә төгәл кайда һәлак булганы бер җирдә дә юк. Шуның өчен дә әни гомере буе әтине көтте. Бала чакта без дә, эти кайтыр, дип өметләндек. Дөрес,

Фото: Лилиана Вәлитова

үсә-үсә бу өмет сүрелде. Исән булса, ике баласы, яраткан хатыны янына кайтмый калмас иде.

Рауза апа этисенең хезмәт кенәгәсен ачты. 1910 елда туган Нәҗип Гарипов 4 класс тәмамлаган дип язылган. 1939 елда ул Чепья колхозына ферма мөдире булып эшкә алынган. 1941 елның гыйнварында исә Әтнә авылына колхоз рәисе итеп билгеләнгән. Шуның белән хезмәт кенәгәсендә башка мәгълүмат юк.

– Безнең әти бик тырыш, төпле кеше булган, – дип дәвам итте Рауза апа. – Аракы эчмәгән, тәмәке тартмаган. Әнә шундый җаваплы, үрнәк кеше булганы өчен аны колхоз рәисе итеп куйганнар да. Сугыш башлангач, әти үз теләге белән фронтка киткән. Әни сөйләве буенча, калырга да мөмкинлеге булган. Ләкин ул: «Мин коммунист кеше, ил алдында бурычымны үтәргә тиеш», – дип әйткән.

«ӘНИГӘ РӘХМӘТ!»

Сугышка киткәндә Нәҗип Гариповның өч яшьлек улы белән алты айлык кызы кала. Сөйгәне Зәйтүнәгә соңгы сүз итеп: «Борчылма, сугыш озак бармас, кайтырмын. Колхоз эшеннән калма, балаларны әни карашыр», – дип әйтә. Чынлап та, яшь хатын, ике баласын каенанасына калдырып, колхоз эшенә чыга. Өйдә сыер да бар, кыш ашату өчен азык әзерләргә кирәк. Эшкә киткәнче, һәр көн арба тартып печәнгә бара Зәйтүнә. Әнә шул тырышлыгы аркасында, балалары ачтан тилмерми. Хәер, кул арасына керә башлагач, улы белән кызы да әниләреннән калмый.

– Безне хезмәт кеше итте, – диде Рауза апа, балачагы турында сорашкач. – Үземне белгәннән бирле хезмәттә булдым. Үсмер чагында авыррак эш эшләгәндә: «Әти исән булса, мондый физик эшләрне үзе караган булыр иде», – дип уйлаганнарым истә.

– Әтиегезнең хатлары сакланмаганмы? – дим Рауза апага.

– Юк шул, саклый белмәгәнбез. Хатларның берсендә әти, борчылып: «Сугыш бик каты бара, үлүчеләр күп», – дип язган. Шуннан соң аның бер генә хаты килде, дип сөйли иде әни. 1958 елда без Комаров-Завод авылыннан Пыжмарага күчендек. Әтидән килгән хатлар шунда калмадымы икән, дип уйлыйм. Ул заманда бит хәтер, тарих дигән әйбергә алай игътибар юк иде.

– Ә ни өчен Комаров-Заводтан күчендегез? – дим.

– Пыжмара – әнинең туган авылы. Без монда күченгәндә әле эби, әнинең энисе, абыйсы да исән иде. Аннары, Комаров-Завод авылы кечкенә, ә Пыжмарада ул чагында ук урта мәктәп бар иде. Югары сыйныфларны мин дә биредә укыдым.

...Коридорга чабата тузаны аркылы көлтә-көлтә булып кояш нурлары сузылган иде. Менә дөньяның рәхәте кайда икән! Әле кичә генә без колхоз басуларында көлтә кертә, бәрәңге ташый идек. Үгезне туарып, тәртә арасыннан этеп чыгарганга әле тәүлек тә тулмаган. Тырнак төпләрендәге дегет, оекбаштагы арпа кылчыклары, бирчәйгән уч төпләре – кичәге тормышның истәлеге әнә шулар. Миләр катып калган, аларны кыймылдатмаганга өч-дүрт ай. Миләрдә ике-өч кенә тирән сыр бар. Аның берсе – сугыш, канкойгыч сугыш турында. Фронтка икмәк кирәк. Без, атасыз калган тәртипсез малайлар, әнә шул икмәкне кырдан җыеп, заготзерного озатырга тиешбез. Без инде һәр җәйне шулай эшлибез. Мидә икенче сыр – ашау турында. Кайда гына, кайчан гына авызга кабарлык нәрсә булса, без аны кабарга, йотарга тиешбез. Ә йотарлык әйбер һәр җирдә бар. Көлтә йөгендә утырып кайтсаң – бодай башы уып ашыйсың. Урман буенда – күшә, су буенда кыр суганы, җир җиләге очрый. Амбар тирәсеннән узганда кесәгә борчак тутырып китәсең. Алабута, кычыткан, чөгендер, яшь бәрәңге яфрагы – болары ашка китә. Табигать бай – үз баласын ул ничек тә саклый. Мидә өченче сыр... Өченчесе – юк. Кичә юк иде...

(Мөхәммәт Мәһдиев, «Без – кырык беренче ел балалары» повестеннән өзек)

Рауза апа 1 мартта 84 яшен тутырган. Әле һаман атлап түгел, йөгереп йөри. Югыйсә гомере буе фермада эшләгән, сыер сауган. Хәер, хәзер дә тик тормый: апрель аенда ук илле чеби алып үстергән. Дөрес, үзе генә түгел, бөтен эшне кызы Диләрә белән башкара. Тик йортта хуҗа кеше Рауза апа икән.

– Зәйтүнә эби дә утыз дүрт яшендә ирен югалткан, әни дә шул яшендә тол калган, – дип сүзгә кушылды Рауза апаның кызы Диләрә. – Әти тракторы белән чокырга төшеп капланган. Иң аянычлысы – минем җәмәгатем дә шулай фаҗигале төстә вафат булды. Язмыш диген, әни картайган көндә үз әнисен тәрбияләде, мин исә – үз әниемне. Икенче яктан карасаң, иң авыр вакытларымда әле ярый әни булды. Улым белән кызымны тәрбияләргә әни булышты, безгә күченеп килде ул. Әни сабыр да, шат күңелле дә. Хәзер дә барыбызның күңелен юата. Бик күптәннән намазда, абый, әнем гаиләсе өчен дә көн саен дога кыла.

Чынлап та, Рауза апа елмаеп кына тора, гәрчә күңелендә ниләр барын чамаларга кыен түгел. Кызы Диләрәнең улы Раузат махсус хәрби операция зонасында хезмәттә. Ятса да, торса да, уенда үзе карап үстергән оныгы икән. Ләкин ул борчу-хәсрәтен кешегә күрсәтергә өйрәнмәгән. Гомер буе көчле, сабыр булып, догада яшәүче зирәк акъэбиләрнең берсе. Тормыш аны шуңа өйрәткән. Инде бары бер теләк – Рауза апага яраткан оныгы Раузатның бөтенләйгә өйгә кайтуын, аның гаилә корып, бәхетле тормышын күрергә язсын.

ХӘТЕРНЕҢ ДӘҺШӘТЛЕ БИТЛӘРЕ

1948 елда Казан Тел һәм әдәбият институтының фольклор секторы галимнәре Хәмит Ярми белән Халидә Гатина һәм булачак язучы, ул вакытта Казан университеты студенты Нурихан Фәттахов сугыштан соң беренче тапкыр Татарстанның Актаныш, Калинин (бу район 1959 елдан Актаныш һәм Мөслим районнарына бүлеп бирелә), Мөслим һәм Минзәлә районнарына фольклор экспедициясенә чыгалар. Сугыш тәмамланып өч ел узган. Әмма, тыныч тормыш башлануга карамастан, сугыш турындагы истәлекләр дә, ул калдырган яралар да яңа була әле. Бу экспедицияләр вакытында галимнәр белән аралашучыларның, мәгълүмат бирүчеләрнең дә күбесе – Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр, фронтовиклар. Алар Бөек Ватан сугышы турында шактый гына истәлекләре белән дә уртаклашалар, үзләре катнашкан яулар, дошман тылына разведкага барулары, сугышчан дуслары турында да сөйлиләр.

Сезне дә 1948 елгы шушы фольклор экспедициясе вакытында Халидә Гатина белән Нурихан Фәттахов язып алган сугыш турындагы истәлекләр белән таныштыруны дәвам итәбез. Язмаларны, сөйләүчеләрнең сөйләм үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, үзгәрешсез тәкъдим итәбез. Сугыш ветераннарының җанлы сөйләме истәлекләрдәге вакыйгаларны тулырак күзалларга, шул чорның дәһшәтен тоярга ярдәм итәр, дип өметләнәбез.

Фотолар: Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фондыннан.

МИРЗА ИБРАҺИМОВ: «БЕР ТАНКНЫ ДА ҮЗЕБЕЗНЕҢ ЯККА ҖИБӘРМӘСКӘ!»

Илсөяр Закирова

Сугыш истәлекләре белән Чалманарат авылында колхоз счетоводы булып эшләгән 23 яшьлек Мирза Ибраһимов уртаклаша. Ул Украинада, Днепр буенда барган каты яуларда япь-яшь егет килеш катнаша. Сугыш беткәндә 20 яшендә генә була. Мирза Ибраһимов үзенең беренче тапкыр яралануы турында да сөйли. Шуны да әйтеп китү урынлы була: 1952 елның ахырында Мирза Ибраһимовның улы Илфак дөньяга килә. Ул, үсеп җитеп, әдәбиятта Мөхәммәт Мирза исеме белән танылачак.

Сугыш истәлеген 1948 елның 13 июлендә Нурихан Фәттахов язып ала.

КУКУРУЗ АРАСЫНДА...

Днепрның сул ягында идек. Безгә нимесне киң җиргә җәелдермәскә кирәк. Нимес безгә таба кереп, җәелергә тырыша. Шуны тоткарлап калырга кирәк.

Бер украин авылында торабыз. Штабтагы посыльный, взвод урнашкан йортка килеп, безне уятты. Комбатареи урнашкан йортка илттеләр. Үзебезнең взвод белән бардык. Безгә комбатареи икенче бер полкка тапшырылуыбыз турында аңлатты. Безне комбатареи белән сөйләшкәндә аерым машиналар көтеп торды. Шушы машиналарга төялеп, икенче бер полкка китәргә тиешбез.

Төнлә килеп төштек бу полкка. Үзебезнең расчетка тиешле пушкаларны кабул иттек. Ә таң ату белән авылдан ашыгыч чыгып та киттек. Фронт бездән 25 километр иде. Таң атар алдыннан, машиналар белән бар-

Хәмит Ярмөхәммәтов экспедиция вакытында. 1948 ел.

ганда, передовой линиягә ике километр кала, үзләре урнашкан участоктан яраланып чыгучы сугышчыларны очраттык. Сугышчылардан фронт хәлләрен сораштырдык. Алар немесләрнең көнгә берничә мәртәбә, үзләренең калган плацдармларын киңәйтү өчен, зур-зур көчләр белән һөҗүмгә килгәннәрен сөйләделәр.

Машиналар калкулык астында калды. Без, пушкаларны тартып, тауга алып менәргә тиешбез. Тау башын безнекеләр кичәге көнне генә алганнар икән. Без пушканы, маскировать итеп, тартып алып менеп киттек. Бу вакытта инде яктыра башлаган иде. Немеснең бер батареясы безгә ата башлады. Тирә-якта – кукуруз басуы. Үле немес гәүдәләре, безнең сул якта ватылган пулемет ята. Әле безнекеләр трофей җыйнарга да өлгермәгән. Кичә генә булган ул операция. Снарядлар бик якын төшә башлады. Без барыбыз да пушкадан 4–5 метр читкәрәк, кукуруз арасына кереп яттык. Бездән ерак түгел генә ярылган немес снаряды үзебезнең иптәшне – Сталинград егетен каты яралады. Мин тиз генә бер иптәшем белән шуышып барып аягын бәйләдем. Аны, плащ-палаткага салып, машинага илтеп куйдык. Бик әйбәт җегет иде, аерылышу кыен булды.

Безгә тизрәк пушканы огневой позициягә илтергә кирәк. Кукуруз сабаклары арасыннан үзебезнең пушка кырыена юнәлдек. Мин командир орудиесе кырында тора идем. Ул пушканы кукуруз арасына эчкәрәк алып кереп урнаштырырга кирәклеген әйтте. Бу вакытта тәмам яктырган иде инде. Без бер шуышып, бер тезләнеп, пушканы сөйрәп киттек. Кемдер арттан этеп барды. Көн якты булгач, аны бик саклык белән, җайлап урнаштырырга кирәк иде. Урнаштырдык.

Экспедиция әгъзалары Нурихан Фәттахов, Шәһидә Максудова һәм Халидә Гатина колхозчы белән әңгәмә вакытында. Актаныш авылы. 1948 ел.

Бу вакытта уң яктан, куаклык арасыннан, безнең танклар наступать итә иде. Боларны без күзәтеп кенә торабыз. Безнең танклар наступлениесе уңышлы чыкмады. Немесләр нык тора. Бу наступлениедән соң, полк командованиесе хәбәр ала – безнең участокка танклар наступлениесе көтелә. Без противотанковый истребительный полк булганлыктан, танк һөҗүме куркынычы булган участокка урнаштырылган идек. Безгә бик ныклы хәзерлек белән торырга кирәклеге турында комбатареи әйтеп чыкты. Расчетыбыздагы егетләр белән һәрберебез дә актыкка чаклы нык торырга, бер немес танкын да кертмәскә сүз куештык.

РӘХМӘТ ӘЙТЕП, КУЛЫМНЫ КЫСТЫ

Шулвакыт ерак түгел беренче немес танкы күренде. Без түземсезлек белән беренче снарядны җибәрергә әзер торабыз. Комбатареи төбәп атарга приказ бирде. Беренче җибәрелгән подкалибрный снаряд немес танкына тиде. Танк туктады. Мин беренче мәртәбә наводчик булып аткан снаряд иде ул. Бу беренче уңыштан соң, үзем эссе-ле-суыклы булып киттем. Тагын да ныграк җан керде. Туктаган танктан немес солдатлары төшеп тирә-якка чәчелделәр. Танктан пулемет ата башлады. Моны ничек тә бетерергә кирәк. Мин икенче снаряд җибәрдем. Танкта ут күренде. Ут күренү белән, мин бу танк белән эш бетте дип куйдым. Монысы белән күңел тынычланды.

Ләкин әле танклар күп. Аларны да җимерергә кирәк. Теләк бер генә – бер танкны да үзебезнең якка җибәрмәскә, дөмектерергә бөтенесен дә. Мин тагын бер снаряд җибәрдем – тимәде. Танк һаман килә. Мин бөтен күңел белән танкист мине күргәндер, миңа киләдер, дип уйлыйм. Ләкин немес танкы төбәп атмады. Миңа бик зур мөмкинлек туган кебек булды. Ныгытып төбәп икенче снаряд җибәрдем, танкта ут күренде. Ут күренү белән, немесләр төшеп йөгерә башладылар. Бездән бер 100-150 метрлар чамасы алда урнашкан пехота аларга каршы ут ачты.

Танк белән эшне бетергәч, үземдә немеснең бу тимер җен машинасы белән көрәшергә көч барлыкны сиздем. Орудиенең башка нумерлары да үз эшләрен җитез башкарып торды. Сугыш кырын төтен, тузан каплады. Немесләр артиллериясе үз танкларына нык ярдәм итә. Хәзер немеснең танклары артканнан-арта кебек күренә башлады. Шушы вакытта безнең расчетта бары өч кенә кеше калды, өч иптәш яраланды.

Өченче танкка ата башладым. Беренче атудан тегенең гусеницасы өзелде. Ләкин танк пушкадан атуын дәвам итә. Шул вакытта мин бер осколочный снаряд җибәреп калам немес пехотасына. Бу вакытта инде танклар безгә якынлашып киләләр. Кисәк кенә тәнемдә кызулык сиздем. Бик каты удар булды. Уштан яздым. Аңыма килсәм, яраланганымны сиздем. Шул вакытта минем иптәш Калащенко – украин егете – өченче танкны да тончыктырган. Мин ныгытып ушыма килгәндә, безнең пехота һәм танклар наступлениегә күчкәннәр иде. Һавадан авиация ярдәм итә.

Бераздан мине санчастька алып киттеләр. Санбатта полк командиры, килеп, минем Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнүем турында белдерде һәм, рәхмәт әйтеп, кулымны кысты. Безнең гаскәрләрнең наступлениегә күчкәннән соң, немесләрне куып, ике авылны алганлыкларын әйтте.

«ВАСИЛЬЕВСКИЙ» ШИФАХАНӘСЕ: БАРЫСЫ ДА ҖИҢҮ ӨЧЕН

8 майда «Васильевский» шифаханәсендә хәрби табибларга һәйкәл белән сквер-мемориал ачылды. Бөек Ватан сугышы елларында бу шифаханәдә госпиталь урнашкан була, анда 334 мең сугышчы дәвалану һәм реабилитация курслары үтә.

ЙОКЫСЫЗ АВЫР ХЕЗМӘТ

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән фронттан тылга яралылар агыла башлый. Илдә тиз арада госпитальләр оештырырга кирәк була. Биналарга, кадрлар, җиһазлар, медицина кирәк-яракларына, даруларга кытлык булуга карамастан, ТАССР-да бик кыска вакыт эчендә госпитальләр челтәре җәелдерелә. «Сугыш вакытында ТАССРда 42 меңгә якын койка урнаштырылган 69 эвакогоспиталь һәм 1500 урынлык обсервация пункты эшли башлый. Республикада барлыгы 334 мең яралы солдат дәвалану һәм реабилитация курсы үтә», – диелә ТР Дәүләт архивында.

«Васильевский» шифаханәсе дә хәрби госпиталь итеп үзгәртелә. Эвакогоспиталь 1941 елның 12 сентябрендә ТАССР һәм Удмуртия буенча Бөтенсоюз үзәк профсоюзлар советы Госпитальләр идарәсенең 10 нчы боерыгы буенча ачыла.

Госпитальнең беренче башлыгы элеге медицина учреждениесен оештырган I ранглы хәрби табиб Яков Израилевич Розенблит була, медчасть башлыгы итеп II ранглы хәрби табиб Израиль Яковлевич Морейнис билгеләнә. Беренче яралыларны – 237 кешене – 4088 нче госпиталь 1941 елның 8 нче октябрь төнендә кабул итә.

Васильевода һәрбер яралы солдатны барлык кагыйдәләр буенча җиһазландырылган санпропусник каршы ала, чөнки кырыс сугыш чоры һәм халыкларның масштаблы күчеше ТАССРда тиф, кызамык, дизентерия кебек авыруларның таралуын китереп чыгара. Әмма эпидемиягә каршы көрәш нәтиҗәсендә 1943 елга республикада тиф авыруы йоктыручылар саны – 6 тапкырга, дизентерия – 2, кызамык 4 тапкырга кими.

Госпитальнең өлкән шәфкать туташы Анна Васильевна Геродатова, яралылар эшелоны-эшелоны белән кайта иде, дип искә ала. Санитарка һәм шәфкать туташлары булып ул вакытта башлыча хатын-кыз эшли, алар авыр яралыларны процедураларга күтәреп йөртә, сугышчыларны карый, ашата, күнегүләр ясарга булыша. Дарулар, эчке кием, савыт-саба җитми. Ягулык утынны да үзебезгә табарга туры килә иде, дип искә ала госпитальдә ашарга пешерүче булып эшләгән Ирина Щетинина.

Госпиталь хезмәткәрләре авыруларны тернәкләндерү өчен барысын да эшли – моллюсклардан котлет ясаулары турында әйтү дә җитә, тәме бавыр паштетын хәтерләтә торган була. Витаминнар урынына пациентларга ылыслы ботаклардан, юкә чәчәгеннән, гөлҗимештән төнәтмәләр, шулай ук каен суы, кызыл чөгендер суы, юа бирәләр. Госпитальнең ярдәмче хуҗалыгында сыерлар асрыйлар, шуңа яралыларга сөт һәм сөт ризыклары да эләгә.

АВЫР ЯРАЛЫЛАРНЫ КАБУЛ ИТӘЛӘР

Госпиталь гомуми хирургия буенча махсуслаша, бирегә авыр яралы сугышчыларны китерәләр. Табиблар тәүлекләр буена госпитальдә калып, алсыз-ялсыз эшли. Госпиталь ачылганнан алып, 1942 елның урталарына кадәр операцияләрне бер хирург, бер квалификацияле сестра һәм җәрәхәтләрне бәйли торган ике шәфкать туташы башкара. Тора-бара җиһазландыру яхшыра, хирургия бүлекләре дә киңәйтелә. 1943 елның икенче яртысында гына да госпитальдә 1031 операция ясыйлар.

Көндәлек киеренке хезмәт шартларында эвакогоспитальдә укыту эшчәнлеге дә алып барыла. 1942 елның гыйнварында госпиталь табиблары өчен хәрби-кыр хирургиясе һәм нейрохирургия буенча курслар оештырыла. 1942

Фотолар «Васильевский» шифаханәсеннән алынды. РЕКЛАМА
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

елның 22 июненнән шәфкать туташлары өчен курслар ачыла: исемлектә 15 кеше исәпләнә.

Даими рәвештә табиблар һәм урта звено медицина хезмәткәрләре өчен фәнни конференцияләр үткәрелә. Шунда ук дәваланучы авырулар үрнәгендә тематик семинарлар да оештырыла. Яраларны дәвалау, кан салу, периферия нерв системасына зыян килү кебек темалар карала.

1941 елның көзендә физиотерапия бүлекчәсе яңадан җиһазландырыла, күп кенә приборларны пациентлар үзләре ремонтлап, җайга сала.

Аппаратлардан кварц, соллюкс, яктылык ярымванналары, дорсенваль була. Парафин белән дәвалау, гидротерапия, торф белән дәвалау, файдалы гимнастика, хезмәт терапиясе кулланыла.

2025 елның 7 маенда, «Васильевский» шифаханәсе тарихының сугыш сәхифәләрен истә тотып, 4088 нче госпиталь табибларына һәйкәл ачтылар. Госпиталь Бөтенсоюз үзәк профсоюзлар советы системасында иң көчлеләрдән саналган, анда эшләүчеләр сугыш елларында үрнәк күрсәткән, дип билгеләп үтте мемориал ачу тантанасында ТР Профсоюзлар федерацясе рәисе Елена Кузьмичева.

2024 ЕЛНЫҢ ИЮНЕНДӘ «ВАСИЛЬЕВСКИЙ» «ЗДРАВНИЦА» XXIII БӨТЕНРОССИЯ ФОРУМЫНДА БЕРЬЮЛЫ ӨЧ НОМИНАЦИЯДӘ ҖИҢҮ ЯУЛАДЫ. ШУННАН СОҢ УК – «ТРНЫҢ ИҢ ЯХШЫ ТОВАРЛАРЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ» КОНКУРСЫНЫҢ «ХАЛЫК ӨЧЕН ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ» НОМИНАЦИЯСЕНДӘ ҖИҢҮ ҺӘМ «РОССИЯНЕҢ ИҢ ЯХШЫ 100 ТОВАРЫ» КОНКУРСЫНЫҢ ФЕДЕРАЛЬ ЭТАБЫНА ҮТҮ. Ә БЫЛТЫР СЕНТЯБРЬ АЕНДА «ВАСИЛЬЕВСКИЙ» ЕЛ САЕН УЗА ТОРГАН «СӘЛАМӘТ ИЛ ҮСЕШЕ ӨЧЕН ИНВЕСТИЦИЯЛӘР. ЦИФРЛАР. ФАКТЛАР. МӨМКИНЛЕКЛӘР» ФОРУМЫ КЫСАЛАРЫНДА «КИЛЕНТЛАР ӨЧЕН ЭШЛИ ТОРГАН ИҢ ЯХШЫ 5 ШИФАХАНӘ» БӨТЕНРОССИЯ КОНКУРСЫНДА БЕРЕНЧЕ БИШЛЕККӘ КЕРДЕ. ШИФАХАНӘ «ИҢ ЯХШЫ МЕДИЦИНА БҮЛЕКЧӘСЕ» НОМИНАЦИЯСЕНДӘ ҖИҢҮЧЕ БУЛДЫ.

ИҢ БИЛГЕЛЕ ШИФАХАНӘЛӘРНЕҢ БЕРСЕ

Бүген «Васильевский» – гаилә форматындагы заманча шифаханә, анда бүген төп бурыч булып өлкәннәрне һәм балаларны ял иттерү һәм сәламәтлекләрен ныгыту тора. Ул күппрофильле шифаханә, анда йөрәк-кан тамырлары, нерв системасы, гастроэнтерология, гинекология, пульмонология һ.б. авыруларны дәвалыйлар.

Шифаханә территориясендә чыгарыла торган минераль сулар составында ортоборлы кислота булган сульфатлы-хлоридлы-натрийлы төркемгә карый, ул күп авыруларны дәвалаганда ярдәм итә.

Шифаханәдә минераль, ылыслы-энҗеле, ылыслы, каштанлы, радонлы, күкертле, скипидарлы, шулай ук Алтай мараллары мөгезләреннән алынган экстарктлы ванналар бар. Төрле душлар, шул исәптән су асты душлары да эшли.

«Васильевский»дагы иң нәтиҗәле дәвалау төренең берсе – барокамерада гипербарияле оксигенотерапия. Шулай ук классик, аюрведа, висцераль, аппаратлы массажлар һәм мануаль терапия бар.

• Пациентларның иң яраткан процедураларыннан «марутака» аппараты ярдәмендә аяк табаннарына акупунктур массажны атарга була. Япониянең шиацу методикасы белән дәвалау аяк табаннарындагы нокталарга энәсез генә йогынты ясауга нигезләнә. Аяк табаннарына массаж аяклардагы кан һәм лимфа әйләнешен яхшырта, киеренкелекне, шешенүне бетерә, шулай ук кан басымын, үзәк нерв системасын һәм йокыны нормага сала.

• Кунаклар «Васильевский»да йокы яхшыра дип билгели. Моңа стресслардан, көндәлек тормышның ыгы-зыгысыннан арынып тору, нарат урманының кислородка бай һавасы, шулай ук көннең режимга көйләнгән булуы һәм рәхәтлек китерә торган процедуралар да ярдәм итә.

• Кунаклар глэмпинг белән дә кызыксына. Бу күл тирәли уңайлы итеп төзелгән бәләкәй генә өйләр. «Люкс»тан «стандарт»ка кадәр номерлары булган 4 торак комплексыннан сайлап алу мөмкинлеге каралган.

• Кыска вакытлы ял яратучылар өчен өч көнлек турлар да бар. Аңа диеталы туклану, бассейнда йөзү, спелеотерапия, фитотерапия, спорт һәм мәдәни-күңел ачу программалары керә.

• «Васильевский» кунаклары игътибарына акцияләр һәм ташламалар каралган. Мәсәлән, сайт аша бронь ясаганда, дисконт 10% ны тәшкил итә.

ТУГАН ТӨБӘККӘ ХЕЗМӘТ ИТҮ ҮРНӘГЕ

Адәм баласы, мөмкин булганда, әллә кайдагы ерак төбәкләргә омтылырга түгел, ә кече ватанында, үз туфрагында калырга тиеш. Яшь әгерҗелеләр өчен бу җәһәттән муниципаль район башлыгы менә дигән үрнәк булып тора.

Әгерҗе районы бүген нинди? Әгәр саннар телендә сөйләшәбез икән, динамик рәвештә үсеш кичерә, алгарышы белән куандыра торган территория турында сүз барганын аңлыйбыз. Икътисадның төп юнәлешләре биредә – сәнәгать, авыл хуҗалыгы, төзелеш һәм транспорт. Узган елның күрсәткечләре дә моны раслап тора: тулай төбәк продукты – 10,5 миллиард сумны (2023 елга өстәмә 3 процент) тәшкил итә, үзләре җитештергән продукцияне төяп озату, күрсәткән хезмәтләр белән эшләнгән эшләр күләме – 6 миллиард сум (+7), түләнгән айлык уртача хезмәт хакы – 66 228 сум (+20,6). Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары – 613 берәмлек (+5). Бу өлкәдә мәшгульләрнең саны 3 096 кешене тәшкил итә. Әлеге сан Әгерҗе җирле икътисады төп локомотивларының берсе – тимер юл хезмәткәрләре исәбенә тәңгәл. Сәнәгать җитештерүе индексы – 104,3 процент, эшсезлек дәрәҗәсе 0,2 процент.

Һичшиксез, бу күрсәткечләр – район башлыгы эшчәнлегенең дәрәҗәсен раслый торган мисаллар. Үзенә ышанып тапшырылган районның тормыш-көнкүреше өчен, иң беренче чиратта, нәкъ менә ул җаваплы. Әгерҗе районына бу яктан уңыш елмайды, дия алабыз: аны яшь, максатчан, мөһим карарларны тиз һәм тиешле югарылыкта кабул итәргә әзер зат җитәкли. Ә иң әһәмиятлесе – үзе дә тамырлары белән шушыннан булган егет, Әгерҗе кешесе.

– Ленар Фәритовичны 2000 нче еллардан бирле беләм. Ул чакта, авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлагач, агрофирмага эшкә килде. Мин ул оешманың җитәкчесе идем, – дип сөйли район Башкарма комитеты җитәкчесе Илгиз Салихов. – Иң баштан ук бу яшь белгеч үзенең булдыклылыгы һәм төплелеге белән җәлеп итте: беркайчан да, миннән киткән, иясенә җиткән, дип кенә эшләмәде, ә һәрвакыт эшнең төбенә, асылына төшеп, аңларга тырышты. Эшлеклелегенә өстәп, аңа һәрчак үзенең белемен арттыру, күнекмәләрен камилләштерү сыйфатлары да хас. Мин боларны хәтта аның холына хас аерым бер үзенчәлекләре дә дияр идем. Еллар узу белән, идарә итү һәм администрация эшен алып бару тәҗрибәсе туплаганнан соң, җитәкче дәрәҗәсенә үсеп җитүе – табигый хәл. Район аның кул астында теләсә нинди кыю һәм амбицияле проектларга алынырга әзер, дип уйлыйм.

Бу сүзләр район башлыгы Ленар Нургаяновның үзе сөйләгәннәргә дә тәңгәл:

– Туган җирендә кирәкле кеше бул. Халык моны белми генә әйтмәгән бит инде. Мин дә үземнең туган төбәккә кирәкле белгеч булырга тырыштым. Мин Сарсак-Омга лицеен тәмамладым. Вузда укыганнан һәм Алабугада эшләгәннән соң, туган ягыма әйләнеп кайттым. Максатым районның социаль-икътисадый темпларын арттыру иде. Безнең бер йодрык кебек бердәм команданың бу максатка ирешерлек көче бар, дип ышанам.

Команда, үз чиратында, чынлап та әлеге ышанычны акларга әзер. Үз лидерларына хас сыйфатларны да шунда ук санап бирделәр. Аларның сүзенә караганда, беренчедән, Ленар Фәритович бик булдыклы, карарлар кабул иткәндә, җиңел эш итә икән. Икенчедән, аның кыюлыгына басым ясадылар, территория өчен әһәмиятле кайбер четерекле карарларны кабул иткәндә, ул бар җаваплылыкны үз өстенә алырга курыкмый, диләр. Өченчедән, ул стрессларга бирешми. Ә бүгенге гел үзгәреп торган заманда бу сыйфат булмаса, эчке мобилизация дә мөмкин түгелдер.

– Хөрмәтле Ленар Фәритович, туган көнегез белән котлыйбыз! Сезгә район өчен иң кирәкле карарларны кабул иткәндә һәм муниципалитет алдында торган бурычларны үтәгәндә ныклык, көч-куәт телибез! Әгерҗе халкы сезне тыңлый белүегез өчен генә түгел, ә ишетә белүегез өчен дә хөрмәт итә! Кем генә мөрәҗәгать итсә дә, баламы ул, өлкән яшьтәге кешеме, әллә инде махсус операция ветераныммы, сез аларның сүзен аяк астына салып таптамыйсыз. Ныклы адымнар белән алга атлыйсыз – бу без, коллегаларыгыз өчен дә, төп ориентир, әгерҗелеләр өчен дә үрнәк. Ә яшьләр өчен сез – туган ягын күтәрү өчен бар көчен куйган мөхтәрәм зат!

Әгерҗе муниципаль районы Советы
һәм Башкарма комитеты хезмәткәрләре

ЛЕНАР НУРГАЯНОВНЫҢ КӨМЕШ АТЫ

«Туган ягыңа хезмәт итү – ул язмыш эше» – шуны аңлаудан һәм үзеңне туган туфрагыңа багышлаудан башлана барысы да. Ул очракта кеше төбәгенә бик зур файда китерә ала. Аны калдырып торган чагы булса да, белем һәм тәҗрибә туплар һәм әйләнеп кайтыр өчен. Татарстанның Әгерҗе районы башлыгы Ленар Нургаянов – әнә шундыйлардан.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго»
АҖ генераль
директоры

ТАТАРСТАННЫҢ «КАЛИНИНГРАДЫ»

Республикадагы теләсә кайсы муниципалитеты үзенең уникаль урыны белән мактана ала, әмма җавап буларак гадәттә: «Андый гына бездә дә бар», – дигәнне ишетә. Шулай да Әгерҗе районы очрагында хәлләр башкачарак. Ул – республиканың үзе белән коры чикләре булмаган бердәнбер районы. Территориясе Удмуртиягә кереп тора, ә Татарстаннан ул Кама сулары белән бүленгән. Аналогияләр эзләгәндә, башка килгән беренче уй - Калининград өлкәсе. Ул да Россиядән нигездә сулыклар белән аерылып тора. Дөрес, бүгенге заманда «аерылып тору» ул әле «кисеп ташланган» дигән сүз түгел. Әгерҗе кешеләре дә үзләрен республикадан аерылган дип исәпләми, башкаларга да алай уйларга юл куймый.

– Бездә ирекле икътисадый зона. Без беркемне дә кысаларга кертмибез, – дип белдерде әле күптән түгел генә ТР Инвестицияле үсеш агентлыгында узган «Муниципаль инвестиция сәгате»ндә район башлыгы Ленар Нургаянов.

Чынлап та районның перспективалары гаять зур, шул ук Удмуртия белән күршелек хисабына да: республиканың алты территориясе Әгерҗе районы белән чиктәш бит. Авыл хуҗалыгы тармагын һәм Россиянең хәлиткеч сортировка станцияләренең берсе саналган Әгерҗе станциясен үстерү белән бергә, болар барысы да үсешнең төп нокталары булырга тиеш.

ТУГАН ЯККА ТУГРЫЛЫК

Планнарны тормышка ашыру муниципалитетта Ленар Нургаянов җитәкчелегендә тормышка ашырылачак. Район башлыгына әгерҗелеләрнең ихтыяҗлары да, омтылышлары да яхшы таныш. Ул – шушы җирлектән. 1985 елда Әгерҗе районының Тирсә авылында туып-үсә. Ижевск дәүләт авыл хуҗалыгы академиясендә укый, ике һөнәр үзләштерә – инженер һәм менеджер-икътисадчы. 10 елдан артык районның агросәнәгать секторында эшли, 2018 елда Алабугага муниципаль хезмәткә алына. Анда ул район авыл хуҗалыгы башлыгыннан башлап, башкарма комитет җитәкчесе дәрәҗәсенә кадәр үсә. 2023 елда Ленар Нургаянов яңадан үз районына әйләнеп кайта. Башта район башкарма комитетында хезмәт куя, 2023 елның сентябреннән – район башлыгы.

Биографиясенең әлеге кыска гына сәхифәләреннән дә Ленар Нургаяновның административ эш буенча тәҗрибәсе дә, муниципалитет ягыннан компетенциясе дә барлыгы көн кебек ачык. Болар аңа икътисадый һәм социаль вазгыятьне аермачык күзалларга, конкрет максатлар белән бурычлар куеп, аларны хәл итәргә булышачак. Бу инде хәзер үк күзгә ташлана – 2024 елның социаль-икътисадый рейтингында Әгерҗе районы 5 урынга өскә күтәрелде. Моннан тыш, район ике ел эчендә 90 процентка кадәр таушалган җылылык челтәрләрен алыштыруга ирешә алган Татарстандагы беренче муниципалитет буларак танылды. Күпләр өчен мондый казаныш әле ерак киләчәк эше булып тора.

Киләчәк дигәннән, Ленар Нургаянов аңа район башлыгы буларак кына түгел, ә гаилә башлыгы вазыйфасында да зур җаваплылык белән карый. Чөнки ул әле – күп балалы әти дә. Өч баласын кеше итәргә кирәк аңа.

– Хөрмәтле Ленар Фәритович!

Сезнең белән безнең уртак туган ягыбыз гербында көмеш атка атланган милли киемле ир-ат сурәтләнгән. Уң кулы белән ул алга күрсәтеп тора, шул рәвешле, әйтерсең, Әгерҗе төбәгенең үсешенә, алгарышына ишарәли. Миңа хәзерге вакытта бу фигура нәкъ менә сезгә тәңгәл булып тоела. Сез – үз эшегезнең остасы, максатчан зат, еллар буена туплап килгән тәҗрибәгез дә бар. Әле кырык яшегезне генә билгеләп узсагыз да, сезгә олпат зирәклек хас.

Сезне күркәм бәйрәмегез белән тәбриклим һәм ат ияренда нык утыруыгызны, гербтагы рухка һәм көчкә ия булуыгызны телим. Җилләр һәрчак сезгә уңай яктан иссен, дөрес кыйбланы сайлап, тиешле ирекне дә калдырып, алга барырга булышсын. Ә безнең компаниябез элеккечә, булдыра алган кадәр сезгә ярдәм итәргә, таяныч булырга әзер!

Фото: ТР Әгерҗе районы матбугат хезмәтеннән алынды

РУХНЫ БАЕТА ТОРГАН ЯЛ КИТАПЛАРЫ

ЧОР ҺӘМ ШӘХЕС ДИАЛОГЫ

ГҮЗӘЛ ЯХИНА, «ЭЙЗЕН» 18+

АСТ, Елена Шубина нәшрияты, 2025

«Эйзенштейн минем өчен һәрчак әһәмиятле фигура булды, формалашуыма зур йогынты ясады. Берара караватым өстендә хәтта «Иван Грозный» фильмыннан фотографияләр дә эленеп торды. Әлеге режиссёр – минем өчен гаять олы, масштаблы, пәһлеван фигура. Кино сәнгатенә килүемә дә Эйзен сәбәпче булды. Һәм менә, ахыр чиктә, шушы китап язылды».

Гүзәл Яхина

Гүзәл Яхинаның дүртенче романы 2025 елның 5 мартында барлык китап платформаларында һәм кушымталарында пәйда булды. Тере форматта аңа шактый алдан заказ биреп куярга мөмкин иде, китап кибетләрендә ул киштәләрдән беренче көннәрдә үк күпләп алынды. Сатулар рекорды исемлегенә керде.

Сүз уңаеннан, аны бик яхшы аудиоформатта да тыңларга мөмкин – сыйфаты ягыннан да, вакытны экономияләү өчен дә менә дигән вариант. Юлга чыкканда, машинада йә колакчында кабызып куйсаң, 19 сәгатьтән артык вакыт аралыгында тыңлап бетерергә мөмкин.

Һәрчак архивлар һәм киң катлам документлар белән эш итәргә, сәнгатилек белән документалистика арасындагы элпәне эретеп, аларны кушып, синтез булдырырга омтылган Гүзәл Яхинаның бу романны язганда да үзенә тугры калуы гаҗәпләндерми. Ул гомумән, кайсы гына темага һәм материалга алынмасын, совет чорының башлангыч, катлаулы еллары темасына әйләнә дә кайта. Романның герое буларак кемне сайлавы гына бераз гаҗәпләндерде. Хәер, кино сәнгате аша әдәбиятка килүен исәпкә алсак, монысы да мантыйкны бозмый шикелле.

«ЭЙЗЕН» РОМАНЫ САТУГА БЕРЕНЧЕ СТАРТ ТИРАЖЫ БУЕНЧА 50 МЕҢ НӨСХӘДӘ ЧЫГАРЫЛДЫ.

Әңгәмәләреннән күренгәнчә, Сергей Эйзенштейн язмышы аны әле үсмер елларыннан, 13 яшеннән бирле кызыксындырган икән. Безнең барыбыз өчен дә бу шәхес – совет кинематографының чишмә башында торган, 1920 нче еллар символы булган зат. «Иван Грозный», «Броненосец Потёмкин», «Стачка», «Октябрь», «Александр Невский» – әлеге фильмнарны, үзләре карамаса да, ишетеп белмәгән совет кешесе булмагандыр, мөгаен.

Гүзәл Яхина әсәренең жанрын «роман-буфф» дип атый һәм бу чыннан да бөтен тормышы рампалар астында узгандай яшәгән Эйзенштейнны гәүдәләндерүдә отышлы алым. Алай гына да түгел, аның бит чоры да нәкъ шундый. Тирәнгәрәк кереп укыган саен, аңлашыла төшә: Яхина биредә үз заманының куккә чөелгән, шул ук вакытта һәр адымы өзлексез энә күзеннән уздырылган шәхеснең трагик язмышына алып чыга. Экраннан тамашачыга беренче фильмында ук кукиш күрсәткән һәм түрәләргә үз кануннарын тага алган даһи эчке каршылыклары белән ничек көрәшә? «Мораль» һәм «кысалар» дигән дилбегәләрдән тыш, яшәү аңа нинди өстенлекләр бирә һәм ахыр чиктә нәрсәгә китерә?

Даһи режиссёрның әнисе, гаиләсе, хатын-кызлар, дуслары белән катлаулы мөнәсәбәтләренә дә орынып уза автор. Ахыр чиктә, бу китап безгә шәхес һәм чор диалогы шаһитлары булырга мөмкинлек бирә. Без һәммәбез дә кабатланмас Эйзенның плёнкага язылган язмышын күздән кичерәбез, әйтерсең.

Фото: goodfon.ru, www.livelib.ru



Луиза Янсуар

Тиздән җәйге яллар башлана. «Татарстан» журналының бу санында 2025 елгы топ-китаплар исемлегеннән төшмәгән ике китап белән таныштырабыз. Отпускка аларны үзегез белән алсагыз, үкенмәссез.

БӘЛКИ, УПКЫН БЕЗГӘ КҮПТӘННӘН КАРЫЙДЫР?

УЛ ШУЛ СОРАУГА ҖАВАП ТАБАРГА ТЫРЫША: НИЧЕК СОҢ БЕЗ, НИЧӘМӘ-НИЧӘ ЦИВИЛИЗАЦИЯНЕ КИЧЕП, ИСКИТКЕЧ ЮГАРЫ ТЕХНИК АЛГАРЫШКА ИРЕШЕП, ЮГАРЫ МӘДӘНИ ЯШӘЕШ МОДЕЛЕ ХАСИЛ ИТЕП, ҮЗЕБЕЗ СӘЕР ҺӘМ МӨШКЕЛ, «КУРКЫНГАН ҖӘНЛЕККӘ ТИҢ» ХӘЛДӘ КАЛДЫК?

БЕНХАМИН ЛАБАТУТ, «КАМЕНЬ БЕЗУМИЯ» 18+

Ad Marginem нәшрияты, 2025

«Лабатут әсәрләрен тәрҗемә итү – упкынга карауга һәм ул упкынның кайчан сиңа күтәрелеп каравын көтүгә тиң. Бәлки, упкын безгә инде бик күптәннән карап торадыр, без аның күз карашын абайламыйбыз гынадыр. Ә Лабатут – абайлаган...»

Полина Казанкова, язучының рус теленә тәрҗемәчесе

Соңгы елларда шактый популяр булып киткән, чыгышы белән чилилы (үзе Нидерландта яши) язучы, чагыштырмача яшь автор Бенхамин Лабатут иҗатын аерым бер кысаларга гына кертеп каравы авыр булыр. Аның романнары синтезны тәшкил итә – нон-фикшн белән фәнни фантастика, философия белән биография, сәнгатилек белән журналистика, публицистика чикләрендә тора. Әсәр геройларын да үзенчәлекле сайлый ул: математик Джон фон Нейман, квант механикасына нигез салучылар Нильс Бор, Вернер Гейзенберг һәм Эрвин Шредингер.

Рус телендә беренче дөнья күргән китабы – «Когда мы перестали понимать мир» – көчле кызыксыну уятты, бестселлерлар исемлегенә керде. Икенче китабы – «MANIAC» – шулай ук яхшы сатылды, язучының Россиядә үз аудиториясе барлыгын янә бер мәртәбә исбатлады. Һәм менә 2025 елда – яңа әсәр.

«Камень безумия» китабында Лабатут беренче китабындагы темалар белән мотивларны дәвам итә. Кешелек дөньясы акыл һәм логика белән эш итүгә, рациональлеккә йөз тотса да, фән белән техника алгарышы күз алдында булса да, чынбарлык контурлары барыбер көннән-көн юыларак төшә, кешелекнең бу дөньяны аңлавы кими бара, ди безгә язучы. Бүген без, әле җир яратылган гына чордагы җан ияләредәй, хаосның өстенлек алып, бар нәрсәне дә пыран-заран китереп ташлавыннан куркабыз. Бу – хайвани дәрәҗәдәге, хтоник курку, ди Лабатут.

Язучы соңгы еллардагы пандемия китергән шом, глобаль челтәр белән ясалма интеллектның кешелекне үз ятьмәсенә йолып алуы, дөнья күләмендә барган локаль һәм масштаблы кан коюлар җирлегендә адәм баласының ничек үзгәрүе турында фикер йөртә. Бу даими хаос эчендә, аның карашынча, бары тик даими аффект халәтендәгечә генә яшәп була. Ягъни кешеләр үзләрен «акылдан яздым» чигендә тоярга ияләшә, бу аларның баш миендәге нейрон бәйләнешләрне дә тулаем үзгәртә.

«Дөньяның нигезен тәшкил иткән нарративлар кризис кичереп кенә калмыйча, җимерелеп юкка чыккан бер дәвердә, борынгылар кебек, кабат интуициябезгә һәм сәер төшләребезгә генә ышанырга кала», – ди ул.

Бу повесть герое – Илнур Хәертдинов. Татарстанда оештырылган «Тимер» батальонының тугызынчы ротасы хәрбие «Урал» мотоциклы белән яу кырыннан, алгы сызыктан 126 яралыны алып чыга. Бусы – рәсми сан, хезмәттәшләре ул коткарган кешеләр исәбе бермә-бер күбрәк, 200 гә якын, ди.
Илнурның позывное, икенче төрле әйтсәк, хәрби кушаматы – Фаза. Аның гомере 2024 елның 6 июнендә өзелде. 12 июньдә мәрхүмне Казанның Курган зиратына җирләделәр. Матәм митингында Илнур Хәертдиновка Россия Герое исеме биреләчәге дә әйтелгән. Бу юллар язылганда ул вәгъдә үтәлмәгән иде әле. Автор чын күңелдән хакыйкать өстен чыгып, Илнур лаек булган әлеге югары дәүләт бүләгенең «Алтын Йолдыз»ы аның якыннарына тапшырылыр, дип өметләнә.
Бу повесть сугыш турында түгел. Бу повесть – үлем тантана иткән мәхшәрдә дә яшәргә омтылу хакында. Яшәү хакын саклап калу теләге нәфрәттән өстенрәк булуы турында.

Фирдүс Гыймалтдинов

«ҮЛЕМНӘН БЕР АДЫМ АЛДАРАК»

(Повестьтан өзек)

– Тагын бер биш йөз метр чамасы калды, Фаза, тагын бераз гына! – Илнур колагында яңгыраган тавышка меңләгән төсмерле хисләр төерләнгән иде.

Ул, тешләрен кысып, «Урал» мотоциклының мөгезләренә ныграк ябышты. Юлы җиңел түгел шул. Танклар изеп бетергән канаулар буйлап барасы. Читкәрәк чыгуы хәтәр – минага эләгүең бар. Әнә бит, хәтта тимер тавы төсле танклар да, язмышларына буйсынып, бер-бер артлы бер генә сукмактан үткән. Танк кадәрле танк минадан курыкканны, аның «Урал»ы нәрсә ул?!

Тегеләрнең чылбырлары изгән кантарларда җиңел мотоциклны як-якка атып бәрә, әмма Илнур аны туры юлдан яздырмаска көч таба. Үзе генә булганда түзәрлек, ә менә арбага яралы солдатны утырткач, болай ук каты куалар җай калмас...

– Хәзер, килеп тә җитәсең, – дип пышылдады колактагы тавыш.

Илнур теге башта блиндажда утырган пилотсыз очкыч операторын күз алдына китерде. Менә ул экранга текәлгән, басу буйлап җилдерщ торган мотоциклдан һич кенә дә күзен алмый. Аның тирәли, һичшиксез, тагын берничә хәрби өелешкәндер. Үзенә күрә реалити-шоу. Аларның да йөрәге, әлбәттә, Илнурныкы белән бер ешлыкта тибәдер. Чөнки бу – көндәлек уен шикелле. Уенның мәрәкәсе генә хәтәр – Фаза бу юлы да исән-имин әйләнеп кайта алырмы, әллә юкмы?!

Экранда – ахырзаман күренеше. Һавада эленеп торган очкыч камерасы аша ул чынбарлык белән чагыштырганда да яманрак төсмергә керә. Очлары урак белән урып алынган төсле караеп торучы агач-куак калдыклары, айдагы кратерлар сыман ыржаеп яткан снаряд эзләре. Басу өсте әйтерсең махсус шулай телгәләп-тишкәләп бетерелгән. Гүя кемдер шушындый манзараны булдыру өчен биниһая күп көч куйган...

– Хәзер сулга, Фаза! – дип дәште колактагы тавыш.

Илнур каерылып өскә карады. Һавада очкыч эленеп тора. Аның җансыз күзен шушы йөз метр чамасы арадан да күреп була төсле.

– Безнеке ул, бер дә курыкма. Әлегә тыныч, – диде оператор тавышы.

Мотоцикл, танклар колеясыннан очып чыгып, бермәл һавада эленеп торды, аннары дө-

бердәп җиргә барып төште. Газны киметмичә генә, Илнур тимер атын агачлыкка юнәлтте.

Һавадагы әчкелтем төтен исе куаклыкка кергәч тагын да зәһәрләнә. Мотоцикл көпчәкләре астыннан көл катыш корым өермәсе күтәрелде. Илнур ерак бармый туктады, двигательне шунда ук сүндерде дә як-ягына каранды.

– Тыныч, Фаза, тыныч! – Колактагы тавыш бу шомлы хасияттә азмы-күпме ышаныч бирә иде.

Ул янә һавага бакты. Очкыч аның өстендә эленеп тора. Бүксә төсле чыгып торган камера-күзе тирә-юньне күзәтә. Димәк, ул-бу була калса, аны кисәтерләр.

Ерак түгел снаряд ярылып гөрселдәде. Алгы сызыкта бәрелеш дәвам итә. Әледән-әле миналар сызгырып үтә. Аннан соң автомат, я булмаса пулемёт сиптереп алгалый. Телевизордан мондый халәтне «канлы бәрелеш» дип атыйлар. Ә тегендә, алгы сызыкта, барысы да ничектер бер җайга салынган төсле салмак кына бара. Кемдер үлә, кемдер җиңә. Хәер, җиңәләрме икән?!

Илнур агачларга күз салды. Алар узган ел ук һөҗүмгә эләккән. Урталай сынган кәүсәләр тоташ кисәүгә әйләнгән, аста исә яңа куаклар шаулап үсеп чыккан. Сукмаклар шәйләнә. «Кабан» сукмаклары...

Аяк астын күзли-күзли Илнур куаклык эченә атлады. Һавада җансыз иптәше – очкыч бар, ә менә җирдәге таҗлы миналар хакында кисәтүче табылмас. Үзе вак, үзе мәкерле – ялгыш бассаң, аяк табанын өзеп ташлый. Ике як та ул таҗларны бик мулдан сибә. Өзелгән аякка үзеңнең мина гаепле булды ни дә, дошманныкы ни – барыбер...

– Фаза, хәзер син аны күрерсең, – колактагы тавышны элеккечә аермачык ишетерлек түгел, тоткарлыклар, чит шау-шу да өстәлде. Фронт сызыгы якын. Элемтәне махсус җайланмалар белән бастыралар. Оператор белән аралар бөтенләй өзелә генә күрмәсен...

Яралы солдат – «ноль» ноктасында. Фаза аңа таба ыргылды. Теге бичара бронежилетын салып ташлаган. Ул, елан кабыгы төсле боргаланып, янәшәдә ята. Яралы егет мылтыгын кулына кысып тоткан. Илнур, солдатка тәмам якынайгач кына, көпшәнең үзенә таба төбәлгәнен абайлады.

– Үзебезнеке мин, – диде ул, кулларын алга таба сузып. Әйтерсең, яралы хәрби кисәк кенә атып җибәрсә, пуляны учлары белән тотып кала алыр. Бу акыл белән уйлап караганда тиле фикер, әмма кеше инстинктлары һәрвакыт өстен чыга, буш кулын сузып булса да организм үзен саклап калырга омтыла. – Син ни атлы буласың? Мин – Фаза.

– Снежок, – солдат моны ыңгырашып диярлек әйтте, аннан хәлсез кулындагы мылтыгын төшерде.

Илнур «өчйөзенче»не күздән кичерде. «Өчйөзенче» – яралы була. Аркасын агач төбенә терәп ята төшкән, сул кулы белән корсагын кысып тоткан. Бармаклар арасыннан аз гына кан саркый. Илнур аның янәшәсендә тезләнде, саклык белән генә кулын корсагыннан каерып диярлек алды. Тегеннән тимер кисәге тырпаеп тора. Пычагын чыгарып, ипләп кенә киемнәрне кисәргә кереште.

– Снежок – синең ише олы гәүдәгә килешеп үк бетми кебек, – дип, ул арада карашын егеткә күтәрде.

– Аның каравы сиңа Фаза килешә. Ярый ла, Заземление түгел, – йөзе авыртудан чытылса да, яралы елмайган итенде.

– Чәчләрең ап-ак, шуңа Снежок, димәк...

– Үзең күзәтүчән тагын, ник разведкага гына бармадың?

Илнур иңендәге букчасыннан күпләп марля, бәйләвеч материал чыгарды. Яраны тимер кисәге тирәли булса да эшкәртергә, аннан әлеге дә баягы кыйпылчыкны арлы-бирле йөрмәслек итеп ныгытып куярга кирәк иде. Тартып чыгару һич ярамый – солдат шул мизгелдә үк үлеп китәргә мөмкин. Һәрхәлдә, Илнурны сугышка җибәргәнче шулай өйрәттеләр кебек.

– Су бирче, – диде Снежок, кипшегән иреннәрен тел очы белән ялап.

– Ярамый, дустым.

– Үзем генә шушында кадәр килә алдым, – диде егет, дезинфекцион сыекча яраны өтеп алганда сискәнүеннән кашларын җыера төшеп. Аның тавышында мактану да, горурлык та сизелде. Илнур янә аның йөзенә күз салды. Танау асты да кипмәгән яшь егет...

– Алай булса, яшисең инде, дустым. Бераз түзәргә туры килер, яме?

Илнур янә яра, аның үзәгендәге тимер кыйпылчык тирәсендә кайнашырга кереште.

– Йоклама, – берничә мәртәбә шулай искәртте ул егетне.

– Күзләрне генә йомып торам мин...

– Йомып торма. Йоклап китсәң, уянмыйсың.

– Алай да булырга мөмкин инде. Ни дисәң дә, ике төн аяк өстендә бит. Изрәтә.

Илнур, яра белән азмы-күпме эшне бетергәч, Снежокның мылтыгына, букчасына һәм бронежилетына үрелде.

– Мин хәзер боларны илтеп куям да кире киләм, яме?

– Үзем бара алам, дидем бит...

– Бармыйсың. Мин хәзер киләм. Ничек мәтәлмәгәнсең, шул ара узып...

Фаза мотоциклы янына ашыкты. «Урал» ачыграк урында тора. Шуңа бирегә иелә төшеп кенә килде.

– Әлегә тыныч, курыкма, – диде колакта оператор тавышы. Якында гына янә миналар гөрселдәде. Пулемет, автомат чиратлары яңгырады. Аннан янә бар нәрсә тынлыкка охшаш халәткә чумды. Бары тик өстә пилотсыз аппарат пырылдаганы гына ишетелә иде.

Снежокны аякка бастыру шактый катлаулы эш булып чыкты. Олы гәүдәле егет тәмам хәлсезләнгән, җитмәсә, берәр төрле хәрәкәт ясаган саен корсагындагы кыйпылчык, яман авырттырып, тирәнрәк кадала бара. Алгы сызыкта укол ясаганнар үзенә, әмма аның тәэсире инде кимегән, ә яңасын кадарга иртәрәк...

– Берәүне «Ашыгыч ярдәм» белән алып киләләр, – диде Снежок, авыр сулап, мышный-мышный булса да атларга тырышып. – Моның корсагында – пычак. Доктор сорый инде: «Нәрсә, авыртамы?» – ди. «Юк, доктор, көлгәндә генә», – дип җавап бирә тегесе.

Бәлки, башка вакыт булса, әлеге мәзәк Илнурга көлке дә тоелыр иде. Әмма мондый шартларда нигәдер бер дә көләсе килмәде.

– Сөйләшмә, дустым. Хәлең генә китә.

Мотоциклга ун-унбиш адым калган иде, колактагы оператор телгә килде.

– Фаза, катып калыгыз. Дрон.

Илнур туктау белән, Снежок та аның гамәлен кабатлады. Әллә ул да дошман аппаратының якынлашуын сизде, әллә үзен коткарырга килгән солдат белән сүзсез дә аңлашу дәрәҗәсенә күчкән иде.

– Акрын гына чүмәшергә кирәк, – дип пышылдады Илнур, чүгәләргә маташып.

Снежок та аңа кушылды, әмма шунда ук тартышып куйды.

– Булмый. Авырта.

– Басып торырлык җаең бармы соң?

– Басып тору хәерлерәк...

Фаза башын һавага күтәрде. Аларны агачларның берән-сәрән ялангач ботаклары гына каплап тора.

– Җиргә кара, – дип боерды ул Снежокка, үзе дә карашын аяк башларына төбәп. – Бәлки, күрмәсләр.

– Бәлки түгел. Күрмәсләр.

– Нәкъ сезнең баш очында, – оператор үзе дә пышылдауга күчте. Әйтерсең, ул да биредә, аның да язмышы Фаза белән Снежокныкы төсле кыл өстендә тора.

Илнур үзен өстән бораулаганнар төсле хис итте. Әлбәттә, дошман аларны күрде, таныды, агач-куак арасына поскан ике солдатның берсе Илнур икәнлеген дә ачыклады! Хәзер үк, сызгырып, алар ягына миналар очып килер.

– Китә, – оператор тирән итеп сулыш алып куйды.

– Хәзер мөмкин кадәр тизрәк мотоциклга таба! – Илнур Снежокны иңеннән кысыбрак тотты һәм кызурак атларга өндәде. – Ныклап тотынып утырырга тырыш. Юлның нәрсә икәнлеген күз алдына китерәсеңдер. Мин булдыра алганча салмаграк барырга тырышырмын, шуннан артыгын вәгъдә итә алмыйм. Аңлыйсыңмы?

– Аңлыйм...

Илнур Снежокка текәлеп карады. Егетнең тәмам хәле киткән, ул инде Фазага салынып ук тора. Күзләре менә-менә йомылып китәр төсле.

– Егеткәй, йоклап китә күрмә! Бераз гына түз!

– Түзәм, – Снежок янә кипшегән иреннәрен ялады. – Миңа егетләр әйттеләр – «Урал» тавышын ишетсәң, котылдым дип сана. Бу якта эвакуациядә бердәнбер шундый мотоцикл, аның әле беркемне дә үлемгә дучар иткәне юк, диделәр. Никтер, мин аларга ышандым...

Егетнең сүзләре Илнурның күңеленә тиде. Тормышның нәрсә икәнлеген аңлый гына башлар борын ут эченә кергән яралы егетнең карашы ихлас өмет тулы иде. Абыйларча тегенең башындагы чәчләрен як-якка тузгытып, «Курыкма, брат!» диясе килде.

– Күп сөйләшмә. Аларның хаклымы-юкмы икәнлеген моннан котылгач белербез, – дип тавышын мөмкин кадәр кырысландырып ысылдады ул.

Алар икәүләп мотоциклга титакладылар. Килеп җитәрәк янә оператор телгә килде.

– Фаза! – Тавышында курку ярылып ята иде. – Тизрәк бул.

– Тырышабыз.

– Сиңа күктән күкәй төшәргә тора...

Илнур эсселе-суыклы булып китте.

– Күргән, димәк...

– Мөгаен... «Өчйөзенче» ничек?!

– Яшәячәк, – Илнур адымын кызулатты. Яралы солдат аңа тагын да ныграк салына төште.

– Әгәр...

– Әгәргә урын юк. Мин аны алып чыгам. Яшәячәк.

Сугышның кырыс кануны. «Әгәр алып чыгарлык булмаса, калдыр», – димәкче иде оператор. Фаза аңа җөмләне тәмамлар җай бирмәде. Юк сүз. Илнур Снежокны калдырмаячак...

Калганы бер сулышта булды шикелле. Йөгерә-чаба мотоцикл янына килеп җиттеләр. Илнурның колагында үзәккә үтәрлек пырылдау – һич аңламассың, бу үзләренең күзәтү дронымы, әллә инде граната аскан дошман очкычымы?! Каерылып күккә караудан мәгънә юк.

Снежокны арбага утырту үзе бер газап булып чыкты. Бер үк вакытта икесе өчен дә газап. Ахыр чиктә, егетне урнаштыра алды, тегесе тоткаларга чытырдатып ябышты.

Калтыранган куллары белән ягулык кранчыгын ачты. Карбюраторны көйләде. Яхшы, бензин үз юлын тапты кебек. Массаны кабызды. Стартерны ычкындырды. Бер кулы белән газга ябышты. Педаль. Бер типте. Мотоцикл кириләнеп пошкырып кына куйды.

– Фаза! – Оператор артыгын әйтмәде. Дошман очкычы алар өстендә икәнлеген болай да аңларга мөмкин иде.

Икенче тапкыр типте.

– Түбәнәя...

Өченче тапкыр. Ниһаять, двигатель кабынып китте. Илнур шунда ук мотоциклга атланды да, газны төбенә кадәр борды.

Алар кузгалып киткәннең икенче мизгелендә граната шартлады. Илнур мотоцикл багына ята төште. Балчык, таш, агач кисәкләре шабырдап аркасына сибелде, яка артына кереп тулды.

Ниндидер кыйпылчыклар кулларын өтеп алды. Әмма алар шартлау үзәгеннән китеп өлгергән иде инде. Илнур бишектә яткан Снежокка күз салды.

– Йоклама, ишетсен колагың! – дип шәрран ярды ул.

Тегесе, әлбәттә, аны ишетмәде. Шулай да, аңладым дип, уң кулындагы баш бармагын күтәрде. Хәтта елмайды да кебек.

Мотоцикл янә бер һавада сикереп куйды. Очып барган көенә үк рульне борып, алар танк колеясына килеп төштеләр. Түмгәкләрдә уңлы-суллы сикергәләп, мотоцикл үзебезнекеләр ягына ашыкты. Бер күзе юлда, икенчесе яралы солдатта иде Илнурның. Нык егет, бирешми! Мотоциклны як-якка бәргәләсә дә, кискен тартышулардан үзен чәнчеп алган авыртуны тешен кысып кичерә.

– Курыкма, Снежок! Без әле!... Без әле яшибез, менә күрерсең, әйтте диярсең!

– Фаза, алга таба чиста, – оператор тавышы янә салмак бер халәткә кергән иде.

– Йөзенче, – дип үз-үзенә пышылдады Илнур һәм мотоцикл бишегендә сузылып яткан егетка күз салды. – Син – мин коткарган йөзенче яралы, Снежок...

Тегесенең күз карашы инде томанлана башлаган, әмма ул Илнур әйткәнне аңлаган кыяфәт чыгарды. Янә баш бармагын күтәреп, шәп, дип ишарәләде. Алда, инде берничә дистә метр гына ераклыкта аны үзләренең медиклары, снаряд-дроннардан сакланган блиндажлар һәм тормыш көтә иде. Бәлки, Снежок өчен бу – фани дөньяга икенче тапкыр аяк басу булгандыр...

...Снежокның әйберләрен, коралын, бронежилетын тиешле тәртип белән тапшырып йөргән арада тегене инде медиклар алып китәргә дә өлгергән иде. Рәтләп саубуллаша да алмадылар. Хәер, насыйп булса, күрешерләр дә әле. Дөрес, Снежокка мондый яраланудан соң шактый вакыт хастаханәдә ятарга туры килер. Иң мөһиме – егет исән-сау.

Блиндажга төшеп, биш литрлы шешәдән су салып, голт-голт итеп эчте дә, бер читкә барып утырды. Йөзенче кешенең гомерен саклап калуны тою ничектер рәхәт иде. Шатлыктан кычкырасы, блиндаж түбәсенә менеп басып биисе, үзәкләргә үтәрлек итеп җырлыйсы килде. Тик ул, әлбәттә, алай кыланмас. Үз шатлыгын үз эченә бастырыр да, бу көнне дә тыныч кына үткәреп җибәрер. Ә Снежок аны, һичшиксез, җылы сүз белән искә алыр. Тегендә, алгы сызыкта яралангач та, үзен коткарырдай фәрештә итеп ул нәкъ менә Илнурны көткән бит. Бер җылы сүз. Шуннан артыгы кирәкмени?!

Бу очрашулар – кыска ялганыш сыман. Гомере буе энергетика белән бәйле Илнур үзенә сугыш кырында насыйп булган язмышка әнә шундый чагыштыру тапты. Ялт итеп кабынып китә, күңелдә онытылмаслык эз калдыра да, шунда ук юкка чыга. Йөз яралы, йөз язмыш. Аларның һәрберсе артында гаиләләр, балалар, әниләр... Әни дигәннән... Кесәсен капшап, телефонын чыгарды, кабызды. Бер-бер артлы хәбәрләр өелешеп килә башлады. Алар арасыннан ул әнисенекеләрен аерып алды. Ничек кенә арымасын, әнигә җавап бирергә кирәк. Ул баласы өчен бик нык борчыла. Бирегә китәргә карар кабул иткәч тә, Илнур өчен иң авыры әнисенә шул хакта әйтү иде. Сугышка түгел, төзелешкә барам дип алдады. Анда минем кебек оста, белемле электрикларга мохтаҗлык зур дип шыттырды. Әнисе ышанмады, әлбәттә, әмма бу ялганга барыбер ышанган кыяфәт чыгарды. Улын фикереннән кире кайтарып булмаячагын белә бит әнисе.

Илнур әнисенең әрнү-борчу тулы хәбәрләрен укып чыкты. Иртәдән яза башлаган. Кичкә кадәр тынычлана алмаган. «Барысы да тәртиптә» – Илнур, гадәттә, шуннан артыгын язмый. Бу юлы да бер күнегелгән калыптан чыкмады. Хәбәр китте. Идел буена, Казан каласына, әнисе хозурына барып җиткәнлеген күрсәтеп, парлы «чәүкә» зәңгәр төскә күчте. Үзенең саранлыгына үзе оялып куйды Илнур. Шушы өч сүзне әнисе елый-елый кат-кат укыячагын белә.

Сугыш кыры – үлем урыны гына түгел. Шушы мәхшәрдә дә тормыш барыбер үзенә юл табарга тырыша. Бернигә карамый, снаряд-пулядан курыкмый, Яшәеш дигән илаһи кыйммәт үлем белән аяусыз көрәштә. Һәм аның үз ярдәмчеләре бар. Илнур үзен шулар исәбенә кертә. Йөз кешене коткарды – ничәмә дистә кешегә шатлык алып килә алды. Димәк, ул бу дөньяга юкка гына яратылмаган. Димәк, әнисенең йокысыз төннәре, аны аякка бастыру өчен түгелгән исәпсез-хисапсыз хезмәте бушка түгел. Ул беркайчан да битараф була белмәде. Гаделсезлекне тыныч кына күзәтә алмый. Мондый холык белән яшәве авыррак иде, билгеле. Ләкин ул шушы рәвешкә салынган тормышыннан чын тәм таба. Аны күпләр аңламый. Хәер, күпләрнең аңлавы кирәк тә түгел. Күкләрдән барысын да күзәтеп торучы Ходай Тәгалә разый булса, үзенең намусы белән каршылыкка кермәсә – шунысы җитә кала.

Көн саен ул үлем белән күзгә-күз очраша. Ничәмә тапкыр аның салкын сулышы аркасын өшетеп үтте, кайнар уты колак очларын көйрәтеп алды. Әлегә кадәр бу куркыныч алыштан Илнур җиңүче булып чыга. Димәк, фәрештәсе аны саклый. Сугышның әлегә очы-кырые күренми. Киресенчә, яу кырындагы шартлар кырыслана гына бара. Снежок төсле өмет белән коткару көткән егетләр аз булмас кебек...

Үлемнән дә җитез. Бу узыш кайчан башланды соң? Әйе, теге вакытта, әле Запорожье якларында резервта торган чакта, командирлары кайдандыр мотоцикл юнәтеп кайткач шушы юлга чыкты ул. Хәзер инде мотоцикллар иярләгән эвакуация төркеме башлыгы данлыклы Фаза...

Илнур, елмаеп, шул чаклар хатирәсенә чумды һәм, оеп, йокыга киткәнлеген сизми дә калды.



Татарстан авылары

ИСКЕ КАРАМАЛЫ: АККОШЛАР КАЙТКАН ЧАК...



Фото: Лилиана Вәлитова

ИСКЕ КАРАМАЛЫ

Авыллар буенча йөргәндә еш кына бер җөмлә ишетәбез: «Сез безгә җәен килегез, ә май аена туры килсәгез, тагын да әйбәт. Бөтен җир шау чәчәктә була». Ләкин май елга бер генә килә, бик теләсәк тә, бөтен җиргә ул айда барып җитешеп булмый. Мөслим районына исә әнә шундый иң матур чакта – май азагында сәяхәт кылдык.

Районның атаклы, борынгы авылларның берсе – Иске Карамалыга килеп җиткәч, кинәт туктап калдык. Авыл башындагы күлдә аккошлар йөзеп йөри. Бер генә түгел, берничә пар. Тик без машинадан төшмәскә булдык, мәхәббәт кошларын куркытасыбыз килмәде. Инде шик калмады – нәкъ менә май аенда бирегә килеп ялгышмаганбыз.

Руфия Фазылова

«ТӘМЛЕ СҮЗЕ БЕЛӘН ДӘ ДӘВАЛЫЙ»

Иске Карамалы борынгы, зур авыл. Биредә бүген 363 кеше яши, 199 хуҗалык бар. Иске Карамалы авыл җирлегенә биш авыл керә. Аның берсендә ике генә кеше теркәлгән. Карл Либкнехт исемен йөрткән бу авылны инде беткән дип әйтеп була. Ләкин аның оешу тарихы бик кызык: революциядән соң, төрле милләт халыкларын бергә җыеп, «яңача» авыл оештырмакчы булганнар. Халык өендә ашарга пешерми, колхоз ашханәсендә туклана, баракларда яши... Ләкин әлеге тәҗрибә бу җирлек өчен туры килмәгән, нәтиҗәдә, Карл Либкнехт исеме бирелгән сала бер гасыр эчендә бардан юк булган.

ФАП – авылның йөзек кашы.

– Коллективыбыз бик тату, рәхәтләнеп эшлибез, – диде Зифа Галиева.

Иске Карамалы җирлекнең иң зур авылы санала. Бирелә урта мәктәп, балалар бакчасы эшләп тора, яңа фельдшер-акушерлык пункты, янгын сүндерү бүлеге, кибет, мәчет бар. Кыскасы, авыл нык. Юллар да каралган. Аны үзсалым акчасына да, дәүләт программасы хисабына да яңартып торалар икән.

Гадәттә, авыл белән танышуны мәдәният йортыннан башлый идек. Ләкин бу юлы авыл җирлеге башлыгы Илнур Кәримов ФАПны күреп чыгарга өндәде.

– Мондый шәфкать туташлары бүтән беркайда да юк, үзегез инанызгыз әле, – диде.

Чынлап та, ФАП – авылның йөзек кашы. 1950 нче елларда авылда участок хастаханәсе ачылган. Анда бөтен тирә-як авыллардан килеп дәваланганнар. Бала табу йорты да шунда ук булган. Амбулатория белән стационар аерым бинада эшләгән. Заманасына күрә бер дигән дәвалау үзәге булган ул. Тик 2012 елда хастаханәнең стационар бүлеге ябылган.

– 2012 елда яңа ФАП бинасы төзеделәр, – дип, көндезге амбулатория бүлеге белән таныштырып йөрде Зифа Галиева. – Ул чакта бик сөендек, чөнки эшләргә бөтен уңайлыклары бар. Физиотерапия, процедура бүлмәсе – барысы да заманча. Аерым даруханәбез дә бар. Халык өчен бик уңайлы. Кан анализлары да алабыз, системалар да куябыз. Чирләп китсә, халык район үзәгенә түгел, башта безгә килә.

Зифа Галиева биредә 46 ел шәфкать туташы булып эшли икән. Күрше Әмәкәй авылы кызы. Минзәлә медицина училищесын тәмамлап, Иске Карамалыга эшкә кайткан. Бүген авылның ветераннар советын да җитәкли. Көнме-төнме – тәүлекнең теләсә кайсы вакытында беренче ярдәм күрсәтергә чыгып йөгерә.

– Тәмле сүзе, ачык йөзе белән дә дәвалый ул безне, – диде ак яулыклы бер апа.

– Кайчагында кешегә бер җылы сүз әйтеп, тынычландырып җибәрү дә ярдәм итә, – дип дәвам итте Зифа апа. – Без шулай эшлибез дә. Ишектән кергәндә үк авылдашларны елмаеп каршы алабыз. Мин генә түгел, ФАПта дүрт кеше без. Коллективыбыз бик тату, рәхәтләнеп эшлибез. Инде күптән лаеклы ялда булсам да, китәсе килми әле. Авыл халкы да җибәрми, үземә дә рәхәт, икенче гаиләм кебек...

ЧИТ БАЛАЛАР БУЛМЫЙ!

2003 елда Иске Карамалыда балалар һәм яшүсмерләр өчен «Наз» социаль приюты эшли башлый. Ни өчен биредә, дигән сорауга җавап: шул елны участок хастаханәсенең бер бүлеге ябыла. Буш бина урынына приют ачалар. Анда егермеләп бала була. Авылның күп кенә хатын-кызы биредә эшли башлый. Кемдер – тәрбияче, кемдер – пешекче, санитарка... Тик приют 2014 ябыла. Ә андагы балаларны авыл кешеләре үзләренә тәрбиягә ала. Шул елларны авылда 16 (!) гаиләдә тәрбиягә алган балалар үсә. Әлбәттә, төрле хәлләр була. Кайберләре балаларны кире дә илтеп бирә. Тик күпчелеге бу балаларны үзенеке итеп тәрбияли. Инде аларның күбесе авылдан чыгып киткән, укыйлар, эшлиләр. Әмма үскән йортларын, әти-әниләрен онытмыйлар, кайтып йөриләр.

Маликовлар авылда беренче булып тәрбиягә бала алган гаилә. Уналты баланы үз канаты астына сыендырган олы йөрәкле, батыр ана белән без дә таныштык.

– Мин приютта эшләдем, – дип сүз башлады Марсилә апа Маликова. – Рәмис исемле малай мине зерә якын итте, артымнан калмый гына бит. Берзаман: «Пычага алып кайт әле мине», – дия башлады. Шулай итеп, мунча керергә алып кайттым. Үзен генә түгел әле, ике абыйсы – Руслан белән Рөстәмне дә. Тора-бара өчесен дә шулай алып кайтып, мунча кертеп чыгара идем. Берзаман приюттан Рөстәмнең документларын соратып алдылар. Америкага тәрбиягә алырга телиләр, дигән хәбәр килеп ирешә. Бик борчылдым шулчакта, бу бертуганнарны аерсалар, аннан соң мәңге бер-берсен табышмаслар. Рөстәмне тәрбиягә алган гаилә нинди булыр... Ятсам да, торсам да, шул балаларны уйлап йөрим. Иремә бу хакта әйттем. «Әллә үзебезгә алып кайтыйкмы? Өй иркен, шунда бергә үсәрләр иде», – дим. Ирем каршы килмәде. Әнә шулай итеп 2004 елда өч бертуган баланы алып кайттык.

Туганнар бүген Чаллы шәһәрендә яши икән. Дәүләт өчесенә дә фатир биргән. Гаиләләре бар. Анысы да монысы, Руслан үзен тапкан әнисен карап, соңгы юлга озаткан.

– Тудырган әнисе авыруга әйләнгәч, карар кешесе булмагач, шулай үзе тәрбияләде инде, – диде Марсилә апа. – Әле үз этиләре дә анық фатирына күченеп килде. Әнә шундый мәрхәмәтле бала булып үстеләр.

Маликовлар бүген тугыз кеше яши: Марсилә апаның улы, килене, аларның ике баласы, кырык алты яшендә тапкан кызы һәм тәрбиягә алган өч баласы. Ни аяныч, гомер иткән тормыш иптәше дүрт ел элек мәрхүм булган.

– Олыгая-олыгая кеше тынычлык эзли башлый. Сезнең йортта һаман да бала-чага тавышы, арымыйсызмы? – дим.

– Беренчедән, без ун бала үстек, тавышка өйрәнгән мин. Икенчедән, йортыбыз иркен, ике катлы, – диде Марсилә апа. – Өйдә тынычлык булганда, киресенчә, ямансулый башлыйм. Әле менә тиздән балалар мәктәптән, бакчадан кайта. Шуларга дип ризык пешереп йөрим.

– Ә дәресләрне балалар үзләре карыймы?

– Үзләре, алар хәзер зур бит инде. Ә элегрәк зурраклары кечкенәләргә ярдәм итте. Ашарга әзерләгәндә дә шулай: бергә-бергә мәш киләбез.

Марсилә апа тәрбиягә алган һәр баласына фатир алу артыннан да йөргән. Мәгълүм булганча, ятим яки ата-анасы хокукларыннан мәхрүм ителгән балаларга дәүләт торак бирә. Документларын барлап, тиешле оешмаларга илтү Марсилә апа өстендә. Ул инде хәзер бу мәсьәләдә белгеч булып беткән.

– Бала паспорт алуга, документлар белән опекага барам, – диде ана кеше. – Элек Казанга йөри идек, хәзер район үзәгендә дә эшләп бирәләр, җайлы. Балалар кая барып урнаша, шул шәһәрдән фатир бирәләр. Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Камада яшәүче балаларым бар, шөкер, үз фатирларында гомер итәләр. Инде үзләре әти-әни булдылар. Кайтып йөриләр, көн саен хәлемне беләләр. Арада аеруча мине якын күргәннәре бар, барысының да исәнимин, матур яшәүләренә сөенеп көн итәм.

Егерме ел эчендә тәрбиягә алган балалар белән нинди генә очраклар булмаган. Күбесенең әти-әнисе исән икән. Марсилә апа аларның очрашуларына беркайчан каршы килмәгән. Алай гына да түгел, балаларның үз ата-аналары алар йортына килеп тә йөргән. Тик бер кыз гына кире үз гаиләсенә киткән.

– Өйдә бала тавышы булмаганда, киресенчә, ямансулый башлыйм, – ди Марсилә Маликова.

– Ундүрт-унбиш яшьләрендә балалар үз әти-әнисе янына барырга рөхсәт сорый башлый, – дип дәвам итте Марсилә апа. – «Бәй, сездә бер кан ага, әлбәттә, күрешегез», – дип әйтәм. Ләкин бер тапкыр баралар да, өйдә рәхәтрәк дип, кире кайталар. Күрәсең, алар чагыштырып карый. Яшерен-батырын түгел, ата-ананы тәртипсез тормыш рәвеше алып барганы өчен хокукларыннан мәхрүм итәләр. Һәм аларның күбесе яңадан аек тормышка кайта алмый...

РУШАТ ПАРКЫ

Иске Карамалы зур авыл, дидек. Бөек Ватан сугышына кадәр биредә 800 дән артык кеше яшәгән. 1929 елда авылда «Алга» колхозы оешкан. 1936 елда исә Иске Карамалы һәм Күбәк авыллары арасында машина-трактор станциясе төзелгән. Халыкның төп кәсебе игенчелек белән терлекчелек булган. Дистә еллар дәвамында бу үзгәрмәгән. Дөрес, хәзер колхоз урынына – агрофирма. Хуҗалыкта мөгезле эре терлек саны да элеккеге кебек өчәр йөз баш түгел, бөтен җирлеккә 123 савым сыеры калган.

– Гөлназ Рәхимова парк эшләүнең барлык чыгымнарын үз өстенә алды, – диде авыл җирлеге башлыгы Илнур Кәримов.

Җирлек башлыгы Илнур Кәримов белән авыл буенча йөрибез. Үзәк урамда, нәкъ мәчет каршында, парк эшләнгән. Баксаң, аны мәрхүм Рушат Рәхимов истәлегенә ачканнар. Иске Карамалының булдыклы егете 2020 елның декабрендә вафат булган. 38 яшендә бакыйлыкка күчкән Рушатның газиз әти-әнисе, өч баласы, яраткан хатыны калган.

– Бу урында элек авыл советы бинасы урнашкан иде, – диде җирлек башлыгы. – Авылыбызның имамы Сөләйман хәзрәт Хафизов шул ташландык бинаны сүтеп, парк ясыйк, дип теләк белдерде. Шулай итеп, авыл халкы көче белән территория куаклардан, ташлардан чистартылды. Аннан соң бу эшне Гөлназ Рәхимова күтәреп алды. Мәрхүм иренең исемен мәңгеләштерәсе килде аның. Балчык җәеп, җир тигезләнде, брусчатка түшәлде, агачлар утыртылды. Барлык чыгымнарны Гөлназ үз өстенә алды. Авылның соклангыч гаиләсе иде алар. Рушатның шулай иртә китүе барыбыз өчен дә авыр кайгы булды.

Парк каршындагы Аллаһ йортын да карап чыгарга булдык. «Борһан» мәчете 2003 елда ачылган. Аның имамы булып Сөләйман хәзрәт Хафизов эшли. Шушы вазыйфада унбиш ел икән. Заманында үзешчән композитор булган, күп кенә җырлар авторы. Лаеклы ялга чыккач, дин юлына баскан. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган, хаҗ сәфәрендә дә булган.

– Революциягә кадәр Иске Карамалыда ике мәчет эшләгән, – диде Сөләйман хәзрәт. – Утызынчы елларда ике мәчетнең дә манарасы киселә, ә биналары совет хакимиятенә тапшырыла. Авыл элек Уфа губернасы, Минзәлә өязенә караган. Сигезенче ревизия документлары буенча, 1844 елда ук Иске Карамалыда мәчет булган. Бүген җомга намазына унбишләп кеше йөри. Һәр елны мәчет каршындагы мәдрәсәдә

Үзәк урамда, нәкъ мәчет каршында, парк эшләнгән. Аны мәрхүм Рушат Рәхимов истәлегенә ачканнар.

укулар бара, ир-атлар, хатын-кызлар, балалар аерым белем ала. Соңгы елларда дингә яшьләр килә, моңа бик сөенәм.

Узган ел мәчеткә янкорма корганнар, аерым тәһарәтханә ясаганнар. Хәтта кырык метр тирәнлектә махсус скважина да казытканнар. Әлбәттә, мәчеткә су кергән булган. Ләкин яңа ясалган кое суын авыл халкы аеруча ярата, шифалы дип, савытларга тутырып та алып китәләр икән.

– Ул суның составын тикшерттем, бик яхшы, – диде Сөләйман хәзрәт.

– Һәм шифалы дамы? – дим.

– Мәчет бит иң изге урын санала. Шулай булгач, андагы су да изге инде. Авыл кешеләре шулай дип ышана. Мин дә инкарь итмим. Бисмилла әйтеп, дога кылып эчсәң, шифасы булмый калмас.

Сөләйман хәзрәт белән Күбәк авылына да барып килдек. Авыл дип, алар Иске Карамалы белән тоташкан диярлек була. Җирле халык өчен андый бүленеш юк та. Мәктәп тә гомергә ике авылга бер булган, хәзер дә шулай. Сөләйман хәзрәтнең тамырлары Күбәк авылыннан, шуңа ул анда да мәчет салып ята.

– Авыл халкы ярдәме белән төзибез. Аллаh боерса, быел түбә астына кертәбез, – диде.

Мөслим халкы матур сөйләме, милли җанлы, зыялы булуы белән аерылып тора. Иске Карамалы да искәрмә түгел. Кайсы гына төбәккә барсак та, үзебезнең татар авыллары өчен сөенеп, горурланып кайтабыз. Т

– Революциягә кадәр Иске Карамалыда ике мәчет булган, – диде Сөләйман хәзрәт Хафизов.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Архивларда Иске Карамалы турында беренче язулар 1762 еллардан башлана. Революциягә кадәрге чыганакларда Карамалы, Калмыя исемнәре белән дә телгә алына. Авылның исеменә килгәндә, бабаларыбыз Калмыя елгасы буйлап килгән һәм бу җиргә төпләнгән. Монда ул чакта күпләп карама агачлары үскән. Шуның өчен авылга Карамалы исеме бирелгән дигән фараз бар.

Сөләйман Хафизов, «Борhан» мәчете имамы

Иске Карамалыда күңелле яшиләр.

Казанибызда сакланып калган, тарихлары милли мәдәниятебезнең асыл шәхесләре белән бәйле агач йортлар белән таныштыруны дәвам итәбез. «Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» шәхси оешмасы белән берлектә эшли.

ТАТАР УТАРЫ: САБИТОВЛАР ЙОРТЫ МЕТАМОРФОЗАЛАРЫ

Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Иске Татар бистәсендәге Шиһабетдин Мәрҗани, 8 нче йорт адресы буенча урнашкан биләмәләр бүгенгәчә Сабитовлар утары булып йөри. Утарны XIX гасыр уртасында сәүдәгәр Хәмит Сабитов төзетә.

КЕМНӘР УЛ – САБИТОВЛАР?

Хәмит Сабитов (1818–1900) үзе тумышы белән Казан өязенең Чувашлы авылыннан. Сәүдә эшен 1852 елда мануфактура товарлары, түбәтәйләр, калфаклар, кәләпүшләр белән башлап җибәрә. Аны Казанда «Азия баш киемнәре белән сату итүче» буларак беләләр.

Бик аз вакыт эчендә тернәкләнеп китеп, Казан базарында үзенең ныклы урынын ала ул. 1869 елдан 2 нче гильдия сәүдәгәрләр исәбендә йөри башлый. Ул гына да түгел, Казан шәһәр думасының гласные, шәһәр управасы әгъзасы, берничә ел Казан татар сәүдәгәрләре җәмгыятенең старостасы булып тора. Иганәче буларак, «Мәрҗания» мәдрәсәсе төзелешенә зур ярдәм күрсәтә.

XX ЙӨЗ БАШЫ ҺӘМ ИНКЫЙЛАБ ЕЛЛАРЫ ҖИЛЛӘРЕ

Утар тарихына килгәндә, аның төрле елларга караган шактый бай тарихы бар. Башка күп кенә сәүдәгәрләрнең затлы йортлары шикелле, ул да XX йөз белән бергә аның күтәрелеш елларын да, михнәтләрен дә кичә.

Утар хуҗасы Хәмит байның картаймыш көнендә сәүдә эшләре әллә ни табыш китерми башлый. 1898 елдан ул, сәүдәгәрлек таныклыгын озайтмыйча, мещан катламына күчә. Үзе үлгәч, 1900 елдан башлап, йорт аның улы Хәйрулла кулында исәпләнә.

Фото: Александр Ефремов

Татар зыялыларының каймагын туплаган «Шәрык клубы» 1907 елда «Болгар» номерларында оешкан булса, 1908–1910 елларда аның әгъзалары Сабитовлар утарында җыела. Димәк, бу йорт диварлары узган гасыр башының затлы шәхесләрен хәтеренә сеңдереп калдырган, дип, шикләнмичә әйтә алабыз.

Гражданнар сугышы да Сабитовлар йортын читләтеп үтми. 1918 елның маенда, Казанны ак чехлардан саклаган иң давыллы көннәрдә, йортның икенче катында 1 нче Мөселман социалистик полкы штабы урнаша.



ЙОРТНЫҢ ЯҢА СУЛЫШЫ ҺӘМ ТОРМЫШЫ

Утарның төп корылмасы классицизм элементлары кергән эклектика стилендә. Үзәк өлеше зур булмаган өч тәрәзәле балкон белән аерыла. Йорт фасадының архитектур бизәлеше шактый саран. Аскы каты кирпечтән, өске каты агачтан төзелгән булуның да хикмәте бар: янгын-фәлән чыккан очракта йортны җиңел генә торгызып була.

2012–2013 елларга кадәр ярымҗимерек хәлдәге утар Универсиада алдыннан реставрацияләнә. Төзекләндерү эшләре биредәге күпчелек иске корылмаларның кирпече хисабына бара.

Комплекс җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объекты булып исәпләнә.

Хәзерге көндә гөрләп эшләгән «Татар утары» кунакханә-ресторан комплексы бинасының язмышы менә шундыйрак. Ул мәркәзебез үзәгендә урнашкан һәм заман шартларында борынгылыкны саклап калуны раслап торган матур бер архитектура үрнәге дә булып тора.



Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

Реклама 16+